КАЛӘМ ИЗГЕГӘ ТАРТЫР

# Мәдәни Җомга

№ 15
27 октябрь
1995 ел

1995 елның июленнән
башлап чыга

Атналык әдәбият һәм сәнгать газетасы



## Бүгенге санда:

**2** *Нәҗибә САФИНА.* Кеше күңеленә тәэсир итүнең төп ике генә юлы бар: берсе — дин, икенчесе — сәнгать.

**6** *Рашат НИЗАМИЕВ.* Халыкның аһ-зарын хәзерге Русия аңламый, аңларга теләми дә шикелле.

**8** *Ильтани ИЛЯЛОВА.* Татар сәнгатенең иң югары үсеш ноктасы рухи иреккә мохтаҗлык заманында, көчле, талантлы затларның рухи изелүгә каршы күтәрелүе чорында туа.

**15** *Хәлиф КУРБАТОВ.* Үзебезнең гүзәл әдәби телебезне кириллицага корылган һәм камиллектән бик ерак торган алфавит һәм орфография аша вату-сындырудан саклап калу өчен латин графикасын гамәлгә кую үтә дә мөһим.

**20** *Фәрит ЯХИН.* Кем дә кем имансыз кала, ул кеше үзен бәхетсезлек вә җәбер-җәфага хөкем итә.

**23** *Марсель ЗАРИПОВ.* Кешеләргә җиләкле болыннардан, урманнардан хуш исле бал ташый торган канатлы җан ияләре турында язу үзе үк рәхәт һәм күңелле шөгыль.



**Ак баланым, диеп чакыр мине,**
**Сине генә өзелеп сөярмен...**

## МӨХӘРРИР МӨНБӘРЕ

Бу илдә аерым кешеләрне генә түгел, тулаем халыкларны да алдап яшәргә була. Чөнки „алдагыч көзгеләр патшалыгы" ялган тәгълиматларны байтак тудырды. Бездә сәяси уенчыларга ялган оят китерми. Йөзләргә миллионлы русияләрне оятсызларча алдалап, яшерен рәвештә, хәтта үзебезнең республикаларга гаскәрләр кертелде. Беркатлы илдәшләрен төрлегә алдап-йолдап, әнә, кемнәр генә властька үрмәләми?! Ни аяныч, дәүләт дәрәҗәсендәге ялганга инде күнегә башладык. Әшулай да алдатмаска иде бит, ватандашлар!..

Мансуров

Зиннур МАНСУРОВ

## МИН ӘЙТТЕМ

Нәҗибә САФИНА

# БЕЗ КЕМНӘР?

Урамда үтеп барышлый берәр баладан шаяртып кына булса да «Син кем?» — дип сорагыз әле. Ул сезгә, кагыйдә буларак, кыз бала булса, «Мин — кыз», ә ир бала булса «Мин — малай» — дип җавап бирер. Мин бу җөмләне язганчы авыл һәм шәһәр урамнарындагы йөз генә балага мөрәҗәгать итеп карамаганмындыр. Берничәсеннән «Мин — Таня», «Мин — Алсу» һәм бик сирәгеннән «Мин — кеше», — дигән җавап ишеттем. Димәк, инде бала сабый чагында ук үзенең төп аерымлылыгы итеп үзе дә аңламастан, җенси аерымлылыгын саный. Ана кешенең дә баласын якты дөньяга кабул итеп алган кендек әбисенә беренче соравы шул ук. «Кем? Кызмы, малаймы?»

Кызның да, малайның да дөньяга килү мизгеленнән аңа булган мөнәсәбәт билгеләнә. Элек-электән өйдә кыз бала дөньяга килгән икән, баланың хәлен белергә, котларга беренче булып ахирәтләре, әби-чәбиләр килә торган булган. Өйгә кергәндә укыла торган догалар да нәкъ кызлар туганда гына укылган, ямьле ыгы-зыгы, гореф-гадәтләр дә кызлы өй өчен генә булган. Бәби күчтәнәчләренә кадәр үзгә булган. Ә инде бүләкләр турында сөйләп тә торасы юк. Кызларга чүпрәкләре дә башка төстә, кием-салымы, юрган-мендәренең җөенә кадәр үзгә булган бит. Ә инде үсә-үсә, алар арта гына бара. Өйләрдә кызлар ягы, кызлар өе, бирнә сандыгы, җеп-чигеш әйберләре барлыкка килә. Ана кеше гаиләдән кыз балага карата илтифатлырак мөнәсәбәт тәрбияләргә омтыла. Көчле мантыйклы аналар теләгенә ирешә дә. Мондый гаиләдә инде ата — улны, ана кызны таный. Ананың: «Кызым, абыеңнар, энеңнәр кайтыр, кыяфәтеңне кара», дигән сыманрак кисәтү сүзләре көн дә телдә була.

Аннары мәктәп. Кызлар — абыстайга, малайлар — муллага, ягъни мөгаллимә һәм мөгаллимгә белем эстәргә китерелеләр. Әлбәттә, озак еллар дөньялар башка төрле булып торды. Малаен, кызын аерып тормыйча гына тәрбия кылмак булып гасырга якын вакыт үткәрделәр. Инде хәзер шуның җимешләрен җыябыз: кыз вә малай, ир вә хатынны үз-үзләрен танырга өндибез. Әмма теләмиләр генә бит танырга.

Ир-егетләребез ирлек горурлыклары тапталу белән килешә алмыйча, әллә нинди хилафлыклар эшләп ташлады инде: сәрхуш, сугыш чукмары, күке-әтиләр булып беттеләр. Ә хатын-кызлар... Йә Ходаем! Әстәгъфирулла, тәүбә лә! Кулларында көрәк тә лом, киркә дә балта. Трамваен, троллейбусын, «Мерседес»ын йөртә. Итәкләренең уртасыннан тегеп ыштан ясап киеп йөриләр. Чалбар турында әйтеп тә тормыйм. Ире булмагач, чалбары ник кирәк инде аның. Ул ир-ат дигәннәре дә хәзер өйләнү өчен өй салу, яшәү өчен хатын алу, багу өчен бала табу дигәнне белми башлады. Фатирлы, машиналы, акчалы һәм бакчалы хатын эзлиләр бит. Нәкъ шундыен тапмаган ничәмә йөз мең ир-ат хатынсыз тереклек итә. Моны яшәү дип булмыйч инде. Ә хатын-кызлар? Ни әйтсәң дә нәфис затлар алар. Хатын-кыз Аллаһы тәгалә тарафыннан нечкә хисле, бәхетле булу һәм бәхетле итү өчен яратылган. Аларның ялгызлары ир-атлардан да күбрәк. Татарстанда гына да ирләргә караганда хатын-кыз 260 меңгә артыграк икән. Тик ирләрдән аермалы буларак, хатын-кызларның күбесе бала табып, ялгыз булса да аны тәрбияләп үстерергә тырыша. Күке-әтиләр исә фәлән сум алимент түләштерә дә башка кайгы-хәсрәте юк. Үз җаена типтереп яши бирә.

Мондый «гаилә»ләрдә инде изге гореф-гадәтләр, үтә нечкә тәрбияви, эстетик чаралар турында уйларга урын да вакыт та калмый.

Урын дигәннән, сүзне бит кызлар ягы, кызлар өе, милләт күе дип башлаган идек. Кызларга түгел, биш-ун кешелек бөтен гаиләсенә бер бүлмә булса да, шөкер итәргә мәҗбүрләр күп бүген.

Мәктәпләрдә дә шулай. Кызы-малаена түгел, урыс-татарына аерым мәктәпләр булдырып булмый. Тырышып-тырмашып ачканнарының да хәлләре мөшкел. Кайсы ябылу алдында, кайсы җимерек хәлдә, кайсы үз илендә килмешәк булып, чиратка салынган чирледәй, кеше почмагыннан кеше почмагына чабып йөри. Ә ул татар мәктәбе, гимназияләрендә кызлар да укый. Кү-ү-п кызлар. Һәм алар малайлардан бик нык аерылып торалар. Әмма кайбер уку биналарында юыну урыны түгел, бәдрәфе дә юк икән. Кызларда хатын-кызлык менә шушы рәвешчә үтерелә башлый түгелме соң?

Учреждение, предприятие, завод-фабрикаларда ике бәдрәфкә һәм бердәнбер юыну урынына бер ишектән диярлек керәсең.

Уңайсызлану, оялу хисләрен кыз бала сүндерергә тырыша. Шул рәвешле үз-үзен югалта бара. Ә бер бүлмәле өйләрдә ир белән хатын иркәләнми торалармы әллә? Әллә назланмый яшиләрме?

Кыз баладагы изгедән дә изге хисләр шулай очсызлана башлый, кыз бала күңеле бу «хәлләр»не күреп хәтта рәнҗи. Әйе, җаны рәнҗи... һәм күнегә. Ә шул алиһәдәй саф күңелле кызларыбызга бүген телевидение аша ниләр генә күрсәтмиләр!!! Андый кызларның түгел, дөньяның ак-карасын, өчесен-төчесен татыган олы гына яшьтәге хатыннар да хурлыктан гаҗиз калабыз. Гомер иткән ирләребезгә күтәрелеп карый алмыйбыз. Ә кинотеатрга егете белән фильм карарга килгән кызлар җир тишегенә керердәй булып утыралар. Күптән түгел миңа ялгыш кына ике ир-атның сөйләшүен тыңлап торырга туры килде. Ул диалогны сүзгә-сүз китерәм:

— Сиңа нәрсә булды? Шундый ярата идең бит син аны?

— Ярата идем шул...

— Ни булды соң?

— Ни, ни? Әйтсәм, ышанмассың да. Болай караганда берни дә түгел кебек. Ә миңа әллә нәрсә булды. Бөтенләй күңелем кайтты үзеннән.

— Бөтенләй күңел кайтырлык нинди әкәмәт соң ул?

— Әкәмәт шул. Болай булды бу. Кичә ифрат ямьле итеп җәйге айлы кичтә йөргәннән соң өенә барганда... шул инде.

— Нәрсә шул инде?

— Ну, тышка чыгасы килде моның, кысталганын тойгач, үзем үк, бар агач арасына, дидем. Һәм... күреп тордым, моның «түгелгәнен».

— Ник?

— Үзем дә белмим... Кыскасы, аның белән башка очрашасым килми.

Әйе, чыннан да, әллә ни дә булмаган кебек. Әмма бер нәрсә көн кебек ачык: артык шәхси, яшерен башкарыла торган гамәлләрне сөекленә дә күрсәтергә ярамый икән. Патша булып патша да үзе генә җәяү йөри торган урын, дип юкка әйтмәгәннәр аны.

Бервакыт чечен милләтеннән булган бер егет болай дип сөйләгән иде: «Сездә хатын-кызга хөрмәт юк. Эчү-тартуны әйтеп тә торасы юк, урамда басып сиюгә кадәр барып җиткәннәр. Ә бездә хатын-кыз бар җирдә сер бирү юк...» Аларның үз горурлыгын саклауларына, хатын-кыз исемен югары тотуларына сокландым. Чечен ирләре хатын-кыз күңелен шулай, олы хөрмәт юлы белән яулыйдыр.

Безнең татар хатын-кызлары башка милләткә кияүгә чыкса, телен дә, динен дә сата. Балалары да башка милләт балаларына әйләнә. Ир-егетләребез башка милләт кызларына өйләнсә дә, Оксана-Анюткалар, Глеб-Лешкалар үстерә. Сөйгәне аның телен-динен ишетергә дә теләми.

Ни кызганыч, башка милләт вәкилләре безнең кызларның иң талантлы, иң чибәрләрен чәлдерә.

Әле күптән түгел генә яраткан бер композиторымның башка милләт кешесенә кияүгә чыкканын ишеттем. Аларның балалары кем булыр инде. Кайсы дин кешеләре булырлар да, кайсы милләт моңы, сәнгатен җаннарына якын итәрләр? Ник болай димме? Чөнки кеше күңеленә тәэсир итүнең төп ике генә юлы бар: берсе — дин, икенчесе — сәнгать. Ә безнең гореф-гадәт, йолаларыбыз исә шул икегә нигезләнгән дә бит.

Үткән атналарның берсендә «Дөнья» радиосы тапшыруында Римзил Вәлиев әңгәмәдәше нәфис сүз остасы Розалия Зәкидән: «Сез кем? Нинди ил кешесе, нинди милләттән?» — дип сораган иде. Тегесе: «Белмим дә инде», — диде. Әтисе — татар, әнисе — татар, ә Розалия үзенең нинди милләттән икәнен белми.

Син — кем?

Әгәр сез бүген Казан урамнарында яшь, урта яки өлкәнрәк яшьтәге кешегә: «Син — кем?» дип сорау бирсәгез, ул сезгә теге нәни кыз кебек тиз генә: «Мин — кыз» дип, яки: «Мин — хатын-кыз», дип җавап бирә алмастыр. Чөнки ул инде бу җирдә үзенең кем икәнлеген оныткан.

Минем дә күп кенә кешеләргә: «Син кем?» — дип сорау биргәнем бар һәм мин алардан шундыйрак җавап ишеттем:

— Синең ни эшең бар?

— Пошла к чертовой матери.

— Мин — кеше.

— Мин — Татарстан кешесе.

— А сама кто?

— Мин эттер, миңа дәүләтем шулайрак карый.

— Мин? Мин — җинаятьче. Чөнки башка юл белән гаиләмне тәэмин итә алмыйм.

— Мин — безработный.

— Мин — доллоровая. Чөнки эш тапмадым, башка сатар әйберем калмады. Хәзер барысы да сата һәм сатыла.

— Мин — сәрхуш, җаным. Аек килеш бу дөньяга карап торсаң, акылдан шашасың.

— Мин? Барысы да. Кеше генә түгел...

— Мин — кол! Син дә шулай бит инде.. Үзеңне дә журналист дип атадың. Миеңдә эш кенә. Кеше икәнеңне дә, хатын-кыз икәнеңне дә күптән онытынсың. Тышкы кыяфәтең белән дә ни татар, ни урыс түгелсең.

Иң соңгы респондентым тиләләр йортыннан качкан кыз булып чыкты. Ул миңа: «Смехота?» — дип каядыр ишарә ясап сорау бирде. Мин аңардан. «Син кем?» — дип барыбер сорыйсы иттем. Ул бармагын чигәсенә куеп әйләндереп күрсәтте.

Әһә. Мин — тиле! Шулай. Үзләренең кемлекләрен дә, туган теле, милләте, җенесе нинди икәнен дә белмәгән кешеләр арасында яши-яши анысына да ышанырсың..

## Җидеген

Вакыйгалар
хәбәрләр
яңалыклар

5 6 7 1 2 3 4

# Хезмәтенә күрә хөрмәте

Матбугат өлкәсендә озак еллар эшләгәне өчен «Новый Зай» атналык газите мөхәррире (Зәй шәһәре) **Корнева Юлия Васильевна** Татарстан Республикасының **Мактау Грамотасы** белән бүләкләнде.

Матбугат өлкәсендә озак еллар нәтиҗәле эшләгәне өчен «Сөембикә» журналының баш мөхәррире **Роза Рәхмәтулла кызы Туфитуллова** Татарстан Республикасының **Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

Сынлы сәнгать өлкәсендәге уңышлары өчен рәссам **Владимир Александрович Попов** Татарстан Республикасының **Мактау грамотасы** белән бүләкләнде.

Татарстан Республикасы Президенты Указы белән мәдәният өлкәсендәге казанышлары өчен

**«Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»**

дигән мактаулы исемгә лаек булдылар:

**Нәсимә Газиз кызы Вәлиуллина**, Татарстан китап нәшриятының китапханә мөдире;

**Строителев Анатолий Борисович**, Зеленодол районы Большие Ключи авылы мәдәният йорты директоры;

Икътисад өлкәсендәге казанышлары өчен

**«Татарстан Республикасының атказанган икътисадчысы»**

дигән мактаулы исемгә лаек булды:

**Солтания Сабирҗан кызы Гаетова**, К.Якуб исемендәге полиграфия комбинатының баш бухгалтеры;

Физик культура өлкәсендәге казанышлары өчен

**«Татарстан Республикасының атказанган физик культура хезмәткәре»**

дигән мактаулы исемгә лаек булдылар:

**Елфимов Всеволод Александрович**, «Идел» хоккей-спорт клубы тренеры;

**Илгиз Гариф улы Усманов**, Зәй шәһәре 2 нче урта мәктәбенең физик тәрбия укытучысы.

* * *

Сынлы сәнгать өлкәсендәге уңышлары өчен Татарстан Республикасы Рәссамнар берлеге идарәсе рәисе, рәссам **Абрек Әмир улы Абзгильдинга «Татарстан Республикасының халык рәссамы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Мәдәният өлкәсендәге уңышлары һәм актив җәмәгать эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасы Милли мәдәни оешмалар ассоциациясе президенты, А.Н.Туполев исемендәге Казан техника университетының лаборатория башлыгы **Сәгыйт Кодебай улы Джаксыбаевка «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

Архитектура һәм шәһәр төзелеше өлкәсендәге уңышлары өчен Казан Промышленность төзелешләре проекты институты баш архитекторы **Әлфия Хөсәен кызы Белостоцкаяга «Татарстан Республикасының атказанган архитекторы»** дигән мактаулы исем бирелде.

Сәнгать өлкәсендәге казанышлары өчен Казан шәһәре 16 нчы балалар музыка мәктәбе укытучысы, дирижер **Василевский Анатолий Александровичка** «Татарстан» дәүләт телерадио тапшырулар компаниясенең сәнгать тапшырулары программасы баш редакторы шагыйрь **Әхмәт Әхәт улы Рәшитовка**, Казан хореография училищесы укытучысы **Суханова Жанна Павловнага «Татарстан Республикасының атказанган сәнгать эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

Матбугат өлкәсендәге казанышлары өчен «Зәй офыклары» газите мөхәррире (Зәй шәһәре) **Глухов Иван Гавриловичка «Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре»** дигән мактаулы исем бирелде.

# Тукайда кунакта

*Тукай музеенда «Мәдәни җомга» газите һәм «Казан утлары» журналы хезмәткәрләре Укытучыларның белемен күтәрү институтында укып йөргән мәктәп директорлары һәм Казандагы мәктәп-гимназияләрнең укучылары белән очрашты. Әлеге очрашуны «Казан утлары»ның проза бүлеге мөдире, язучы Тәүфикъ Әйди һәм «Мәдәни җомга»ның баш мөхәррир урынбасары, шагыйрь Газинур Морат алып барды. Анда шулай ук шагыйрьләр Мөдәррис Әгъләмов, Нияз Акмал, язучы Фәрит Яхин, танылган баянчы һәм композитор Марс Макаров, татарларга кагылышлы чыганакларны өйрәнүче Кытай галиме, профессор Госман Гыйләҗетдин чыгыш ясады.*

# Хәмдүнә кияүгә чыкты

Яраткан җырчыбыз турындагы бу хәбәрне аның яраткан тамашачысы күптән көтә иде. Үзенә тиң насыйп ярны ул үзе дә озак көтте.

Айга, йолдызларга карап, теләк телим, кайдадыр бик еракта миңа пар кеше бардыр, дип әйткәнен ишеткән идек. Сабыр итсә дә, өмет итсә дә ялгызлык халәте Хәмдүнәнең иҗатында, җырларында да яңгырады. Сәхнәләргә балкып чыгып: «Галигә барам әле», — дип җырлый иде дә, юк, бармыйм әле, кыз булып калам әле, дип, зур концерт залларын алкышларга күмдерә иде. Сагыш-моң тулы «Сары чәчәк», әйтерсең лә, бары тик аңа багышланган. Юк, әгәр җыр аңа гына багышланган булса, татар халкының егет-кызларын шулай сагышландырмас, күзләргә яшь китерә алмас иде ул. Шулай да «Сары чәчәк» халык күңеленә Хәмдүнә җыры булып керде. Һәм, ниһаять, менә шул җыр Себер киңлекләренә Флорид исемле егет солтанына барып ирешкән. Аны сискәндереп җибәргән, үзенә чакырган, ашыктырган. Югыйсә, күптән күрешергә, кавышырга тиеш булгандыр алар. Һәр икесе Башкортстанда, күрше районнарда: Хәмдүнә — Борайда, Флорид Балтачта туып-үскән. Менә, Аллаһыга шөкер, озын, урау юллар аша бер-берсен эзләп тапты алар. Бергә яшәлмәгән көннәрнең кадерен белеп, тигез гомер итсеннәр, бәхетле булсыннар, дигән теләктә калабыз.

Ә шимбә, якшәмбе көннәрендә Мәскәүдә Хәмдүнә Тимергалиеваның концерты була. Уңышлы үтсен, ул бит пар канатлы Хәмдүнәбезнең беренче концерты. «Мәдәни җомга» газите үзе чыга башлаган елны тормыш корган парларын кайнар котлый. Афәрин, Хәмдүнә, афәрин, Флорид!

**1 нче биттәге рәсемдә: Татарстанның халык артисткасы Хәмдүнә Тимергалиева.**

**Мидхәт ШАКИРҖАНОВ фотосы.**

# Җырламаган чагы юк

Тамашачыларыбыз җырчы Нурәхмәт Мөхәммәтҗан хакында шулай сөйли. Аның моңлы тавышын бик күпләр үз итеп өлгерде. «Татар җыры-93» халыкара конкурсында катнашып лауреат исеменә лаек булганда ук бу яшь җырчы тамашачыларның игътибарын җәлеп иткән иде. Аннары Нурәхмәт Мөхәммәтҗанның «Яңа исемнәр» дигән III бөтенсоюз һәм «Голоса России» дигән II бөтенрусия халык җырлары конкурсларында катнашуы аны яңа биеклеккә күтәрде.

Нурәхмәт Мөхәммәтҗан концертларын шушы араларда гына Кама аръягы төбәкләрендә — шәһәр һәм районнарда тыңладылар. Әлеге концерт 1-10 ноябрьдә Казан шәһәре мәдәният сарайларында була.

# Мөфтигә җинаять эше кузгатылган

*Татарстан Президенты Минтимер Шәймиев «Интерфакс» агентлыгына биргән интервьюсында, шәкертләр тарафыннан элекке «Мөхәммәдия» мәдрәсәсе бинасының басып алынуын экстремизмның бер чагылышы, дип белдерде. Ул, бу юл белән мәсьәләне хәл итәргә ярамый, диде һәм мөфти Габдулла хәзрәтнең эш-гамәлләрен тәнкыйтьләде.*

*Дини җитәкчеләрнең «шәхси мәнфәгатьләрдән чыгып ясаган» әлеге адымнары «Ислам диненә күләгә төшерә», дип билгеләп үтте Президент.*

*Безгә мәгълүм булганча, Казан шәһәре прокуратурасы Габдулла хәзрәткә каршы җинаять эше кузгаткан.*

# Татарстанлыларга — Мәскәү бүләкләре

Дәүләт алдындагы хезмәтләре һәм күпьеллык намуслы эшләүләре өчен Русия Федерациясе Президентының 1995 ел, 11 октябрь Указы белән бүләкләнделәр:

**IY дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен»** ордены белән

**Коновалов Александр Иванович** — Казан фәнни үзәгенең А.Е.Арбузов исемендәге органик һәм физик химия институты директоры.

**Тарчевский Игорь Анатольевич** — Казан фәнни үзәге президиумы рәисе.

**Дуслык ордены** белән

**Марат Әхсән улы Илһамов** — Казан фәнни үзәгенең механика һәм машина төзелеше институты директоры;

**Почет ордены** белән

**Алемасов Вячеслав Евгеньевич** — Казан фәнни үзәгенең энергетика бүлеге директоры.

**II дәрәҗә «Ватан алдындагы хезмәтләре өчен»** ордены белән

**Анисимов Александр Васильевич** — Казан биология институтының баш фәнни хезмәткәре.

**Анастас Әхмәт улы Бохараев** — Е.К.Завойский исемендәге Казан физика-техника институты гыйльми секретаре.

**Дания Шәүкәт кызы Вәлиева** — Татарстан таможня идарәсенең икътисад бүлеге начальнигы

**Стинский Герман Владимирович** — Казан фәнни үзәгенең энергетика бүлеге директоры урынбасары.

**Федяев Владимир Леонидович** — Казан фәнни үзәгенең механика һәм машина төзелеше директоры урынбасары;

**Роальд Рифгать улы Шаһидуллин** — Казан фәнни үзәгенең А.Е.Арбузов исемендәге органик һәм физик институты лабораториясе мөдире;

**Мөхмүт Шәрәфетдин улы Ягъфәров** — Казан фәнни үзәгенең А.Е.Арбузов исемендәге органик һәм физик химия институтының төп фәнни хезмәткәре;

**«Россия Федерациясенең атказанган фән эшлеклесе»** дигән мактаулы исем бирелде

**Эльвира Салих кызы Батыеваga** — химия фәннәре докторы, профессор, Е.К.Завойский исемендәге органик һәм физик химия институтының лаборатория мөдире;

**Әхәт Вахит улына Ильясовка** — физика-математика фәннәре докторы, профессор, А.Е.Арбузов исемендәге органик һәм физик химия институтының лаборатория мөдире;

**Кессель Александр Рахмиэлевичка** — физика-математика фәннәре докторы, профессор, Е.К.Завойский исемендәге Казан физика-техника институтының лаборатория мөдире;

**Левин Яков Абрамовичка** — химия фәннәре докторы, профессор, А.Е.Арбузов исемендәге органик һәм физик химия институтының лаборатория мөдире;

**Кев Миңнулла улы Салиховка** — физика-математика фәннәре докторы, профессор, Е.К.Завойский исемендәге Казан физика-техника институты директоры;

**Федотов Владимир Дмитриевичка** — физика-математика фәннәре докторы, профессор, Казан биология институты директоры.

## ҖОМГАДАН — ҖОМГАГА

### Җөмһүрият елъязмасына җөмләләр

**Татарстанның Мәскәүдәге вәкаләтле вәкиле Фәрит Мөхәммәтшин Иранның Киш шәһәре мэры Ибраһими әфәндене кабул итте.**

Быел үзенең биш еллыгын билгеләп үтүче Рөстәм Аббязов җитәкчелегендәге «Ла Примажера» камера оркестры ноябрьдә Германиягә барырга җыена һәм шул уңайдан КДУның актлар залында булган кичәдә ул үзенең яңа программасын тәкъдим итте.

**Татарстан Президентының искергән йортларда яшәүче гражданнарның торак шартларын яхшырту турындагы Указы республикада бу мәсьәләне 6-7 елда хәл итүне күздә тота.**

28 октябрьдә Мәскәүдә башланачак Русия композиторларының YII съездында Татарстан Композиторлар берлегеннән 4 делегат катнаша.

**Казанда 30 октябрьдә «Балаларга, яшүсмерләргә, яшьләргә медицина һәм психология ярдәме» дигән темага Русия галимнәре катнашында фәнни-гамәли конференция үзенең эшен башлый.**

Казанда ун мең тираж белән эшкуарлар һәм финанс хезмәткәрләре өчен «Бизнес план» журналы чыга башлады.

**Әгәр сез йөри торган маршрут автобусы вакытында килмичә, барырга тиешле урыныгызга соңга калсагыз, үз дәгъвагызны белдереп, Казандагы 36-06-62 телефоны белән транспорт инспекциясенең җирле бүлекчәсенә шалтырата аласыз.**

Татар-башкорт эстрада тормышында беренче тапкыр буларак, Башкортстанның халык артисты Идрис Газиевның компакт-дискы чыгу уңаеннан 30 октябрьдә Г Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры бинасында таныштыру кичәсе уздырыла.

# Фестиваль — күңелләр ачкычы

Берничә ел элек булды бу. Телевизордан Мәскәү каналларының берсен ачып җибәргән идем, киемнәре белән бөтенләй безнең милләт кешесенә охшамаган өлкән яшьтәге апалар саф татарча җырлыйлар. Бераздан аңлашылды. җырчылар мордва каратайлары икән. Алар Татарстан Республикасының Кама Тамагы районындагы кечкенә генә бер авылда яшиләр. Телевизор аша шушы авылдан Лидия Глонина җитәкчелегендәге «Мордовские узоры» вокаль ансамбле чыгыш ясый булып чыкты.

— Каратай Болгар патшалыгыннан сакланып калган бердәнбер мордва авылы, — диде миңа халык иҗаты буенча республика фәнни-методик үзәге өлкән фәнни хезмәткәре Нәфисә Сәгъбиева. — Аларның гореф-гадәтләре, мәдәниятләре бик тә үзенчәлекле. Каратайларның, мәсәлән, туйлары урысларныкы кебек, ә җырлары татарларныкына якын. Әмма алар хәзер бик аз калып бара. Кама Тамагындагы әлеге совхоз участогында нибары 111 каратай яши.

Мордва халкының борынгыдан килгән тулы бер тармагы, алай гына да түгел, аларның үзенчәлекле теле, сәнгате, иҗаты, җыр-биюләре юкка чыгачак дигән сүз түгелме соң бу? Менә шушы җәүһәрләрне үз вакытында актарып чыгарасы, дөньяга күрсәтәсе һәм саклап каласы иде бит.

Шушы максатны күздә тотып, халык иҗаты буенча республика фәнни-методик үзәге фин-угор халыкларының җырларын башкаручыларның I республика фестивален үткәрә дә инде. Иртәгә К.Тинчурин исемендәге театр бинасында аның йомгаклау концерты була.

Күпмилләтле республикабызда 29 меңгә якын мордва, 19 меңнән артык мари, 25 меңләп удмурт халкы татарлар белән аралашып, иңгә-иң торып, мәдәниятләрен һәм сәнгатьләрен алмашып яши. Әлеге йомгаклау концертында республикабызның 25 район һәм шәһәреннән килгән мари, удмурт, мордва халыкларының үзешчән сәнгатьтә катнашучылары чыгыш ясаячак. Фестивальгә килгән коллективларның күбесе инде республикада дан казанып, танылып өлгергән. Алар арасында Кукмара районында популярлык казанган «Арган», «Инвожо», «Марий ял» фольклор коллективлары, Актаныш районы мариларының «Ший помаш», Минзәлә районының «Мари кас» фольклор ансамбльләре, Тәтеш районының Урюм авылында яшәүче мордваларның фольклор ансамбльләре бар. Фестивальдә шулай ук Чистай, Әлмәт, Чирмешән, Бөгелмә, Лениногорски, Арча, Балтач һәм башка районнардан килгән фольклор һәм эстрада коллективлары катнашачак.

Тамашачылар әлеге фестивальдә Менделеев районы удмуртларының борынгы йолаларга нигезләнеп эшләнгән музыкаль күренешләр әзерләп килгән «Тэремшур», Лениногорскида яшәүче мордваларның фольклор ансамбле «Эрзянка» белән дә кабат очрашырлар.

Гомумән, фестиваль күңелнең бай сандыклары ачкычына, алардагы җәүһәр энҗеләр балкышына, фин-угор халыкларының борынгы халык иҗатын ачып салган күркәм бәйрәмгә әверелер.

**Сөембикә КАШАПОВА.**

# «Үзем турында» үзем

***Татарстан китап нәшрияты сәнгать дөньясы белән кызыксынучылар өчен тагын бер матур бүләк әзерләде. Мәшһүр җырчыбыз Әлфия Афзалованың «Үзем турында» дигән китабын бастырып чыгарды.***

***Татар эстрада сәнгате үсешенә зур өлеш керткән, сәхнә йолдызы Әлфия Афзалованың бу китабы киң катлам укучылар өчен дә кызыклы. Сурәтләү чараларына бай булган китапны җырчы үзенең язучы дуслары ярдәмендә иҗат иткән. Татарстанның халык, Русиянең атказанган артисткасы Әлфия Афзалова үзенең сәхнәдә 45 ел эшләве, дуслары, туганнары турында чын ихласлык белән яза. Ятимлектә үткән балачагы, тырыш хезмәт белән кичергән тормыш юлы турында исендә калганнарын кызыклы хатирәләр итеп сөйли.***

# Исемнәре генә кайтты

*Санкт-Петербургның «Төньяк-Көнбатыш» эзләнү берләшмәсе шәһәр һәм Ленинград өлкәсе буенча үзенең сәүдә-икътисади рәсми вәкиллегенә чыгышлары белән Татарстанныкы һәм милләтләре татар булган дүрт солдатның сөякләре табылуы һәм аларның Бөек Ватан сугышында һәлак булучылар өчен махсус зиратка күмелүе турында хәбәр итте.*

*Һәлак булучыларның сөякләре янында табылган медальоннарда мондый язмалар бар:*

***Госман Галимов,** 1906 елда Казанда туган, армиягә Казан шәһәренең Калинин районы хәрби комиссариатыннан чакырылган.*

*Туганнарыннан Хонар (?) Галимова исеме язылган.*

***Шәриф Зәйнулла улы Зәйнуллин,** 1910 елда Югары Масра авылында туган (Иске Масра авыл советы). Туганнарыннан Рабига исеме күрсәтелгән. Армиягә Арча районы хәрби комиссариаты тарафыннан чакырыла.*

***Гайнул Шайнур улы Галиуллин,** 1913 елда Арча районының Сикертән (медальонда Сакертяк дип язылган) авылында туган.*

*Медальонга туганнарыннан Нурулла Галиуллин исеме теркәлгән.*

***Сәләх Җәләй улы Җәләев,** 1910 елда Арча районы Орнашбаш авылында (Утар Аты авыл советы) туган. Туганнарыннан Гөлсем Җәләева исеме күрсәтелгән.*

*Һәлак булган әлеге 4 татар сугышчысы каберләре янында Санкт-Петербург һәм Русиянең Төньяк-Көнчыгыш төбәге мөфтие Җ.Пончаев алар истәлегенә Коръәннән сүрәләр укырга ризалык бирде.*

*Теләүчеләр «Төньяк-Көнбатыш» берләшмәсенә (Санкт-Петербург шәһәре) түбәндәге телефоннар белән шалтырата алалар:*

*275-71-15 — Ирина Александровна Муравьева,*

*275-75-47 — Александр Павлович Нечаев, Илья Владиславович Дюринский.*

# Җырчыга машина вәгъдә итәләр

Инде гәзитебездә хәбәр ителгәнчә, башкалабызда октябрь ае дәвамында популяр җырчы Айдар Галимовның концертлары барды. Залларның һәрвакыт тулы булуы, хәтта басып торыр урын да калмавы Айдарның татар халкы арасында популярлыгы көннән-көн үсә баруын, аның җырлавын яратуларын тагын бер кат раслады. Айдар халык мәхәббәтен казануга, билгеле, матур тавышлы җырчы булу белән бергә, сәхнәдә һәм тормышта үзен искиткеч тәрбияле, зәвыклы тотуы, тамашачыны хөрмәтли белүе белән дә ирешкәндер.

Соңгы концертларның берсендә Айдар Ульяннан да чакыру алган. Алар, Айдар Ульяновскига килгән очракта, аңа машина вәгъдә итәләр икән.

# Ерактагы кояш ныграк җылыта, күрәсең...

«Комсомольская правда» гәзитеннән мәгълүм булганча, Татарстанның элемтә министры Р.Җәләлов бу гәзиткә язылу мәсьәләсен шәхси җаваплылыгына алган һәм аны тараткан өчен бөяне бер сумга да (!) күтәрмәгән икән. «Мондый хәлне Русия моңарчы белми иде әле», — дип гаҗәпләнеп яза гәзит хәбәрчесе дә.

Кул кулны юа, ике кул битне юа, дигәндәй, «Комсомолка» да бу хәлгә битараф калмый, Татарстанның почта эшчеләрен 250 доллар күләмендә акча һәм «Адидас» костюмнары белән бүләкли.

Әнә бит, элемтә министрының урынбасары Ф.Хәбибуллин да, «Комсомолка» — яраткан гәзитем, аның өчен эшләү файдалы гына түгел, күңелле дә, ди.

Хуш, Мәскәү гәзитләре өчен тырышасыз да ди. Ә бит безнең үз гәзит-журналларыбыз да бар, хөрмәтле элемтә җитәкчеләребез! Ләкин аларның әлегә доллары да, «Адидас» костюмнары да юк бүләк итәргә. Әмма үз татарыбызның матбугатын бар итү, аның да дәрәҗәсен күтәрү безләрнең беренчел бурычы булырга тиештер, дип беләбез.

# Нәшрият киштәсендә ниләр бар

*Икътисади киртәләрне төрле юллар белән җиңә барып, Татарстан китап нәшрияты тел, дин, тарих турындагы һәм дә халкыбызның күренекле әдипләре иҗат иткән матур әдәбият әсәрләрен бастырып чыгара тора. Әйтик, бүген нәшрият киштәсендә «Хәзрәте Рәсүлуллаһ һәм дүрт хәлифә» (Мәҗит Гафури), «Җиз кыңгырау» (Әмирхан Еники), Мөхәммәд Мәһдиев (сайланма әсәрләр, 1 том), «Язылмаган кануннар» (Хуҗи Мәхмүтов), «Мәҗмугыль хикәят» (борынгы татар прозасы), «Тәүбә» (Рахмай Хисмәтулла), «Таң җиле» (Фоат Садриев), «Олуг пәйгамбәр» (Фәрит Яхин), «Уем — тел очымда» (Илдар Низамов), «Исемнәрдә — ил тарихы» (Фирдәвес Гарипова), «Сандугач кунды талларга» (поэзия, башкорт шагыйре Шәриф Биккол), «Бака да бата» (юмор-сатира. Фәнзаман Баттал), «Агымсуда ни булмас» (сатирик роман һәм повестьлар. Зөлфәт Хәким), «Җырлап ачыла күңел» (җыентык) һәм башка күп кенә татарча басмалар. шулай ук тәрҗемә әсәрләр, балалар өчен матур-матур китаплар бар.*

*Татарстаннан читтә яшәүче бик күп милләттәшләребез китап нәшриятына татарча китаплар сорап хат язалар. Әлбәттә, нәшрият һәркемгә берәрләп китап җибәрү вазифасын үз өстенә ала алмый. Шулай да без милләттәшләребез яши торган өлкәләрдә милли китаплар сатылуын теләр идек. Чөнки хәзер һәркайда диярлек татар гимназияләре ачылды, мәчетләр эшли. Димәк, телебезгә, динебезгә кайтучылар сафы да ишәя.*

*Бу китапларны турыдан-туры Татарстан китап нәшриятыннан килеп алырга була. Күпләп алучыларга акча күчерү юлы белән дә эш итәргә мөмкин (Казаннан акчаны — р/с 363901 ТКСБ г.Казани МФО 265016; районнар һәм чит өлкәләрдән — р/с 363901 кор.счет 700161503 в РКЦНБ РТ МФО 265005 исәбенә күчерергә кирәк). Күпләп алып китүчеләр өчен нәшрият китапларны үз транспорты белән дә илтә ала. Төгәлрәк белешмәләрне 32-77-05, 32-68-46 номерлары белән телефоннан сорарга да була.*

# Әгәр мин президент булсам...

**«Азатлык» татар яшьләр берлеге һәм Чаллыда нәшер ителүче «Көмеш кыңгырау» гәзите 9-15 яшьлек укучылар арасында «Әгәр мин президент булсам...» дип аталган бәйге игълан итте. Ул киләсе елның 25 гыйнварына кадәр дәвам итәчәк. Әлеге конкурсның төп максаты татар балаларын ана теленә якынайту, үз Ватаны белән горурлану хисе тәрбияләүдән гыйбарәт. Язмаларда (жанрлар чикләнмәгән) «Әгәр дә мин президент булсам, татар милләтен, татар милли дәүләтен торгызу өчен нәрсә эшләячәкмен» дигән сорауга кыскалыкта — осталык принцибы белән җавап бирелергә тиеш. Кулъязмаларның 10 биттән артмавы шарт. Җиңүчеләрне магнитофон (I урын), «Балалар энциклопедиясе» (II) һәм микрокалькуляторлар (III) көтә. Болардан тыш, 10 кызыксындыру бүләге дә каралган.**

**Язмаларны түбәндәге адрес буенча җибәрергә кирәк: 423805, Чаллы шәһәре, Х.Туфан проспекты, 23 нче йорт, 113 нче бүлмә, «Көмеш кыңгырау» гәзите редакциясе.**

# Шагыйрь бәхәскә чакыра

Илдар ЮЗЕЕВ

## Ни булды сезгә, көйчеләр?

Ни булды сезгә, көйчеләр?
Нигә әле тындыгыз?
Әллә заман авырлыгын
Күтәрәлми сындыгыз?
Әллә инде бу болгавыр
Чорның көен тапмыйсыз?
Әллә инде авыр моңны
Җаныгызда саклыйсыз?
Төзиләр дә җимерәләр,
Коралар да ваталар.
Кораллар һаман аталар...
Хаталар да хаталар...
Сәясәт безнең тормышка
Китермәде куаныч.

Гаделлек тик телдә калды,
Җырда калды юаныч.
Сезнең яралы йөрәккә
Юкка ук атам бугай.
Кыйбламны таптым дигәч,
Мин дә югалтам бугай.
Бер көнлек көйнә сәхнәләр
Кыйммәт бәягә сата.
Җырлап яшисе урынга
Шигырем елап ята.
Тормыш авыр... бик авыр,
дип,
Өметне өзмик әле,
Тормышның югалган көен
Бергәләп эзлик әле...

# Бүләккә... Рудольф Нуриев ботинкалары

*Күптән түгел Мәскәүнең «Пилот» төнге клубында Андрей Бартенев «Бумажное кино» дигән коллекциясен күрсәткәч, ул Рудольф Нуриев киеп йөргән ботинкалар белән бүләкләнгән. Бүләкләүчесе исә — дөнья балеты йолдызы турында язылган китап авторы. Аңа Андрейның чыгышы бик ошаган һәм ул тәэсирләнеп китеп, 1929 елда Америкада тегелгән аклы-каралы штиблетларны бүләк иткән. Ә үз чиратында ул ботинкалар Нуриевка бер джаз музыкантыннан калган булган.*

**Сәхифәләрдә редакциябез журналистлары, авторларыбыз, «Татар-Информ» һәм башка чыганаклар хәбәрләре файдаланылды.**

# Биеклектә кал, Азнакай!..

## Районда татар әдәбияты көннәре гөрләп узды

**Азнакай районын без еш кына «нефть ягы» дип атарга күнеккәнбез. Бу төбәк, иң беренче чиратта, йөгерек юллы, тау-үзәнле, урман күлле бик тә гүзәл як, мул уңыш бирә торган басу-кырлары, һәрвакыт мәдәнияткә тартылучы киң күңелле күркәм кешеләре белән аерылып торган як булыр.**

**Татарстан Язучылар берлеге идарәсе рәисе Ринат Мөхәммәдиев җитәкчелегендә бер төркем каләм ияләре Азнакай районында әдәбият бәйрәме үткәргәндә әлеге төбәкнең гаять үзенчәлекле булуына тагын бер мәртәбә инандылар. Районның бәрәкәтле туфрагында мөхтәрәм әдипләребез Гариф Ахунов, Шәүкәт Галиев, Туфан Миңнуллин, Гөлшат Зәйнашева, Равил Фәйзуллин, Флера Гыйззәтуллина, Фоат Галимуллин, Мәдинә Маликова, Марсель Галиев, Зиннур Мансуров, Фәез Зөлкарнәй, Зиннур Хөснияр, Нәбирә Гыйматдинова, Хәйдәр, Рәмис Әймәт; Әлмәт һәм Азнакай төбәгендә иҗат итүче язучылар Илдус Гыйләҗев, Нур Әхмәдиев, Разим Вәлиуллин, Фәйрүзә Исмәгыйлова, Сәрия Вильданова, шулай ук «Ватаным Татарстан» гәзитенең бүлек мөдире Асия Юнысова, Татарстан телевидениесе редакторы Эльмира Хамматова һ.б.ларны зарыгып көтелгән кунаклардай итеп зурладылар.**

**Татар әдәбияты көннәрендә катнашучыларны Азнакай районы һәм шәһәре хакимияте башлыгы Әнәс Исхаков олылап каршылады, төбәкнең символына әверелгән табигать һәйкәле Чатыр тау түбәсенә алып менде, шулай ук күп кенә очрашуларга озатып йөрде, үзенең дә җиргә, кешеләргә, мәдәнияткә гашыйк шигъри җанлы җитәкче булуын кунаклар алдында бөтен тулылыгы белән янә бер раслады.**

**Кунаклар Азнакай шәһәре белән танышып, тиздән сафка басачак мәчеттә булдылар, район үзәгендәге 1 нче мәктәп-гимназиядә, ятимнәр интернат-мәктәбендә, төрле предприятие һәм оешмаларда, Техниклар мәдәнияте сараенда үткәрелгән очрашуларда катнаштылар. Икенче көнне каләм ияләре, аерым төркемнәргә бүленеп, Әсәй, Уразай, Тымытык, Урманай, Әлкәй авылларында әдәбият сөючеләр, игенче-терлекчеләр, укытучылар, мәктәп балалары белән очраштылар, авыл үзешчәннәре белән бергәләп, әдәби-музыкаль кичәләр үткәрделәр.**

**Татар әдәбияты көннәре азнакайлар өчен дә, бәйрәмгә кунак булып килгән каләм ияләре өчен дә онытылмаслык вакыйга буларак хәтергә уелып калды.**

Марсель ГАЛИЕВ

## Чатыр тау җиле

**(Сәҗдә кылу)**

Исәнме, мәгърур тау!

Туган як тәхете — Чатыр тау, исәнме...

Туган елың кайчан — аны белү мөһим түгелдер, әмма гомерең җир гомеренә бәрабәр. Бакый заманда дәһшәтле боз катламнары аша мамонтларның соңгы күз карашын хәтереңә сеңдереп калыккансың да, бүген инде Азнакай төбәгенең йөзек кашы булып, күпме күңелләрне әсир иткәнсең.

Янындагы дулкын-дулкын тауларга басып, меник әле синең иярең.

И бу җиһанның гадел минутлары!..
И бу җанның убылыр упкыннары...

Табигатьнең тибрәнешенә тәңгәл килер мизгелне кабул итеп алыр өчен шушындый лаек биеклек кирәк икән. Кочагында — рәшә сулышыннан хозурланган җир Бу кодрәт каршында үзеңнең бик кечкенә зат икәнеңне беләсең, әмма тау. үз биеклеге белән исертеп, сиңа сиздермичә генә олылау хисе, юаныч бирә, күңел дөньяңның чиге офык сызыгына тоташа да йөрәгең тау йөрәге белән бер аһәңдә тибә башлый.

Ә җиле... Чатыр тау җиле юксынып, үз кагына кеше менгәнне ярата, зарыгып көткән була уйнаклап килеп кочаклап ала да. шатлыгыннан әле җылый, әле көлә, аннары үләннәр өстендә мәтәлчек ата билеңнән алып көрмәкләшә аягыңа сөт тешпе көчек булып сарыла, суык борынлы песи булып куенына керә, сабый булып чәчеңә үрелә Юк, мондый җил, мондый да саф. эчкерсез мәҗүси җил бүтән беркайда да исми, валлаһи исми.

Тау артында таулар бар, дигәнгә мин юл йөреп, үз күзләрем белән күреп ышандым Җил-Су-Кояш берсеннән-берсе гүзәлрәк манзаралар тудырган икән якынайган саен ерагая барган кар чалмалы Кавказ сыртлары дисеңме, канлы язмышлар шаһиты — Кырым дагпары дисеңме, Пиреней ярымутравында, Андалусия тауларындагы мәрмәр күкрәкле Сьерра Невада оркачләре дисеңме, самолет канаты астыннан үрелеп калган Альп кыялары дисеңме — болар һәммәсе дә кешедән өстен горурлыкта, хәтәр упкыннар сагында...

Ә Чатыр тау башка...Идел-йортыбызның иң биек түбәсе саналса да, иңенә ятып еларлык яшел мендәр дә ул, рухыңа көч өстәрлек мәгърур биеклек тә ул, балачакка кайтара алган җил иярә дә ул.

Түбәсендә кылганнар йөгергән Чатыр тауга менеп син тарихны уятасың. Кара диңгез ярындагы Чатыр даг белән Урал бусагасындагы Чатыр тау — табигатьнең игезәкләре, иксез-чиксез киңлекләрне биләгән төрки-татар мәмләкәтенең тере маяклары...

Хушлашыр алдыннан, күңел догаңны укы да, иелеп, тауны бер сыйпап ал. Күпне күргән олпат таупар да юатуга мохтаҗ...



● Чатыр тау — Азнакай төбәгенең йөзек кашы — табигать һәйкәле.

Ераклашкач, Чатыр тауга соңгы тапкыр борылып кара. Олы юлга чыкканда капка төбендә озатып калган әниеңә дә шулай бер генә тапкыр борылып, кул болгый идең бит Күз яшеңне күрсәтмәс өчен...

Һәр хушлашуда «бәлки бу соңгысыдыр» дигән бәхилләшү төсмере бар Безгә бу турыда оныту бәхете бирелгән, соңыннан үкенү өчен

Ә син, Чатыр тау җиле яшеннәр оясын гуздырып уйна шулай без кешеләр дәрәҗәсенә төшә күрмә, илаһи биеклектә кал!

Ярабби

### Котлыйбыз!

*Дәүләт алдындагы хезмәтләре һәм күп еллар дәвамында намуслы эшләве өчен Русия Федерациясе Президентының 1995 ел, 11 октябрь Указы белән Азнакай районы һәм шәһәре хакимияте башлыгы ӘНӘС ГОТЫФ улы ИСХАКОВ Дуслык ордены белән бүләкләнде.*

**Мәдинә МАЛИКОВА,**
язучы, Бөтентатар Кызыл Ай җәмгыяте президенты

## Игелек иткән юлда калмас

Язучылар белән очрашу вакытында Азнакай районы һәм шәһәре хакимияте башлыгы Әнәс Готыф улы Исхаков минем хакта:

— Мәдинә апа безнең үз кешебез булып бетте инде, әйтергә мөмкин. Азнакайга пропискага керде. — диде

Әйе, соңгы ике елда мин Азнакай юлына тузан кундырмыйм. Бөтентатар Кызыл Ай җәмгыятенең президенты итеп сайланганнан бирле. күңелем гел шул тарафка ашкынып тора. Мин Азнакайның үз кешесенә генә түгел, мәктәбенең укучысына ук әйләнеп киттем кебек. Хикмәт шунда ки, безнең җәмгыятьнең эше — моңарчы күрелмәгән яңа эш, минем кебек гомерен өстәл артында уздырган язучыга шәфкать җәмгыятен җитәкләү авыррак бирелә. Тәҗрибә, акыл җитми, күз күреме тар, алдагы эшләрне барлап бетереп булмый. Һәр эшнең хикмәте бар диләр, шәфкать юлында да наданлык белән ерак китеп булмый!

Мин үземә бик кирәк тәҗрибәне, олы сабакны Азнакай хакимияте башлыгы урынбасары Суфия Кашап кызы Ямалиевада таптым. Гомерен мохтаҗларга ярдәм итүгә, аларның тормыш шартларын аз гына булса да җиңеләйтүгә багышлаган Суфия ханым минем хәлемне дә аңлады, үз-якын итте. Аның белән кара-каршы утырып, сәгатьләр буе сөйләшкәннән соң минем күзләрем күп нәрсәгә ачылды, барыр юллар ачыкланды. Шуның нәтиҗәсендә Азнакайга һәр баруымда мин ятимнәргә, гариплөргә, ялгыз-хәлсезләргә ярдәм итү өчен шактый күчтәнәчләр алып кайтам. Карабодай ярмасы, һинд чәе, өр-яңа кием-салым..

Азнакай районы быелгы авыр елда да яхшы уңыш җыеп алды Сентябрь аенда мин хакимият башлыгы Әнәс Исхаков кабинетына кергән идем.

— Без сезнең җәмгыятькә ун тонналап бодай илтербез, соңрак карабодай да бирербез. — диде ул.

Минем тыным кысылып куйды Дөрес, кайсы гына район хакимияте башлыгына мөрәҗәгать итсәм дә, үтенечемне аяк астына салмыйлар Унар тонна бөрөңге, яшелчә бирүчеләр бар Рәхмәт аларга. Әмма ун тонна бодай, аннан да бигрәк карабодай җибәрү башкалардан аерылыбрак тора Хәзерге заманда шикәр чире киң таралган, бездә исәптә торучылары да шактый Алар өчен карабодай ярмасы ризык кына түгел, дару да!

Казанга кайту белән мин ул хасталарны өметләндереп куйдым быел да була ярма, була, дидем Сарман районында Азнакай карабодаен ярып бирәчәкләр, анысын да сөйләшеп куйдык

Бодайны исә Балык Бистәсе районының Яңа Арыш авылы тегермәнендә тартып бирергә ризалаштылар Азнакай районының Ялантау күмәк хуҗалыгы рәисе Хәмит Мөстәкыймов җибәргән «КамАЗ» машинасын без шунда бушаттык.

Шулай итеп, безнең Кызыл Аебыз төрле районнарда яшәүче һәм эшләүче игелек ияләрен изге гамәлдә берләштерде

28 октябрьдә Азнакай районы Казанның Чехов базарында ярминкә үткәрәчәк Районда бу ярминкәгә бик нык әзерләнеп киләләр, чагыштырмача арзан бәягә азык-төлек, тормыш кирәк-яраклары сатылачак. Фәкыйрьләр дә онытылмаган — түләүсез ашату оештырыла.

Дөрес, ярминкәне чын бәйрәм төсендә үткәрү өчен һәр район тырыша. Әмма азнакайлар бу эшкә дә яңалык керттеләр: планда, Кызыл Ай җәмгыяте белән бергәләп, урын өстендә ятучыларга, өеннән чыга алмаучыларга ярдәм итү дә каралган Андыйлар моңа кадәр ярминкә-бәйрәмнәрнең ятимнәре булып килделәр бит Бу юнәлештә район җитәкчеләре белән хезмәттәшлек итү юлын без күптәннән эзлибез Мамадыш, Буа кешеләре минем базарларда тыз-быз чабып йөргәнемне хәтерлиләрдер Кызганыч, моңарчы без бу өлкәдә бергә эшләүнең әмәлен таба алмаган идек.

Суфия ханым моның да юлын тапты — бу көннәрдә без Азнакай планы белән эшлибез. 28 октябрьдә барыбыз да үз урынында булачак. ике машинабыз туктаусыз йөреп торачак Республикада иң яхшы саналган Азнакай бодаеннан тартылган он, шул оннан пешерелгән күмәчне. шулай ук ярманы өеннән чыга алмаган мохтаҗларга илтеп бирергә ниятлибез. Алар да халыкның бер кыйпылчыгы, Азнакай ярминкәсендә ятим булмаслар Шуңа өстәп бәрәңге дә бирербез — Азнакайдан үрнәк алып. Баулы районы үз машинасы белән безгә 6 тонна бәрәңге китерде Рәхмәт яусын Баулы район хакимияте башлыгы Наил Шамил улы Зариповка һәм «Ленин юлы» колхозы рәисе Айдар Әнүрбәк улы Гафуровка.

Әйе, Азнакай ярминкәсе Казан кешеләренең күбесе өчен күңелле узар шактый мохтаҗларга да күпмедер җиңеллек китерер Һәм Кызыл Айны да югарырак күтәрергә хезмәт итәр

Хуш киләсез Казанга, азнакайлар!

**Шәүкәт ГАЛИЕВ,**
Татарстанның халык шагыйре

## Азнакайлар, әллә кайлар...

*Җырлый идек яшь чакларда*
*«Китәм Азнакайларга,*
*Азнакайлар, әллә кайлар,*
*Китәм әллә кайларга!»*

*Ашкына иде йөрәкләр*
*Еракка юл алырга —*
*Баш ташлап авыр еллардан*
*Китәргә, югалырга..*

*Тынгысыз татар. аптырап,*
*Гел урын алмаштырган,*
*Офыклар артында, имеш,*
*Нужасын адаштырган...*

*Кай тарафка омтылсаң да,*
*Дөнья бит ул түгәрәк —*
*Сагышлар белән әвәләп.*
*Йөрткән язмыш-дүңгәләк*

*«Китә казлар Донбасска » дип.*
*Бу яктан да киткәннәр*
*Читтән эзләгән бәхет ул*
*Туган җирдә икән лә*

*Яшьлектәге җыр эзеннән*
*Килдек Азнакайларга.*
*Азнакайлар ерак түгел*
*Яшьлек — әллә кайларда*

*Очрашулар аңлашулар*
*Онытылмас гомергә*
*Сагындырган көннәр белән*
*Бик якын сез күңелгә!*

***Хөрмәтле казанлылар, башкалабыз кунаклары!***

*Бүген 19 сәгатьтә К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театрында Азнакай сәхнә йолдызларының зур концерты була. Ә иртәгә иртүк Чехов базарында ярминкә ачыла. Килегез. азнакайларның талантларга бай булуын, уңганлыгын, кунакчыллыгын үзегез үк күрерсез.*

Мөнәсәбәт

# Чүрәкәй дигән нәни кош...

Русия Федерациясендәге милли республикаларда җитәкче урыннарга дуңгыз каплату серләрен яисә трактор төзелешен аңлау дәрәҗәсенә ирешкән кешеләрне кую элек-электән гадәти хәл булып санала. Әйе, торгынлык елларында да шулай булды. хәзер дә һичбер үзгәреш юк Минем уйлавымча. бу урыс булмаган халыкларны, иң беренче нәүбәттә, татарларны мал-туар көтүе дәрәҗәсенә төшерү максатында эшләнә. Әлбәттә. Мәскәү Татарстандагы һәр кәнәфигә кандидатура эзләп азапланмый. Моның өчен югарырак урынга ике-өч ялагайны утырту да җитә. Калганын инде әнә шул җитәкчеләр башкарып чыга.

... Авыл халкы бер караңгыдан икенче караңгыга кадәр бил бөгә, хакимият башында утыручылар исә илен, ил байлыгын имә, халыкка вакытында хезмәт хакы түләмәүне замана авырлыкларына сылтый. Колхоз рәисләре хезмәт хакын чикләүсез түләү мөмкинлеге булган Брежнев чорында да үз милләттәшләренең хезмәтен тишек тиеннәр белән генә бәяләп, әрмән шабашчыларына ачыктан-ачык меңнәрчә сум акча түлиләр иде Бу хәзер дә шулай. Әлбәттә, шабашчылар рәисләрне дә өлешсез калдырмаганнардыр Район хуҗалары да аларны һәрвакыт яратты, татар авылы уңганнарына дип кайтартылган санаулы җиңел машиналарны өләшкәндә дә аларны онытмадылар.

Чүрәкәй дигән нәни үрдәк, моңа үзе сәбәпче булуын да аңламыйча, бусы исләнде дип, икенче күлне эзләп китә, имеш. Түрәләребез дә шундый: аз гына җай чыктымы, безнең халык көнче, берсе күтәрелсә, икенчесе аягыннан тарта, фәлән-фәсмәтән, дип зарланырга керешәләр. Юкса, алар үзләре үк халыкның рухын имгәтә бит. Көнче кешеләр һәр халыкта да бар. Андыйлар эчә дә, сугыша да, ызгыша да белә. Безнең түрәләр халыкны сукбай, хәерче хәлендә калдыру максатында эшләүгә программалаштырылган кебек. Шуңа күрә дә милләтне милләт итә торган өлкәләр җан асрарлык дәрәҗәдә генә финанслана, коры саламга калдырыла. Әйтик, музыкада Ростәм Яхинны кайсыдыр хуҗалык җитәкчесе алмаштыра... Милләтебез мәдәниятенең якты йолдызы — Татарстанның җыр һәм бию ансамбле күпме еллар бинасыз, эт типкесендә яши. Ленинградта узган Сабан туенда марҗа әбиләре ансамбле катнашуы гына да әлеге фикернең хаклыгын раслый. Ә җыр-бию ансамбленә бина бирү мәсьәләсен республикада төзелеп яткан дуңгыз комплексларының берсен киметеп тә хәл итеп булыр иде, югыйсә.

Аһ бу дуңгызларны! БТИҮ корылтаенда Сабадан килгән делегат Илдар Яхин Татарстанда дуңгызчылык тармагына мораторий игълан итәргә кирәклеген әйтеп чыгыш ясаган иде. Чыгышы басылмаса да, татар матбугаты аны тәнкыйтьләргә керешә. Юкса, һәркемгә мәгълүм: татар өчен чучка асрау иң пүчтәк, иң хурлыклы эш бит. «Да, парин, чучкалар карыйм, хатын да шунда, ыштанын ямыйм», — дигән шигырь дә бар бу турыда.

**Ростәм ЗАРИФ.**
Шәмәрдән бистәсе.

Мөнәсәбәт

# Грачев — министр, әти һәм ...

Дөнья әлмисактан бирле шулай яратылган инде: тормыш-яшәеш киңлегендә гавам — гади халык та, түрәләр — власть башында утыручылар да һәркайсы үзләренчә яшәп ята. Халык ифрат күп, җитәкчеләр исә санаулы гына. Шушы ике катлам арасында күрер күзгә бәрелеп тормаган шактый аерма посып ята. Бу, әлбәттә, зур тема. Мин исә бу очракта мәсьәләнең бер генә кылына — хәрби хәлләргә кагылып узмакчы булам.

Һәркем хәтерлидер: Русия, өч ел буе битараф кына кашынып утырды-утырды да, узган елның декабрендә кинәт кенә Чечнстанга ташкындай гаскәр белән бәреп керде. Фронтның алгы сызыгына, билгесез сугышка кемнәр китте соң? Милләтен аерып тормастан әйтик: Русиядә туып-үскән христиан һәм мөселман кавемнәреннән булган 18-20 яшьлек бер гөнаһсыз, тәҗрибәсез. ак-караны юньләп аермаган яп-яшь егетләр. Аерым казаннан эре калҗа ашап үскән элита гаскәрләре исә Кремльне, президент һәм хөкүмәт даирәсен саклый — монысын аңларга да була әле. Русия оборона министры Павел Грачевның бер әңгәмәдә биргән җавабында, минем үз улым да офицер, армиядә хезмәт итә, дигәнрәк сүзләре хәтердә калган. Ельцинның да кияүләре, оныклары, тагын-тагын әллә нинди туганнарының барлыгы мәгълүм. Әмма, кемдер әйтмешли, ашар-эчәр сулары бүтән, алар бит беркайчан һәм һичкайчан сугышларның утлы сызыгына барып кермәячәкләр. Соңгы ун елда җәмгыятебездә байтак үзгәрешләр булды. «Перестройка» дулкынында оешып, яшь буржуйлар — бизнесменнар, эшкуарлар, сәүдәгәрләр буыны ныклап аякка басты. Аларның бер ишен, гадәттә, мафия дип кенә атыйлар. Боларның баласы да армиягә яисә кайнар нокталарга барып керәме соң? Юк, әлбәттә. Комиссариат чиновникларына берничә «лимон» ришвәтне төртәләр дә, шуның белән мәсьәләне хәл итәләр — вәссәлам...

Чират кемгә кала? Әлеге дә баягы, гади халык һәм аларның бетмәс-төкәнмәс уллары яшәсен! Кремль сәясәтчеләре үзләренең намуссыз, әхлаксыз гамәлләрен яшь буын җилкәсенә бик ансат кына күчереп куялар. Ядрә, снаряд, хәвеф астына көтүе-көтүе белән яшь егетләрне куып кына торалар. Инде Әфганстанда тулы бер буын яшьләр амбицияле сәясәтчеләр корбаны булган иде. Иген игәсе, йортлар саласы, бала-чага үстерергә тиешле күпме яшьләр ул чакта да әнә шулай утлы мәхшәр уртасына ыргытылды... Юк шул, империячел түрәләр тарихтан сабак ала белмиләр икән.

Бүген Русиядәге миллионлаган ата-аналар борчулы: хәлдә яши. Алар армиядәге яисә армиягә алыначак улларының язмышлары өчен хәвефләнәләр. Андый борчу безнең гаиләдә дә бар. 19 яшьлек улыбыз — студент. Мондый да әхлаксыз, сәяси тотанаксыз булган армия сафларына бер дә җибәрәсебез килми аны.

Мин үзем — запастагы капитан, хәрби әзерлегем җитәрлек дип саныйм. Чечен Республикасының азатлыгын яклап, бүген үк сугышка китеп барыр идем. Ләкин бер нәрсәдән куркам: Михаил Шолоховның «Миң» дигән хикәясендә (әсәрдә гражданнар сугышы вакытында аклар ягындагы әти кешенең кызыллар ягыннан сугышучы үз улын танымыйча атып үтерүе тасвирлана), миңа да 19 яшьлек улым, аның яшьтәшләре, ә бәлки милләттәш егетләр белән мылтыкка-мылтык очрашырга туры килсә, нишләргә? Шовинист түрәләр чит куллар белән утлы күмер чүпләргә бик осталар бит! Гомер ишетмәгән «федераль гаскәрләр» дигән гыйбарәне дә бик оста гына худка җибәрә белде алар. Татарстан егетләре әле һаман да Русия армиясенә алына, сугышка китә тора. Бу җәһәттән суверенитет игълан итүебезнең дә ярдәме тимәде. Теге чакта, гражданнар сугышы елларында, Урта Азия басмачыларын (кем «басмачы» булгандыр бит әле!) татар-мөселман кулы белән бастырдылар. Ә хәзер үзбәкләрнең безгә яшерен генә кинәя саклап йөрүләре гаҗәпмени?

Министр Грачев та — кеше, ул да улын, һичшиксез, яратадыр. Ә менә газиз балалары Кавказ мәхшәренә эләккән ата-аналарның кайгы-хәсрәтен аңлармы, сугышны туктату өчен тырышлык күрсәтерме ул? Җавап бирү читен.

Халыкның аһ-зарын хәзергә Русия аңламый, аңларга теләми дә шикелле.

**Рәшат НИЗАМИЕВ.**

Мөнәсәбәт

# Хөрәсән ялкавы хәер эсти

Турысын әйтик, арабызда хәзер хәерчеләр дә шактый. Әмма аларны халык дип тә, сыйныф дип тә атап булмый.

Мисалга эшсезләрне генә алыйк Казан каласында эш муеннан. Кай тарафка күз салма, йөк төяүчеләр, кибетчеләр, баш бухгалтерлар кирәк. Тик хәзер көннәр буе чәй эчеп яисә тәмәке тартып утыра торган эш урынын табу иллә дә нык кыенлашты Хәтта түрәләр дә эшләмичә тамак туйдыра алмаган заман килеп җитте

Эшсезләрне ике төркемгә бүләргә мөмкин. Беренче төркемгә айлар буе хезмәт хакы ала алмаучы, шуңа да карамастан, стажларын тутырып. соңыннан яхшы гына пенсия акчасы алырга теләүчеләрне кертергә мөмкин Ә бу вакытта күршедәге цехта чын эшсөярләр чын продукция җитештерә һәм алар тормыштан һич тә зарланмый.

Икенче төркемгә исә социализм чорында ук эшсезлеккә күнеккән кешеләр керә Дөрес, алар бер дә тик тормыйлар. Кайсы чүплектә берәр нәрсәне сүтеп, «бет» базарына чаба, кайсы тегендә-монда йөк төяп тамак туйдыра. Әмма андыйларның күпчелеге эш урыны белән тәэмин итү хезмәте тирәсендә чуала. Үз һөнәрләре буенча эш таба алмагач, аларга вакытыннан алда пенсиягә чыгарга тәкъдим итүләре дә бар ич. Һәм ул эшлексезләргә шул гына кирәк тә.

Җимерек өйләрдә яшәүче кешеләр турында да берничә сүз әйтеп узасы килә. Тырышкан очракта, социализм чорында да йорт салып чыгарга була иде.

1979 елда трамвай-троллейбус идарәсенә эшкә урнашканда, миңа кадрлар бүлегендә шундый сорау биргәннәр иде:

— Кооператив йорт төзергә теләмисезме?

— Төзеп булыр дип уйлыйсызмыни,— мәйтәм.

— Теләге булган кешеләрне туплап бетерүгә үк төзергә тотынабыз, — дип җавап бирделәр.

Хәер, Казан ТТУсы гынамыни. Теләгең булса, Мәскәүдә дә салырга була йортны. Рәхим ит, Метрострой сиңа һәрвакыт булышырга әзер. Эшләргә теләге булган кеше беркайда да югалып калмый. Зур-зур шәһәрләр кемнәр хисабына үсте, зурайды, дип уйлыйсыз? Нәкъ менә шундый кешеләр хисабына инде. Ә бетле, кандалалы фатирларда яшәүче шәһәр ялкаулары ни эшләде? Кыл да кыймылдатмадылар. Дөрес, алар арасында да тырыш кешеләр булгалады. Мин әле хәзер дә шул җимерек фатирларында яшәп ятучыларны күздә тотам.

Физик яктан гына түгел, акыл һәм зиһен ягыннан да ялкауланган бәндәләр дә бар дөньяда. Бер әбинең кызына эш урыныннан фатир тәкъдим иттеләр. Әмма ул үзе яши торган ике катлы агач йортның беренче катын артыграк күрде булса кирәк, беркая да бармыйм, дип киресен тукыды. Ник дигәндә, суны үзе ташымый, мичкә дә ул якмый. Ә инде кызы, ичмасам, барып карап кайт, дип үгетли башлагач, теге риза булды. Кайнар сулы ваннадан чыгасы килмәде әбинең. Әйберләрен иске фатирдан күчереп бетергәнче чыкмады судан.

Хәзер инде эш сөймәүчеләр турында сөйләшүгә кайтыйк. Казансу буендагы йортларның берсендә күп балалы гаилә яшәде: бер малай, дүрт кыз. Әтиләре бик тырыш кеше иде. Малайлары өйләнде, кызлары кияүгә чыкты. Һәм килен кеше каенсеңелләрен артыксына башлады. Ниһаять, каенсеңелләр ирләре белән акрын-акрын гына кайсы кая китеп бардылар, бер дигән йортлар салып чыктылар. Фронтта булган әти кешегә дә фатир бирделәр. Малай белән килен бер дигән йортта утырып калдылар. Яшә дә яшә генә инде — юк шул, яшәргә теләмәделәр, каралты-кура җимерек хәлдә калды, бакчада әрем үсте.

Йортсызлар да кызгандырмый мине. Аларның күпчелеге табигате белән сукбай бәндәләр. Әллә нинди зиннәтле патша сараена кертеп утыртсаң да, алар адәм заты кыяфәтенә керә алмаячак. Үз йортың булгач, эшләргә кирәк бит. Кайсы, зур акчалы булырга теләп, фатирын саткан, кайсы, эшнең рәтен белмәгән башы белән сәүдә итәргә алынып, әҗәткә үзенең фатирын биреп торган... Өйдән куылган ир-ат яисә хатын-кыз турындагы сүзгә дә ышанмагыз. Барысы да чеп-чи ялган. Әйтерсең, бездә торак йортны бүләшер өчен халык судлары юк. Алимент түләмәс өчен, шул акчага рәхәтләнеп аракы эчү өчен чыгып кача андыйлар. Һаман да шул комсызлык галәмәте.

Инвалидларга килсәк, аларның хәле авыр. Ходай язмасын гарип булырга. Култык таягына таянган яп-яшь егет хәер эстәп кулын сузганда, Космонавтлар урамында яшәүче Валя Чурбанов күз алдыма килеп баса. Фронттан ике аяксыз кайткан ул. Тормышны башлап җибәргәндә, ике урындык та сыймый торган бер бүлмәсе булган аның. Шунда хатыны белән бер кыз, бер малай үстергәннәр. Әмма ул урамга хәер сорарга чыгып китмәгән. Итекче һөнәрен өйрәнеп, көне-төне эшләгән. Хәзер менә Космонавтлар урамында шәп кенә фатиры бар. Гомере буе аракы эчмәде, хәтта башкаларга әҗәткә акча да бирә иде.

Нишлисең бит, эшлексезлек җитә адәм башына. Дөрес, без иске алган кешеләр арасында кем дә булса тарафыннан алданып, рәнҗетелгән кешеләр дә шактый. Үзенең киләчәге өчен көрәшергә теләмәгән андый бәндәләрне дә хөрмәт итмим мин. Рухи яктан ярлы, ихтыярсыз кеше генә үз язмышын үзгәртә алмый.

**Александр ПАУШКИН.**
Казан.

# Татар теле

Ыргыттылар — төшеп ярылмадым,
Изсәләр дә изелеп бетмәдем.
Чит иманнар оҗмах вәгъдә иттә,
Татар тәмугыннан китмәдем.

Һәр халыкның теле бер генә ич,
Телсез калса, татар кем булыр?
Бу хурлыкка түзми, күпә-көндез
Зәңгәр күктән йолдыз егылыр.

Болгар каберләре телгә килеп:
— Хыянәт бу, хурлык, — диячәк.
Кол Галиләр, мәшһүр Сараилар
Әле тагын бер кат үләчәк!

Туасылар тумый калачаклар,
Яралгылар хәтта оялыр.
Теле бетсә, үзен татар, диеп
Әйтә алырлардан кем калыр?

Шуңа күрә мине саклагыз сез,
Намус саклагандай саклагыз.
«Поганый», дип, юк-юк, әйттермәгез,
Кылыч тотып хәтта яклагыз!

Кирәк икән, чыгып рельсларга
Синең белән бергә ятармын.
И син, Хуҗам — гафил һәм ваемсыз,
Каһәрләнгән газиз татарым!

**28 сентябрь, 1995 ел.**

# Иртәнге дога

И раббым!
Рәхмәт, бүген дә
Кояшымны күрдем.
Сөйгәнемнең керфекләрен
Таң җиленә төрдем.

Мең разый, исән дусларым,
Тыныч җирем, күгем.
Өстемә алыр хәлдә мин
Дөньябызның йөген.

Әткәем укый намазын —
Туган нигез исән!
Теләм корсын ятимнәрдән,
Гарипләрдән көлсәм.

И раббым, сулар агышын,
Кош сайравын тыңлыйм.
Зәңгәр күкләргә сокланып,
Ышанычыгыз, туймыйм!

Балаларым, оныкларым
Бар да исән-имин.
Җирдәге һәммә кешегә:
— Бәхетле бул! — дим мин.

**20 апрель, 1995 ел.**

# Язгы ташу

Шушы чыкмаган җанымның
Яз җитүгә ярсуы!
Гүя, минем тамырларда
Кайнап торган кар суы.

Ашкына ерак диңгезгә,
Белмим, ник адарына.
Ышана микән суларның
Шулай гел агарына?

Ышана микән кояшның
Гел шулай карарына.
(Бәхетнең поты бер тиен
Читләрнең базарында).

Читтә кояш җылырактыр,
Бәхет тулырак сыман...
Утырам кичке эңгердә
Күзем алалмый судан.

Ага ташу, ургый сулар,
Сылана ярга күбек.
Узышлый, гаярь дулкыннар
Китә хәлемне белеп.

Кыяр-кыймас кояш байый,
Юашлана җилләре.
Кар сулары булып ага
Гомерем мизгелләре.

**19 сентябрь, 1995 ел.**

**Нур ӘХМӘДИЕВ**

# Саташу

Кинәт җылытып җибәрде,
Юлда су, гөрләвекләр.
Мәхәббәт туе ясыйлар
Урамга сыймас этләр.

Саташты бугай каргалар:
— Яз! — диде, тамчы күреп.
Кышның яртысы узмаган,
Өстә — тун, башта — бүрек.

Ә без каргадан артыкмы:
Кулларга богау киеп,
Дөньяга сөрән салабыз,
Бәйсезлек килде, диеп.

Һәм ышанырга телибез
Кол түгел дип җаныбыз.
Акны карадан аермый
Имгәтелгән аңыбыз.

**19 март, 1995 ел.**

# Ике чик

Назлар хәтәр.
Шул назлардан инде
Чак-чак кына исән калынган.
Ни өчен соң, белмим, мәхәббәткә
Сөю, нәфрәт бергә салынган?

Иркәләгән чакта — җиде күктә,
Җитәр, гукта, төшик күкләрдән.
Мәхәббәт күк тагын нинди көч бар
Йолдызлардан биек күтәргән?

Яратулар — давыл,
Ачу, үпкә —
Диңгезләрдә туган цунами.
Мескен йөрәк ничек гуктап калмый,
Үпкә томалана — суламый.

Бер мизгелдә бар да юкка чыга,
Изге хисләреңне ут ала;



Диңгезләрнең асты өскә килә,
Җирләр, күкләр бергә бутала.

Мәхәббәтне ачу басып китә,
Хисләр челпәрәмә, төн утта.
Гомер уза, уза ике чиктә:
Әле оҗмах, әле тәмугта.

**22 сентябрь, 1995 ел.**

# Гади дә син, серле дә син

Белмим, ничек сизми калганмындыр
Кергәнеңне күңел түренә.
Сине искә төшерү дә җитә —
Якты хискә күңел төренә.

Туганчы ук беләм кебек сине,
Беренче кат күргән сыман да.
Гаҗәпләнәм нәни бер йөрәккә
Шулкадәрле сөю сыйганга.

Хакыйкать күк артык гади дә син,
Аңлап җитә алмас серле дә.
Күргән минутымнан Мәҗнүнең мин,
Карамыйча сөям бернигә.
Чөнки син бит...
син бит — бер генә!

* * *

Кулларым төштө салынып,
Сыгылды аякларым.
Ашкынып барган җиремнән
Югалды маякларым.

Көндезен сүнде кояшым,
Каплады җирне зольмәт.
Ымсынып багам күкләргә
Хет берәр йолдыз эзләп.

Кайда ул! Хәтта чыра юк —
Бөрелдем болытларга.
Юлны дәвам итәргәме,
Йә тиешме йокларга?

Буталды агы, карасы,
Бу соң әллә кабермә?
Кайларга илтеп дәвалыйм
Кан саркыган бәгырьне?

Кай яктан офык ачыла,
Кай яктан иңә нурлар?
... Яралы җан төпкеленнән
Туа кояшлы җырлар.

**19 март, 1995 ел.**

# Татарым

Син чыгарган газны ягып яткан,
Аурупалар күптән рәхәттә.
Ә син үзең, үшән алашадай,
Риза булып йөрдең рәхмәткә.

Урманнардан урлап чыбык яктың,
Салам яктың, яктың кизәген.
Тирес сукты —
Мөнбәрләргә менеп,
«Социализм», диеп сөйләдең.

И бәркатлы минем нарасыем,
И беркатлы газиз татарым,
Дөнья базарында син бүген дә
Бер товары алыпсатарның.

**15 ноябрь, 1994 ел.**

# Язмышым

Чоңгылланып агып ята гомер,
Борылмалар саен — тугае.
Агымында ялтыр чабак уйный —
Минем малай чагым бугай ул.

Чоңгыллары — хәвеф,
Агымнары җитез,
Тугайлары, ай-һай, тирәндер!
Хак Тәгалә үзе раслап миңа
Шушы язмышымны биргәндер.

**11 март, 1995 ел.**
**Әлмәт — Азнакай.**

**Ильтани ИЛЯЛОВА,**
сәнгать галиме, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе

# Каршылыклар аша —

***Тагын бер елдан, 1996 елның азагында татар профессиональ театры туугa 90 ел тула.***

***Шушы вакыт эчендә татар театры нindирәк хәлдә, хәл-халәттә иде соң? Хәер, театрыбыз хакында инде җитди дә, саллы да фикерләр әйтелгән. Әнә шул фикерләрнең хаклыгын-дөреслеген шик астына алмыйча, мин театрыбыз узган юлга янә бер күз салмакчы булам.***

Әле күптәнме без, совет заманы калыпларына таянып, һәртөрле мәдәни күренешне, театрның юлын, шул исәптән Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрының юлын да, гел үсештән, күтәрелештән генә торган итеп сурәтләргә ярата идек. Һәм, шул ук вакытта, театрның үсеш-үзгәреш баскычлары төрле елларда төрлечә булганлыгы хакында оныта идек.

Миңа театрыбыз тарихын парадоксаль бер кагыйдә аша күзәтү кызыклы булып тоела: сәнгать каршылыкка гына таянып үсә ала. Әйе, каршылык булмаган җиргә, каршылык тумаган урынга таянып булмый ич!

Дөньякүләм сәнгать үсеше тарихы — моның ачык бер мисалы. Иң югары үсеш ноктасы — рухи ирекке мохтаҗлык заманында, көчле, талантлы затларның рухи изелүгә каршы күтәрелүе чорында туа. Барлык зур, бөек сәнгатьләр каршылыкларның иң кискен бер вакытында барлыкка килгән. Хәер, бу җәһәттән рухи изелүгә каршы күкрәк киереп күтәрелгән бөек Тукаебызны, ГУЛАГ төрмәләрен җиңеп чыккан Хәсән Туфаныбызны, «Моабит дәфтәре» авторы Җәлилебезне генә искә алу да җитә. Д.Шостаковичның, В.Шукшинның, В.Высоцкийның иҗаты совет системасының көчле басымы астында үскән. Әлеге системаның басымы шулкадәр дәрәҗәдә булды ки, монда инде бары тик көчле рухлылар гына исән кала, көрәшә ала иде.

Әйе, ирек һәм сәнгатьнең чәчәк ату чоры тәңгәл килә алмый. Моңа мисал итеп Көнбатыш Аурупа һәм дә Америкадагы икътисади туклыкны гына алыйк. Ә сәнгать? Аларда мин уртакулдан чак кына югары торган, фәлсәфи һәм сәнгать ачышларыннан ерак булган иҗат күрәм. Иң талантлы актерларның көче бетмәс-төкәнмәс «полиция сериаллары»на сарыф ителүен, йә булмаса очсыз мелодрамаларда файдалануын күрмибезме без? Икътисади уңышларның бәһасе бик тә кыйбатка төшә кебек: кеше шәхесенең бәясе кими бара. Кешенең яшәешендә төп урынны матди байлык ала, рухи байлыкка игътибар азая.

Татар артистларының беренче буынын искә алыйк әле. Аларның беренчел максаты-бурычы халыкка мәгърифәт нуры тарату булган. Әмма без шушы беренче профессиональ театр тудырырга алынган зыялы затларыбыз өстенә нинди генә авырлыклар төшкәнен күзаллый алабызмы? 1917 елга кадәрге чорда актерлык хезмәтенең юридик һәм гражданлык хокуклары булмый. Театр пьесаны сәхнәләштерү өчен рөхсәтне һәрчак цензорлардан алып торырга мәҗбүр булган, спектакль кую өчен рөхсәт полиция идарәсеннән алынган. Ә ул рөхсәт дигәннәре теләсә кемгә һәм теләсә кайчан бирелмәгән. Атналар-айлар узган, ә актерлар, рөхсәт көтеп, вакыт үткәргәннәр. Алар Рәсәй буйлап гизгәннәр, үзләренең спектакль кую һәм дә яшәү өчен төп урыннары да булмаган. Казаннан — Кырымга, Кырымнан — Уфага, аннан йә җәяүләп, йә очраклы транспортта йөргән алар. Поездларда «куян» булып та барырга туры килгән. Аларга нахак сүз дә, таш та ыргытканнар, өсләренә каргыш та яудырганнар. Ә алар — безнең беренче артистларыбыз — теш кысып булса да түзгән, халыкка яктылык, мәгърифәт алып килгән. Әлбәттә, монда да иң көчле кешеләр, үз эшләренең изгелегенә фанатикларча табынучылар гына театрда калган. Акылга сыярлык һәм дә акылга сыймаслык киртәләрне җиңеп, алар иң югары сәнгатькә омтылган. Габдулла Кариев, Сәхибҗамал Гыйззәтуллина-Волжская, Зәйни Солтанов, Гөлсем Болгарская, Касыйм Шамил, Фатыйма Ильская, Мохтар Мутин һәм башкаларның исемнәре безнең милли сәхнәбез тарихында чын мәгънәсендә алтын хәрефләр белән язылырга тиеш.

Бүгенге көндә без үз тарихыбызның әллә ни ерак булмаган чорларын яңабаштан бәялибез һәм дә совет чынбарлыгында бернинди дә яхшылык күрмәскә тырышабыз. Әмма бу бик үк дөрес караш түгел, дип уйлыйм мин. Әйтик, 70 нче елларда коточкыч мәгънәсезлекләр күп булса да, уңай хәлләр, уңай күренешләр дә аз түгел иде бит. Монысы инде милли театрыбызга да кагыла. Революциядән соң, мәсәлән, актер хезмәте дә башкаларныкы кебек үк, гражданлык һәм юридик хокуклар ала. Гражданнар сугышыннан соң, татар театры да даими эшләүче, үзенең стационар бинасын алган театр буларак оеша.

20 нче елларда илнең төрле төбәкләрендә — Ташкентта, Мәскәүдә, Бакуда, Җаекта, Чиләбедә, Свердловскида, Петропавловскида яңа татар театрлары барлыкка килә, Әстерхандагы, Ырынбурдагы, Уфадагы театр коллективлары актив эшли.

Ә инде 30 нчы еллар азагында бу театрларның барысы да диярлек ябылып бетә.

20 нче еллар — театрга эшче-крестияннар арасыннан яңа тамашачы өзерләү заманы. 20 нче елларда татар театрының гастрольләре дәүләт планы буенча оештырыла, ә инде соңрак театр олимпиадалары, декадалары уздырыла башлый. Мондый дәүләтләштерүнең дә, әлбәттә, ике ягы бар. Беренчесе — театрлар дәүләт тарафыннан финансланып, аның яклавын тойсалар, икенчесе — аларның ныклы контроль астына керүе. Дәүләт, театрларны үз кул астына туплап, театр сәнгатенең идеология өлкәсендә нинди зур роль уйнаганын аңлаган, билгеле. Әнә шул бер көчле идеология коралын үз кулына алып, матди яктан үз кулында тотып, дәүләт театрлардан тамашачыга үзе теләгән сүзне җиткерүне таләп итә. Социалистик реализм дигән бердәм принцип әдәбиятка да, сәнгатькә дә һәм, әлбәттә, театрларга да бәреп керә. Бу хәл XYII гасырда Франциядә барлыкка килгән абсолютизм күренешенә бик тә охшаш. Сталинизм чорындагы сәнгать — шул ук күренешенең көзгедәге бер чагылышы. Тоталитар режим бөтен җәмгыятьне үз кысаларына буйсындыра, ә инде әдәбият һәм сәнгатьнең баш очында әле тагын «социалистик реализм» камчысы да тора. Ә талантлы язылган, яңалыкка, үзенчәлеккә омтылган әсәрләр «дошман идеология тыкшынуы»на әверелә. В.Мейерхольд һәм аның Мәскәүдәге театры, С.Ахметели һәм аның Грузиядәге театры, Л.Курбас һәм аның Украинадагы театры әнә шулай юк ителде. Татар театры исә тулысынча юк ителүдән котылып калды, әмма аның да башын кистеләр — иң талантлы драматургларыбызны юк иттеләр. Ә драматургия — ул, чыннан да, театрның башы да, нигезе дә. К.Тинчурин, Ф.Бурнаш, А.-Т.Рахманкулов, Ф.Сәйфи-Казанлы, Ш.Усманов кебек драматургларның һәм режиссерларның юк ителүе, Г.Исмәгыйлевнең Камал театрыннан куылуы, Уфада татар һәм башкорт театрларын оештырган В.Мортазинның атылуы — болар барысы да театрның нигезен корыту максатыннан эшләнгән. Һәм, ни гаҗәп, аерым очракларны искә алмаганда, әлеге террор актерларны читләп узган. Татар театрыннан, белгәнебезчә, күренекле романтик актер Мохтар Мутин гына кулга алына һәм 1941 елда Колымада үлә.

Террорның актерларны читләбрәк узуын мин үземчә аңлыйм. Мөгаен, монда актерлык эшенең икенчел булуы, аның тамашачыга драматурглар һәм режиссерлар сүзен-мөнәсәбәтен генә җиткерүе сәбәптер. Һәрхәлдә, моны террорчылар үзләре шулай аңлагандыр: драматургсыз, язучысыз актер нишли алсын?!

Татар театрының, аерым алганда Камал театрының, ул куркыныч еллардагы репертуары турында сүз чыкса, кемдер — авыр сулап, кемдер — көлемсерәп, партия кушканча гына эшләвебезне искә алыр. Чыннан да шулай бит: барлык пьесаларда да бер сүз — халыкның революциягә кадәр бик начар яшәве, самодержавие белән көрәштә сыйнфый аң туплавы һәм дә совет чорында бәхетле-шат тормышка ирешүе. Кыскасы, бу чорда театрлар, сәнгать чараларын кулланып, партиянең идеологик күрсәтмәләрен башкарып килде. Һәм, ни гаҗәп — моны һичшиксез билгеләп, әйтеп үтәргә кирәк — күп кенә спектакльләр — «Ташкыннар», «Разлом», «Шәмсекамәр», «Кандыр буе», «Зәңгәр шәл» (аны куюны 1937 елда, К.Тинчурин кулга алынгач тыялар), «Хуҗа Насретдин», «Дошманнар», «Таня», «Фигароның өйләнүе», «Банкрот», «Бәхетсез егет» кебек спектакльләр югары сәнгать дәрәҗәсендә куелдылар-уйналдылар. Бу — драматургларыбызның, режиссерларыбызның, актерларыбызның таланты, рухи көче нәтиҗәсе, әлбәттә. Һәм иң гаҗәбе шул: тоталитар режим чорындагы ирексезлек, Каменев-Зиновьев, Бухарин-Рыков, «Шәрәфчелек», «Солтангалиев эше» кебек фаҗигале эшләр кузгатылган бер чорда совет театрының, шулай ук татар театрының да кискен үсешен күзәтергә була. Бу парадоксны аңлау өчен дә тарихка мөрәҗәгать итү кирәк. 20—30 нчы елларда яңа, матур тормышка ышанган халыкның энтузиазмы нәтиҗәседер бу. Гомумән, өмет-ышаныч көчле була бит ул беренче елларда.

Халык рухи тигезлеккә, хокуклар тигезлегенә, ирекле тормышка өмет итә, ышана. Ә бу ышаныч һәм энтузиазм көчле пропаганда коралы ярдәмендә «өретелеп» тора. Чкаловның очышлары, челюскинчыларны коткару вакытындагы шау-шулы пропаганданы гына искә төшерик. Матбугат һәм радио, кинохроника — барлык мәгълүмат чаралары бу чорда партияне һәм хөкүмәтне мактады бит. Халык соклaнудан «тотлыкты» һәм бу хәл 1932 елгы ачлыктан соң, крәстиән хуҗалыкларын юк итү, зур сыйнфый террор вакытында иде.

Менә шундый каршылыклы бер заманда, татар театрының чәчәк ату чоры күзәтелә. Иң зур авырлыкларны күтәрә белгән, үз эшләренә соң чиктә бирелгән, чын талант иясе булган кешеләр генә, рухи яктан нык, сабыр һәм көчле кешеләр генә булдыра ала мондый эшне. Сәхнәдә уйнамаган, ә бәлки сәхнәдә үз тормышы, геройларының тормышы белән яшәгән Ш.Шамильский... Үзенең герое — зиһен һәм акыл иясе Хуҗа Насретдине белән шаккатырган Х.Әбҗәлилов; Гөләндәм, Таня образларын тудырган Ф.Ильская һәм дә гаҗәеп рольләр башкарган Г.Болгарская, Н.Арапова, З.Солтанов... Нәкъ менә шундый актерларыбыз 20—30 нчы еллар театрының үзәге булдылар. Хәер, театрга әле соңрак килгән Х.Уразиков, Г.Камская, М.Сульва, Г.Булатова кебек артистларыбыз арасында да «өлкән буынга бирешмәслек» талантлар аз түгел иде. Әмма...«яңа буын» ул чорда, гомумән алганда, сәнгать осталыгы ягыннан күпкә калышты. Ни өчен? Беренчедән, әлбәттә, шәхси мөмкинлекләр аермасы бар. Икенчедән, алар инде — сәхнәгә гомумкурку чорында килгән артистлар. Шулай ук драма әсәрләрен язган авторларның да шул ук курку — табигый курку белән иҗат итүләрен онытмыйк. Әнә шул кешеҗаны һәм тәненең барлык күзәнәгенә кереп оялый торган курку Камал театрындагы күп кенә артистларны бер гаепсезгә кулга алынган М.Мутинга яла ягарга мәҗбүр итте, аңа пычрак аттырды. Әлеге курку өстән килгән барлык күрсәтмәләргә берсүзсез буйсыну халәтен тудырды. Ә бу инде иҗатта, сәнгатьтә коточкыч хәл...

Бөтен дәүләт күләмендә шәхес культы, бер кешенең культы барлыкка килгән икән, бөтен совет театрлары өчен бер театрның — Мәскәү сәнгать театрының (МХАТ), шул театрдагы зәвык һәм ысулларның культ булып әверелүе гаҗәп түгелдер. Сталин нәкъ менә шушы театрны яратканга күрә, ул башкаларга да «тәрбия» мәктәбе була.

Җитмәсә, бу хәлләргә әле тагын 40 нчы елларда туган «каршылыксызлык теориясе» дә өстәлә. Әлеге теория буенча, сәхнәдәге геройларның фикере, инкубатор чебиләре кебек үк, бертөсле генә булырга тиеш. Менә шушы хәл театр үсешен шактый озак еллар тоткарлап килде.

Хәтта Сталин үлеп, чагыштыр-

мача «җепшек» еллар башлангач та, әлеге дә баягы курку хисе уза тошкәч тә, театрлар яңа ысуллар табу мөмкинлеге алгач та — сәхнәдә жанрлар төрлелеге тусып, Мәскәүдә инде атаклы «Современник» театры барлыкка килеп, яңа, яшь режиссерлар үсеп чыккач та — татар театры бер урында таптанды, элекке калыплардан арына алмый интекте. Бары тик 1957 елда гына, Мәскәүдә узган декада вакытында театрда зур бер үзгәреш булып алды, Камал театрының иң яхшы спектакльләре кире кайтты: «Зәңгәр шәл», «Ташкыннар», «Хуҗа Насретдин», «Король Лир», «Миңнекамал», «Зифа» әсәрләре яңадан куелды, иң яхшы бәяләр алды.

Ә аннан соң әлеге ут та сүнде, барысы да элеккечә, искечә калды. Театр шул рәвешле үз тамашачысын югалтты. Моның сәбәпләре дә шактый иде. Коллектив үзе дә яшь ягыннан олыгаеп-картаеп китте. Өстәвенә 1950 елда ГИТИСның татар студиясен тәмамлап кайткан яшь артистлар читкә тибәрелде, өлкәннәр аларга үз урыннарын бирергә теләмәде. Яшь геройларны, яшь образларны 50 яшьлекләр уйнады. Театрның заманча уйлый белгән сәнгать җитәкчесе дә юк иде. Ул елларда пәйда булган яшь драматурглар — А.Гыйләҗев, И.Юзеев, Х.Вахит, Ш.Хөсәеновларның әсәрләре искечә ысуллар белән куелды, шуңа да уңышка ирешә алмады. Монда бары тик Р.Бикчәнтәев куйган комедия әсәрләре генә уңышлы чыкты. Татар студиясенең икенче төркеме — щепкинчылар кайткач та, — ә монысы 60 нчы еллар башы — аларны гитисчылар язмышы көтәргә мөмкин иде. Әйтик, училищены менә дигән билгеләргә тәмамлаган Т.Миңнуллинны театрдан «за профнегодность» дигән сылтау белән чыгардылар. Бүгенге көндә күренекле артистларыбыз Р.Таҗетдинов һәм Р.Шәрәфиевне дә шундый ук хәл көтәргә мөмкин иде, әмма аларны театрга яңа җитәкчелек килүе коткарып калды. Партиянең өлкә комитеты һәм Мәдәният министрлыгы карары белән, Камал театрының директоры итеп — артист Р.Җиһаншина, ә баш режиссер итеп әле ул чакта бик тә яшь булган М.Сәлимҗанов билгеләнде.

Әнә шул чактан инде театрыбызның эше чын-чынлап җанланып китте, аз гына вакыт эчендә ул бөтен СССРда дан алды. Фоат Халитов, Габдулла Шамуков, Шаһсәнәм Әсфәндиярова кебек талантларыбыз яннәсендә Шәүкәт Биктимеров, Ринат Таҗетдинов, Равил Шәрәфиев, Әзһәр Шакиров, Наил Дунаев, Нәҗибә Ихсанова калкып чыкты. 1949 елда театрга танылган баянчы Рәис Сафиуллин килде, соңыннан театрның алыштыргысыз концертмейстеры булып китте. Театр Казан театр училищесыннан килгән яшь артистлар белән даими тулыланып торды. Алсу Гайнуллина, Илдар Хәйруллин, Фирдәвес Хәйруллина, Рузия Мотыйгуллина, Зөлфирә Зариповалар һәм башкалар театрга әнә шул рәвешле, өлкәнрәкләрне тулыландырып килде.

Ә быелгы язда сәнгать һәм мәдәният академиясенең (беренче чыгарылыш икәнен дә онытмыйк) тулы бер төркеме, Казанның үзендә профессиональ актерлык һөнәре алып, театрыбыз эшчәнлегенә кушылды. Бу — матур һәм мактаулы күренеш инде: чөнки өлкәннәр янында осталыкка һәм остазлыкка өйрәнү милли сәхнәбезне баетачак кына.

Соңгы елларда сәхнәнең үзен дә бизәгән, актерларга да очыш мөмкинлегә биргән спектакльләребез күп булды. Алар арасында төрле жанрдагы әсәрләрнең күп булуы ни тора! «Миркәй белән Айсылу», «Американ», «Сүнгән йолдызлар», «Әни килде», «Качаклар», «Казан сөлгесе», «Зәңгәр шәл», «Әлдермештән Әлмәндәр», «Моңлы бер җыр», «Диләфрүзгә дүрт кияү», «Бичура», «Идегәй»... һәм тагын әле бик күп, бик күп спектакльләр. Тамашачыбыз да рухи яктан байый төште. «Сүнгән йолдызлар»ның кайчаннан бирле куелып килгәнен искә төшерик тә, «Әлдермештән Әлмәндәр»нең 1976 елдан бирле куелуын, тамашачысын югалтмавын уйлыйк. Бу спектакльләр уйналган-куелган чорда яңа буын яшьләр үсеп чыкты. Үз яшьләребез. Үз халкыбызның үз театрына мәхәббәтле яшьләребез. Теге чагыштырмача «җепшек» елларда туып, соңыннан килгән «торгынлык»та юкка чыккан мәктәпләребезне уйласак, татар театрының телебезне, рухыбызны, гореф-гадәтләребезне ни-

## йолдызларга

чек саклаганын бөтен тирәнлеге белән аңларбыз.

Ә бит үз дөньяңны саклап калу бик авыр иде. Шәхес культы елларындагы кебек сыйнфый репрессияләр булмаса да, ул торгынлыкны тудырган идеологик басымның көчен театр нык тойды! Соң, Ташкентта үзбәк академия театры Шекспирның «Гамлет» әсәрен әзерләгән чакта, спектальне тикшерү вакытында әйтелгән бер «мәзәк»не генә искә төшерик. Сәнгать идарәсе башлыгы ул чакта әйтә: «Иптәшләр, бәхәсләшеп тормыйк, иптәш Шекспирның үзен генә чакырыйк та, калганын үзе төзәтсен!» — ди. Татар театрында ул кадәр үк әкәмәтләр килеп чыкмаса да, мәгънәсез-көлкеле хәлләр аз булмады. Әйтик, «Әни килде» спектаклен 70 нче елларда үзәк матбугатның уңай фикере генә саклап калды. Шуңа да карамастан, өлкә комитеты бәйләнде: имеш, спектакльдә (шахтер Ислам образы) эшче сыйныфы тискәре герой итеп бирелгән. Мондый мисалларны тагын да санап булыр иде...

Әйтергә теләгәнем шул: театр үзенең бөтен яшәешендә каршылыклар, көтелмәгән һәм очраклы-мәҗбүри киртәләр аша узды. Ә шул киртәләрне узу аның үзен дә сәнгать булу ягыннан үстерде.

«Үзгәртеп кору» лозунгларын җәмгыять үзе бик шатланып кабул иткән иде. «Азатлык!» — дип кычкыру рәхәт иде! Әйе, идеологиядә ирек тугандай булды. Театрлар үз репертуарларын үзләре хәл итә. Әмма кыргый базарны уйлап чыгардык. Кем әйтмешли, «Америкада — эшсезлек, Әминә апада — тешсезлек ...җитешсезлек...» Кыйбла эзләргә тиешле театрлар акча эзлиләр. Менә шундый бер чорда татар театры акыллы булды. Ул соңгы елларда милли классиканы һәм дөнья классикасы әсәрләрен куйды, М.Гыйләҗев, З.Хәким, Д.Салих, Г.Каюм, Х.Ибраһим кебек яшь драматургларны эзләп тапты, Т.Миңнуллиндай бай тәҗрибәле драматургыбызны да һич онытмады. Көлде-елмайды, елады-көлемсерәде, уйланды-уйландырды: театр рухыбызны саклауда, тарихи аңыбызны уятуда фидакарьләрчә хезмәт итте.

Мин инанып-ышанып әйтәм: татар театрының әлеге хак кыйбласы бу буталчык заманда да милли сәхнәбезнең намусына тап төшермәдә. Әмма бүген аңа да авыр. Гәрчә шулай булса да, ул үсештә, чөнки театр каршылыклар чорында да ныграк үсә...



***Т**атарстанның халык язучысы Гариф Ахуновка 70 яшь тулу уңаеннан элекке СССРның төрле җөмһүриятләреннән 60тан артык котлау килде. Котлаучылар арасында урысның мәшһүр язучысы Валентин Распутин, атаклы авар шагыйре Рәсүл Гамзатов һ.б. бар иде. Ә без ошбу сәхифәдә ут-күршебез — Башкортстанда яшәүче күренекле әдип Мостай Кәримнең котлау сүзен тәкъдим итәбез. Ник дигәндә, безнең халыкта: «Үз хәлеңне күршеңнән сора», дигән әйтем дә бар бит әле...*

# Гомерең озын, картлыгың кыска булсын

Хөрмәтле Гарифйән!

Бездә, Башкортстанда, Сине бик тә үз күргәннәр, исемеңне тутырып, җылы итеп, Гарифйән, диләр.

Чөнки Синең ил бәһаләр
Юнең бар,
Йөрәкләрне били торган
Җаның бар.

Син яшәгән җитмеш елның, Гарифйән, яртысыннан күбрәген, күзгә-күз карашып, сүзгә-сүз куешып, иҗади сулышларыбызны тоешып, байтак-байтак шәраб коешып, араларга салкын җил җибәрми, күләгә төшерми, тату яшәдек. Шул заман эчендә Сиңа карата минем күңелем суынмады. Син — соңгы егерме биш елда булып узган минем түгәрәк даталарымда, йортымны олылап, табыннарымны ямьләп, мәҗлесләрдә тамада булдың. Озын сөйләсәң дә бозык сөйләмәдең, мине мактасаң да, оялырлык итеп, чамасыз мактамадың, хәтта үтереп мактаганда да мактап үтермәдең. Мин дә сиңа карата бүген үземне шулайрак тотармын.

Беренче очрашкан чакта ук Син без җырлаган җырга кушылдың:

Тып-тып кына басып килә
Көмеш тояк тулпар атым...

Ул чакта Синең иҗатыңның тулпары, ышанычлы итеп, тып-тып басып, татар әдәбиятына, күп милләтле зур совет әдәбиятына кереп бара иде инде. Әмма Синең иҗат тулпарың бәйгеләрдә ярышып кына даннар һәм бүләкләр алмады. Дөрес, бәйгеләрдә дә ул күп вакыт ал бирмәде. Ул тулпар, асылда, татар әдәбиятының чабыш аты да, сабан аты да, йөк аты да, гаскәр аты да булды һәм була килә. Ярыш мәйданында ул ап-ак күбеккә батса, бураэнада ул кап-кара тирләрен түгә.

Хәзер өченче затка күчеп, «Син» диясе урында «ул» дип сөйләячәкмен.

Тел төбем шуңа бара: мондый иҗатчыларның җырына да, зарына да халыкның төрле-төрле катламнары колак сала, йөрәгенә һәм аңына кабул итә. Һәркем үзенең рухына тансык азыгын таба.

Гариф Ахунов татар әдәбиятында үз урынын күптән раслады Аның әсәрләре милли ызаннарны үтеп, бүтән тарафларга, урыс теле ярдәмендә бүтән илләргә, бүтән телләргә барып җитте Татар халкы хакында, татарның рухи булмышы хакында вак сүз сөйләп, дөнья алдында милләтенең дә, үзенең дә дәрәҗәсен төшермәде. Эреләнми генә эре сүз сөйләде, сөйләп килә

«Ызан» дидем дә, әллә ничек ямансу булып китте Петр Беренче Аурупага тәрәзә уйганнан соң өч гасырга якын гомер үткәч, бөек илдә халыклар, мәдәниятләр, әдәбиятлар, сәнгатьләр арасында биек-биек коймалар хасил булды. Нигездә ул коймаларны каты бәгырьле йомшак зиһенле политиклар һәм аларның мәнсез яраннары һәм иярченнәре койды.

Бу җәһәттән язучыларның мөкатдәс бурычы шулдыр димен әлеге коймаларны берьюлы гына җимереп булмаса да, һич югында, капкалар тишәргә, капкалар ачарга кирәк.Гариф Ахунов кебекләрнең иҗаты, шәхесе, эшмәкәрлеге әнә шул капка ачучылар хезмәтен үтәргә бурычлы. Чөнки дөнья күрмәгән, дөньяга күренмәгән адәм — надан бичара. Дөньяны күреп тормаган, дөньяга күренеп тормаган әдәбият сәнгать, фән бөек куәткә ирешә алмаячак «Үзебез генә...» дип паф ору — җитлекмәгәнлек билгесе Коймалар коелганчы ирешелгән казанышлар турында уйласак, сез минем бу борчылулы сүзләремнең раслыгына ышанырсыз

Хөрмәтле җәмәгать!

Бу мәҗлескә мин сезгә, татарларга, Гариф Ахуновның нинди язучы икәнен, бәйнә-бәйнә сөйләп, төшендерергә килмәдем Белеклеләр болай да беләләр. Белмәгәннәр өйрәнеп белерләр. Рухларын, аңнарын баетырлар.

Мин җитмешә генә тулган энемне, зур бәйрәме белән котлап, кочакларга гына килдем Бер генә теләгемне әйтәм

— Гомерең озын булсын, Гарифйән, картлыгың кыска булсын, Гарифйән.

**Мостай КӘРИМ,**

Башкортстанның халык шагыйре, Социалистик Хезмәт Герое Ленин премиясе, СССР, Русия, Башкортстан дәүләт бүләкләре иясе

МӘХӘББӘТ ТУРЫНДА ИКЕ ХИКӘЯ

Тәлгать ГАЛИУЛЛИН

# КОЛЮНЧИК

Үзен ата төлкедән дә хәйләкәррәк санап йөрсә дә, Нәҗип гомерендә бер хата ясады. Хата дип тә булмый инде аны. Хатның эчтәлеге бик җылы иде шул. Ертып ташлый алмады. Йөрәге җитмәде. Акыллы кешеләр кирәкмәгән бер кәгазьне дә, сәяркәңнән килгән «кош теле»н инде бигрәк тә, янында тотарга киңәш бирмиләр. Нишлисең, язмыштан узмыш юк. Шайтанның бисмилла дигән вакытына туры килгәндер.

«Милый Колюнчик...» дип башланып киткән мәхәббәт мәктүбен кабат укыган саен, йөрәгенә җылы сары май акты. Ашыкмыйча, матур, татлы итеп саркыды ул май бөтен гәүдәсенә, юан беләкләренә, кыска муенына.

Чибәркәй белән Самарада армиядә хезмәт иткәндә танышты ул. Чүл Гарәбстанындагы кебек эссе көн иде. Һәркем салкын эзли. Нәҗип тә суык каймакка — мороженоега чиратка басты. Алдында торган төз, матур гәүдәле кызыл өстенә мул итеп ак борчаклар сибелгән җиңсез күлмәкле кызның муен артындагы ак чәчләренә күзе төште.

Шуннан соң гына ул аның төз һәм туры аякларына, нечкә биленә игътибар итте. Солдат тәне буйлап ачы һәм татлы калтырау дулкыны үтте. Аякның чәнчи бармагыннан башлап, йөрәк аша китеп, колак тамырларына барып җитте. Гомергә салкын борыннан тир бәреп чыкты.

Кызның чираты җитте. Акчасы егерме бишлек икән. Сатучы: «Барыгыз да зур акча бирәсез, сезгә каян җиткерим мелочь?!» — дип тузынды да, акчаны кире ташлады. Егерме тиенлек боз өчен шул чаклы акча санап, вакытын заяга уздырасы килмәде бугай.

Увольнениегә чыккан солдатта егерме бишлеге булмаса да, вак акча бер букча була. Нәҗип үз сәгате сукканны җиденче тою сәләте белән сизеп, тимер акчаларын тактага куеп, ике каймаклы бозны алып, аптырап, югалып торган кызга сузды.

— Рәхим итегез, тотыгыз!

Кызның уйлап торырга вакыты юк иде. Тырнаклары өлгергән чия төсенә буялган куллар ихтыярсыздан хыялда яшәгән тәмле, татлы суыкка сузылды. Озын керфекләрен ишекле-түрле йөртеп, «рәхмәт»не әйтте дә, киң җилкәле, киң каешлы солдатка күз сирпеде. Аяз күк йөзедәй зәңгәр күзләр канәгать калды бугай. Һәркөлдә Нәҗип шулайрак фараз кылды. «Чибәркәй мине хуплады булыр, абзагыз ошатмаслык түгел шул: югары белемле булуым да яхшылап кырылган биттән үк күренеп тора».

Мәгәр кызның һаман да янымда торуының хикмәте башкада икән. Бурычлы каласы килми икән тегенең.

— Хәзер, сезнең белән бер кибеткә кереп, акчаны алыштырабыз. Кемгә-кемгә — хезмәттәге кешегә бурычлы кала алмыйм.

Нәҗипнең ирennәре салынса да, сиздермәде. Иярде. Аларны беркайда да көтмиләр икән. Әйбер алмасаң, акчаны ваклау юк.

Кыз Светлана исемле булып чыкты. Ательеда эшли икән. Тулай торакта бүлмәсе бар.

Урыс җирендә күнегелгән гадәт буенча, Нәҗип үзен Николай дип тәкъдим итте.

Самарада хәрби хезмәтен башлагач, Казан егете татарча исемен саклап калырга тырышмады түгел. Милли горурлык хисе канында бар иде. Мәгәр барып чыкмады.

Үзе белән Нәҗип дип таныштыруга, аңа «Джип» кушаматы тактылар. Әмерикәннәрнең җиңел хәрби машинасы булыр инде ул.

Нәҗип дигәч ике иҗекне аерып, соңгы «п» хәрефен «д»га алыштыра торган булдылар. «На жид» килеп чыкты. Бу наданлык сәхрәсендә башкача булмый икән дип, Николай язмышына ризалашырга мәҗбүр булды.

Бер сәгатьтән тегүче кыз аны Коля, Колюнчик дип кенә атый башлады. Ә инде тулай торакка килеп йөри башлагач, ул исем-фамилиясез «милый Колюнчик», «мой солдатик» булып кына калды.

Еш һәм яратышып очраштылар. Нәҗипнең мөмкинлеге бар иде. Данлыклы совет армиясендә әлбәттә өлкән офицер-генералларны санамаганда өч һөнәр иясе яхшы яшәде: музыкантлар, физкультурниклар, ат һәм кеше докторлары. Аларның мәчеләре куян тотты.

Идел буе гимнастика уенчылары командасына кергән Нәҗип, теләсә кайчан диярлек, шәһәргә чыга ала иде. Светлана аңа төмам ияләшеп, Самарада калу, гаилә кору турында сүз ката башлагач, Нәҗипне өенә кайтарып җибәрделәр. Хрущев кыскартуына эләкте.

Эш адресын калдырып һәм тиздән өйләнеп кайтырга кайнар вәгъдәләр биреп, Нәҗип бөтенләйгә гаип булды.

Инде Светлананы йөрәгеннән башка чибәркәйләр кысрыклап чыгаргач, хат килеп төшмәсенме. Есенин әйтмешли, «Письмо, как письмо... Я в жисть бы таких не писал».

Кызый бергә булган бәхетле мизгелләрне бәйнә-бәйнә искә төшергән.

Хатның эчтәлеген зиһенгә алуга юкка чыгарса, ак сакаллы ил карты буласы иде дә, адәм баласына истәлек, хатирә кирәк. Әнә бит ничек, һаман да өзелеп-өзелеп яратуы, сагынуы, юксынуы турында яза.

Шул көнне генә, гөнаһ шомлыгына, ул чорда ябырылып укылган Павел Нилинның «Жестокость» исемле китабын сатып алган иде. Шуның эченә кыстырды да хатны, онытты.

Байтак сулар акканнан соң, җыентыкны өенә алып кайтып, китап шүрлегенә куйды. Нияте изге иде — укый башлау.

Хатыны Халисә өй җыештырганда, китапларны берәм-берәм алып, юеш чүпрәк белән тузаннарын сөрткәндә, хат шап итеп идәнгә килеп төшмәсенме. Кат-кат укыла кәгазь. Бишенче сыйныфта укучы кызы Гөлназ да мәхәббәт мәктүбенең эчтәлеге белән таныштырыла. Хат гаиләнең шәхси дошманы булып китә.

Нәҗип өйгә кайтыр алдыннан өенә чылтыратып алды.

— Бу синме? — диде ул трубканы алган хатынына.

— Юк, мин түгел, — диде Халисә, телефонны ташлады.

Ир-ат җенесе әле берни сизенми, Сөйдәшнең «Совет армиясе маршы»н көйли-көйли бусагадан узды.

Хатыны аның ягына өйләнеп тә карамый. Тулы артын Нәҗип ягына куеп, бөгелеп идән юа. Борылса, күзләре яшьле.

— Карчык, кайнар сәламнәр сиңа, — диде Нәҗип, гадәтенчә. — Капкаларга нәрсә бар? Ачыктым.

Нәҗипнең сәламе салам бәясенә дә алынмый. Шунда гына йөрәге жу итеп китә. Хат... теге хат... Дошман кулында...

— Нигә шулай эреләнәсең әле, хатын?

— Хәзер белерсең!

Хатын, ире ягына өйләнеп тә карамыйча, чиләкне түгәргә урамга йөгерде.

Нәҗип яшен тизлеге белән элек яратыплар укыган, хәзер аның да шәхси дошманына әйләнгән хатны эзли башлады. Китап эчендә юк.

Туфанның «Очрашырбыз әле» шигырендә генә ул бер нәрсә дә юкка чыкмый, бер төрдән икенче төргә генә күчә. Күпме кабатласаң да, юк әйбер юк инде ул.

Халат, күлмәк кесәләрен актарып, хәле бетеп диванга утырды Нәҗип. Вакыт санаулы. Менә хатын килеп керәсе.

«Тукта әле син, Нәҗип туган. Хатын-кыз хатны, сәткә дигән вак акчаны өстәл өстендәге клеенка астына кыстыра торган иде». Кызыл шакмаклы клеенканы күтәрсә, хат шунда ята. «Милый Колюнчик...»

Нәҗип хатны, ач бүре сарык ботарлаган кебек, бөтен ачуын, көчен салып, вак кисәкләргә ертты да, бер өлешен авызына капты, буыла-буыла йотты, калганын форточкадан ташлады...

Хатыны чиләкне шыпылдатып идәнгә куйганда ул инде диванда эре генә утыра иде.

— Нәрсә болай күркә кебек кабарынып йөрисең, матурым?

— Оятсыз, тирес бит. Мин монда бала үстереп ятам, тол хатыннар кебек. Ул ниләр генә кыланмаган армиядә. Һаман да хатлары агылып тора.

— Юкны сөйләмә инде. Фантазерка. Ниткән хат ул тагын.

Хатын мәхәббәт мәктүбенең эчтәлеген яттан өйрәнгән. Шуны дога шикелле тәкрарлый-тәкрарлый, идәндәге чиләкне алып, һөҗүмгә китте.

Нәҗип, диванга ятып, аякларын өскә күтәрде.

Күпне күргән кара чүп чиләге, Югославия ботинкаларының калын табанын кыйнап аргач, көчсезләнеп өстәл астына тәгәрәде.

— Тукта, дим, хулиганка. Нинди хат, тагын нәрсә уйлап таптың.

— Сволочь, нинди хат дип, теленә салына тагын. Менә нинди хат!

Хатын гаилә драмасына тартып кертелгән бәхетсез клеенканы идәнгә алып бәрде.

Хат юк иде. Халисә телсез калды. Матур бит алмалары ишелеп ияккә төште, коңгырт сүзләре зур ачылып, маңгайны кысрыклый башлады.

— Хатны син урлаган, бир!— дип янәдән совет яугирләре кебек һөҗүмгә күчте хатын.

Нәҗип, тыныч кына торып, өстәлнең аръягына басты, сыртын кабартты.

— Син тагын нәрсә уйлап таптың!? Әллә ычкына башладыңмы? Галлюцинацияме синдә? Чирлисең икән, врачка күрен!

Шул мизгелдә ханымның йөзендә барлыкка килгән аптырау, югалып калу өсәренү, хурлану, гарьләнү калдырган эзләрне сурәтләргә минем каләм көче генә җитәрлек түгел.

Ул, теле яңа ачыла башлаган бала төсле, тотлыга-тотлыга, өзек-өзек җөмләләрне кысып чыгара башлады матур иреннәреннән.

— Нә-җип, хат кая?.. Шунда гына иде. Гөлназ белән укыдык. Кат-кат.

Нәҗип, джинсы чалбарыннан юк тузанын каккандай итте дә, үзе һөҗүмгә күчте.

Уйларга өйрәнмәгән башка бала чакта әтисеннән күңеленә иңгән мәкаль келт итеп килеп төште.

— Тегермән башын җил борыр, адәм башын сүз борыр, диләр. Син, матурым, хет авызың ни сөйләгәнгә җавап бирәсеңме? Без бит демократик илдә яшибез. Эш кешесенә күрәләтә яла яккан, гайбәт тараткан өчен, между прочим, статья бар. Анда фәлән ел каралган. Белеп чыгар сүзеңне сирәк тешләрең арасыннан.

Сандугачны сайрарга өйрәтмиләр. Китте кызып Нәҗип. Хатынының иң авырткан сөяленә басты. Тешләре ямьсез иде аның. Һәр яктан килгән, тулы, шул ук вакытта уйнап торган, җыйнак гәүдәсен, мул күкрәкләрен, түгәрәк битен ямьсезләп торган сирәк тешләрен күрсәтеп, катты да калды физкультура укытучысы хатыны.

Эшне зурга җибәрү, аерылышу турында сүз кузгатасы килә Халисәнең. Кая ул, Нәҗип дулаганнан-дулый, кызганнан-кыза бара.

Физкультура укытучысы югары, урта уку йортларында да, мәктәпләрдә дә, Һиндстандагы халык кебек, аерым каста булып яши. Укучылары белән бергә буыннарын язган, зарядка ясаган өчен ул хәреф, сан чүпләп, дәфтәр тикшереп күзләрен бозган укытучы хәтле үк эш хакы алыр.

Шул ук вакытта физкультура укытучысы үзе турында югары фикердә булып, шул хакта фәлсәфәгә чумарга яратыр. Сөйләгән сүзе зыялылар өчен кызык, яңалык булмаса да, бер үк балык башын чәйнәсә дә, син аның фикере белән килешмичә, монологын өзмәс. Бичарадан ни чара, син аның белән ризалашырга мәҗбүр булырсың.

Нәҗипнең сүзләре Халисәнең йөрәгенә, бавырына, сукыр эчәгенә барып җитте.

— Ахыр чиктә, мин бит коммунист кеше. Большевиклар партиясе члены. Иртәгә эшеңә, директорга барам һәм синең мине хур итәргә йөрүең турында бәйнә-бәйнә сөйләп бирәм. Эшеңнән кудыртам. Хәзер немец теле укытучысына кытлык юк.

Хатын үзе дә сизмәстән:

— Колюнчик, милый. Хат бар иде бит! Шуны гына әйт, — диде.

— Бернинди хатны белмим. Хат юк. Башкасы — гайбәт.

Мәктәптән кайтып кергән кызлары Гөлназ идәндә ырҗаеп, ямьсезләнеп яткан чүп чиләген, кызыл шакмаклы клеенканы күргәч, мәсьәләнең торышын бик тиз аңлап, үз бүлмәсенә шылды.

Кеше хаты өчен баш катыру ни пычагыма аңа. Үз күрәсе алда.

Нәҗип бушбугаз Рудин, әтек Сатин, булдыксыз Батырханнар төсле төмам рольгә керде. Мескен хатынны почмакка китереп кысты. Тегесе инде сүз кузгатканына шат түгел иде.

Бу хәлләрдән соң егерме елдан артык вакыт үтте. Оныклары Тимур үсеп килә. Хат гомере буена Халисәнең миен бораулап торды. Хатын-кыз хәтере хыянәтне беркайчан да онытмый. Нәҗиптән кеefe яхшы чакта да, чыгырыннан чыкканда да, шашып сөешеп, агач караватка сыймыйча, үзен идәнгә сөйрәп төшергәндә дә, лөх исерек вакытында да хат, дөресрәге, аның булу-булмавы хакында сорауны биреп торды.

«Колюнчик»ның җавабы бер булды:

— Хат юк иде. Булмады да!

Тотылмаган аюның тиресен тунамыйлар.

# СПИД вә мәхәббәт

Авыр тимер ишекне каерып ачып, Рәүф эчкә үтте. Икенчесен үтәргә насыйп булмаган икән. Анысында тере йозак — яшь кенә кибетче кыз басып тора. Бу инде гади халык теленә тәрҗемәдә азык-төлек кибете ябык, буйдак ир төнгә катыксыз, иписез калды дигән сүз иде.

Өстенә тупас киндер тукымадан тегелгән, сыек зәңгәрсу төстәге халат кигән кызый кибетнең эчке ягына борылган да, симәнкә чиртә. Бөтен сүрәсен китереп, дөньясын онытып, идәнгә түкереп, төмләп ашый. Көнбагыш кабыклары мәрмәр идәнгә Яңа ел карлары кебек акрын гына төшеп сылаланалар.

Сакка куелган сатучы бер аягы белән юлны япкан. Әллә каян, тирәннән, халат эченнән чыккан аякның озын һәм төз булуын искәрде хатын-кызга игътибарлы, үткен күзле карт буйдак. Колагында алтынданмы, әллә бакырдан гынамы, ул хәтлесен Алла белсен, әмма җете сары металлдан дуга рәвешле ясалган олы алка асылынып тора. Ә борыны... Шул чаклы килешле, әгәр адәм баласы томау тишекләрен үзе сайлап ала алса, Рәүф мондый мөлаем йөзгә нәкъ шул борынны тәкъдим итәр иде. Һич ике уйлап тормыйча...

Буйдак ир шактый таптанып торды җанлы бик янында. Игътибарның «и» хәрефенә дә лаек була алмады. Бер ягы каралган ак кар коелыпмы-коела идәнгә, ачуны китереп, саруны кайнатып...

Рәүф әллә каян алдына килеп баскан гүзәл сын белән сокланып туйгач, гасабиланып:

— Үтәргә мөмкинме? — диде.

Кыз аның ягына борылды. Күзе уйнаклап алды. Зәңгәрне фирүзә төс алыштырды.

— Кибет ябык. Күрмисезмени?!

— Җиде туларга әле унбиш минут бар.

— Без көндезге ялны кыскарттык.

Назланып-үтенеп сорап тормады Рәүф. Кире атлаган — ишеккә җитмәс, диләр. Чигенәсе дә килмәде.

Кемдер калак сөяге астына юан энә белән төрткәндәй булды. Ни өчен шулай эшләгәнен кабереннән Берия торып сорау алса, җәзаласа да, Рәүф аңлата алмас иде. Әллә тәтеми калган катык башын ашадымы, шайтан ялгыштырдымы, язмышмы...

Ни булса булды, ул мәче тизлеге белән кызга якынлашты да, чапылдатып үбеп тә алды. Көнбагыш маеннан кайнарланган иреннәрнең яртысы кереп китте Рәүфнең комсыз авызына.

Йә Хода, бетте баш, дип уйлап өлгерде карт буйдак. «Хәзер ул матур, салпы кулы белән яңакка китереп сылаячак, яисә минем йомшак җирдә импортный итегенең эзен калдырачак. Милиция чакыруы да бар. Җитмәсә, каһәре, авыздан аракы исе дә килә».

Вакыйга көтелмәгән юнәлеш алды. Кыз, Рәүфне якасыннан эләктердә дә, кибетнең эченә сөйрәп алып керде.

Аягы капкынга эләккән ерткыч кебек кычкыра ук башлады.

— Кызлар, кызлар килегез әле Бур тоттым.

Коне буе прилавка артында торып арыган, дөнья мәшәкатьләренә, сәяси борылышларга бик исе китмәгән сатучы халкына һәрдаим кызык кирәк. Килеп тә җиттеләр.

— Нәрсә булган?

— Ни урлаган?

— Зөлфа, ниткән шыр ярасың?

Шактый көчле кулын якадан ычкындырмыйча гына. кыз ярсый-ярсый аңлатып бирде.

— Бу мужик мине көчләп үбәргә ябышты. Кешелек дәрәҗәмне таптады. Оятсыз

Тынлык урнашты. Дистәләгән кара, комсыз, соры, битараф, яшькелт, зәңгәр, тагын әллә нинди күзләр Рәүфне астан-өскә капшый башлады Уртачадан озынрак буйлы, түгәрәк йөзенә килешле кара мыеклы ир күбесенә ошады бугай.

Егет исә шөлли калды. Шолохов Давыдовын кыйнаган шикелле бергәләп тукмап, йоныңны йолкып ташласалар, ни хәл итәрсең. Уймак уеннан чыга икән шул.

Сатучыларның кызмача ирне тәпәләп, кул пычратырга исәпләре юк иде бугай. Аларга кул май, колбаса, ит, он үлчәп бирү һәм көнлек калымны санау өчен кирәгрәк.

Сатучы халкы гөж килде Казан кибетчеләренең җитмеш проценты татар хатын-кызлары булып, йөзнең сиксәне мишәр кавеменнән. Алар йомры сүз эзләп кесәгә кереп тормас, тел очында йөртер көмеш кашыгын.

— Мине шундый ир, үбүгенә түгел, көчләсә дә рәхмәт кенә әйтер идем әле. Җебегән.

— Тиле бәрән орлыгы ашаган кыз! Нәрсә дип акырасың?

— Дуңгызны өстәлгә утыртсаң, аягын өскә куяр. Милисәгә тапшыр.

— Үпкән-кочкан — җилгә очкан.

— Зөлфа, язмыштан узмыш юк. Сине әҗәлең эзләп килгән.

Шактый тел чарлаганнан соң, кибетчеләр урыннарына таралыштылар. Зөлфаның да кулы талды бугай, яканы ычкындыруны кирәк тапты. Үзе һаман Рәүф янында. Кызны артык чибәр дип булмый. Әмма ир-ат халкының кабырга арасын кытыклап, нәфесен котырта торган татлы җитешкәнлек бар. Магнит кыры кебек тартып тора үзенә. Канына сөт өсте катышкан диярсең.

— Ярый чыгып китегез, башка монда күренмәгез!

Рәүфнең һич кенә дә кыз кырыннан китәсе килми иде инде. Эчтә утырган хәмер пары кыюлык өстәп тора.

— Озатып куйсам, ничек булыр икән?..

— Шул гына җитмәгән. Минем егетем каршы алырга килә. Очрашмавыгыз хәерлерәк булыр. Сезнең өчен.

Шунда Рәүфнең башына бөтен тормышын, яшәешен әйләндереп ташлаган, аңа ахыр чиктә күктән эзләгән бәхетен юлына чыгарып куйган бер оятсыз, ялангач фикер килде.

— Ярый, сеңелем, хуш Тик минем бер сүзем бар, — дип кызның халат җиңенә кулын тидереп, почмаккарак алып китте.

— Зөлфа, мин моны әйтергә дә оялам, әйтмичә дә кала алмыйм. Беләсеңме... мин бит тиләләнеп, сине үпкән идем. Иренеңә дә кагылдым бугай.

— Соң, — диде кыз пырдымсызлана башлап Искә төшерүне ошатмады бугай.

— Мин теге атнада гына Угандадан кайттым. Врачлар тикшерделәр... Сездә СПИД чире булу ихтималы бар, диделәр.

— Нәрсә? — дип кычкырып җибәргәнен сизми дә калды кыз.

Күзләрендә янә учак утлары уйнады. Йөзендәге каны аяк табаннарына төште.

— Сеңлем, кычкырма. Бу хакта иптәшләрең ишетмәсен. Эшсез дә, ирсез дә калырсың. СПИД — сулыш алу, үбешү аша да бик тиз күчә торган чир ул.

— Йа, Ходам, ник мине шулай каргадың? Миңа шул гына җитмәгән иде. Ник, әти-әнинең сүзен тыңламыйча, авылдан чыгып киттем?! — дип көчле куллары белән битен каплады кыз.

СПИД турында лекцияләр укып, китаплар таратып, сатучы халкын куркытып бетергәннәр иде. Тамак тук җирдә авырулача шикләнү, шөбһә куян кебек үрчи Булмаган авыру эзләү чире Зөлфаны да әйләнеп үтмәгән иде. Ул үзен биюче Рудольф Нуриев кебек ябыгып, хәлсезләнеп, үлем түшәгендә яткан хәлдә күз алдына китерде Әнисе җылый-җылый, агач кашыктан су каптыра. «Балакаем, ник тыңламадың сүземне, китмә авылдан, эшләп йөр балалар бакчасында, дип күпме үгетләдем. Ана сөте белән кермәсә, керми икән ул тәртип... Акылың югалды...»

Вакыйга үсеше янәдән Рәүф көткәннең, теләгәннең нәкъ киресен, детектив фильмнардагы юнәлешен алды.

Зөлфа әзмәвердәй таза егете белән аны өенә кадәр озата барды. Трамвайда бергә килделәр, тукталыштан майламаган күн итектәй шыгырдап торган салкын карны бергә изделәр. Шактый барасы иде.

Зөлфа егет белән уртак танышлары, туган авылларында үлгән, яңа туган кешеләр турында гәпләшеп барды. Карт буйдак әллә бар, әллә юк аның өчен.

Рәүфнең аркасы бер тирләде, бер суынды. «Блатной компаниягә керү бәясе бер сум, чыгу мең тәңкә дип юкка гына әйтмиләр икән «Кибетче хатын-кызның явыз кырмавык булуын белә торып, үз башыма бәйләндем Карт тәре, кырыкка үрлисең, ә акыл бер шешә катыклык та юк. Мишәр малае, кыйнап димим, үтереп ташласа да, эт тә таба алмас үзләрен, эзләренә төшсәләр дә, кешене көнчелек юлында хәл кылган өчен ике-өч елдан артык бирмиләр бугай», дип, юл буе үзен каһәрләп, әрләп, ник туганына үкенеп кайтты.

Фатирын кулының калтыравын басарга тырышып, көчкә-көчкә ачып, эчкә үтте, тегеләргә борылып, керегез, дигәнрәк ым какты, алары Хуҗа Насретдин ишәге төсле «Юк, рәхмәт» мәгънәсендә баш селкегәч, ашыга-ашыга йозакларны бикләде.

Зөлфаның үз кайгысы кайгы иде «Кемнән йоктырдың әлеге зәхмәтне», — дип сорасалар, бу адәм өтеген каян табасы икәнен белеп калырга кирәк иде аңа.

Икенче көнне нәкъ кичәге вакытта Рәүф янәдән кибет ишеге янына килеп орынды Сакта ямьсез, өлкән яшьтәге апа тора иде бүген.

— Зөлфаны чакырыгыз әле?

— Зөлфа, тәнә гелә сине чапылдаткан мужигың сорый, — дип кычкырды ул иләмсез тавыш белән.

Кыз акрын гына ишек янына килде Кичәге ваемсызлыкның эзе дә юк. Йөзе тартылган, ябыккан, өзелгән өмет диярсең.

Рәүф Зөлфа янына үтеп колагына пышылдады:

— Мин кинога билет алган идем Нишлибез?

— Кит янымнан, оятсыз өрәк. Күрәсем дә килми.

— Ашыкма әле Фильм алдыннан СПИД турында документаль фильм күрсәтәләр, ди.

Ишектә сакта торган апа «Каршы килмә, Зөлфа бәгырем. Билеңдә үз кулың торганчы, ир-ат кулын салсын»— диде, хихылдавыннан туктамыйча.

Үзен инде чын-чынлап XX гасырның иң әшәке чирен йоктырган кешеләр рәтенә керткән кыз кармакка капты.

Табигый ки, йогышлы авыру турында пәм-мим сүз юк иде кинода Атышу үтерешү үбешү талау хакында иде фильм «Значит, мине алдаганнар», — дигән булды Рәүф. кызның кулын учына алып. Зөлфа тыпырчынгандай итте «Бир кулны» — дигән булды Ә үзенең авылда чыныккан көчле кулы, җегәрең югалта барып, бөтенләй йомшап, кайнарланып, эреп бетте Рәүфнең учларында, тез башында...

— Матурым, безнең язмышлар бер инде. Чирне тагын кемгәдер йоктырганчы, икебездә генә калсын. Чык миңа кияүгә!

Аргумент бик көчле иде.

— Ә балаларыбызга йокса, — диде тәмам югалып калган Зөлфа.

— Миндә нәселдән нәселгә күчми торган сорты. Высший сорт Негрский

— Үзең кая эшлисең хет?

— Эшлим дип. Дамелля мин.

— Нинди мулла тагын. Миңа шул гына җитмәгән.

— Юк ла, укытучы мин. Югары мәктәптә эшлим. Аны эш дип санап булса.

— Нәрсә укытасың инде?

— Нәрсә дип, элек Маркс белән Ленинны мактап, хәзер шуларны ук эттән алып эткә салып тамак туйдырам.

— Бәйләнер кешеләрең булуы әйбәт икән Миңа теш кайрап йөдәтмәссең. Хатының кая? — дип сорауны кирәк тапты Зөлфа.

— Үлде

— Чирләпме?

— Әйе, СПИДтан үлде.

— Мине дә үтерәсең киләме?

— Кояшым син, аем син, ачылмаган роза гөлем син, Зөлфа, без бергә булсак кына, СПИДны да, башка дошманнарны да җиңеп чыга алачакбыз. Безнең чәчләребез бәйләнгән, язмыш бу

Зөлфа дуслары, туганнары белән киңәш-табыш иткәндәй булды. Җавап бер иде:

— Тешең барда тешләп кал. Күпме тупайда сөрсеп ятырга була. Чык! Чат ябыш!

Кибетче халкы ике тәүлек биеде туйда.

Әзмәвердәй авылдаш егете ияген әле бер җилкәсенә, әле икенчесенә куеп, һәйкәлдәй катып калып, хромкада уйнады

Соңрак Рәүфнең Угандага түгел, гомумән чит илләргә аяк та басмаганы ачыкланды

Шактый вакыт тату гына яшәгәннән соң, Рәүф әйтеп куйды

— СПИД белән яхшы каптырдым мин сине. матурым Абзаңда баш бар. укыган кеше — укыган кеше инде ул

— Шулайрак булды шул...

— Миндә бу каһәр суккан чир булуга чын-чынлап ышандың бугай

— Нишләп алай юрыйсың.

— Соң беренче көнне үк өемә чаклы озата бармас идең Соңыннан хөкемгә тартсалар кайда яшәгәнемне беләсең килде. — диде Рәүф. чыраена җиңүче кыяфәте чыгарып

Зөлфа чирагын уздырмады Рәхәтләнеп җәелеп көлде

— Юләрем син Авыл кызлары дигәч тә безне чеп-чи дураклар дип саныйсыз Сүзеңә ышанмадым. үзең ошадың Озата баруымның сәбәбе бик гади Фатиры бармы булса, үз ачкычы белән керәме, әллә ишекне теге яктан ачалармы... Шуны беләсем килде

Хәзер инде Рәүфнең авызына салынып төшү чираты җитте Ни булса да, йогышлы вируска яңа гаиләнең башкодасы булырга туры килде

Бу фани дөньяда биш миллиардлап халык СПИДны каһәрләп яшәсә, шул саннан аңа икесе — Рәүф белән Зөлфа рәхмәтле булыр.

# Йотылып укыйм

Мин үзем Башкортстандагы Дуван районы, Өлкенде авылында туып-үстем. Бу авыл татар халкына танылган шагыйрь Әхмәт Ерикәйне бүләк итте. Һөнәрем буенча китапханәчемен. Язмыш мине Дөбъязда да яшәтте, Казанда да көн күрдем. Анда фатир ала алмагач, Югары Осланга китеп бардым. Тәзелештә бер ел эшләп, йорт-җирле булдым. Пенсиягә кадәр соңгы ун елымны янә Казанга йөреп, төгәл машиналар заводында эшләдем.

Болары — сүз уңаеннан гына. Әйтәсе сүзем «Мәдәни җомга» турында. Озак еллар «Социалистик Татарстан», «Казан утлары»н алдырдым. Хәзер дә «Мирас», «Казан утлары» журналларын, «Республика Татарстан» гәзитен алабыз. Әмма «Мәдәни җомга» кебек гәзитне укыганыбыз юк иде. Мин аны башыннан ахырына кадәр бер тында йотылып укыйм. Рәхмәт сезгә, «Мәдәни җомга»ны чыгаручылар. Сез мәдәниятнең, әдәбиятыбызның бөтен якларын да яктыртасыз. Рәсми материалларга урын аз бирәсез, ә нигә аларны «Мәдәни җомга»га тутырырга, алар өчен махсус гәзитләр бар бит. Теге яисә бу әдип турында моңарчы укучы белмәгән мәгълүматлар бирүегез дә бик әйбәт. Мин, мәсәлән, Таҗи Гыйззәтне драматург дип кенә белә идем, ә ул бик катлаулы чорда Язучылар берлеге рәисе дә булып торган икән. Олы шәхесләр турындагы мондый детальләр аны укучыга якынайта гына бит.

Менә безнең гаилә Җәмил Зәйнуллин турында күбрәк белергә теләр иде. «Точмаш»та мин бу галимнең авылдашы белән бергә эшләдем. Ул Җәмил энекәшнең әтисен шул кадәр ихтирам итә иде; авыл советы секретаре булып эшләгәндә динебезне тыйган иң авыр чорда да ул авылдашларын үз өенә җыеп дини бәйрәмнәр үткәрә, намазлар укыта торган булган.

Мәдәният өлкәсендәге зур кешеләр, иншалла, онытылмас. Гыйнварда шундый танылган кешеләрнең берсе — Исмәгыйль Рәминең туууына 100 ел тулды. Аның турында «Заман» гәзите генә мәкалә бастырды. Бу хәлгә күңелдә зур үпкә калды.

Гәзитегезне башта Казанга килеп ала идем, сентябрьдән өйгә килә башлады. Киләсе елда да аннан аерылмабыз, иншалла.

**Рамил ХӨРМӘТУЛЛИН.**
Югары Ослан.

# Гыйльми шура кирәк

**«Мәдәни җомга»да тарихи язмалар күп басыла. Фәнни материаллар, халкыбызның тарихы, археологик табышлар, тел тарихы һ.б. турындагы мәкаләләрдә төгәлсезлекләр китмәсен өчен, минемчә, редакция каршында, редколлегиядән тыш, гыйльми шура эшләргә тиеш. Анда фәннәрнең барлык тармаклары буенча киң мәгълүматлы белгечләр билгеләнсә, гәзитнең дәрәҗәсе дә, тиражы да артачак кына.**

**Фирдәүс САЛИХОВА,**
Казан дәүләт педагогика университеты доценты.

# Изге сәфәргә озаттык

***17 октябрьдә Арчадан Мәккә шәһәренә бер юлаучы сәфәр чыкты. Ул, хаҗга баручы башка мөселманнардан үзгә буларак, самолетка утырып турыдан-туры Согуд Гарәбстанына очмады, элекке дәрвишләр кебек, берни дә өзерлексез, кайда җәяү, кайда атка яисә машинага, поездга утырып юлын дәвам итү нияте белән чыгып китте. Халыкара классы парапсихолог, халык табибы Раушан Шәмсемөхәммәд улы Салиховның аркасында җыйнак кына юл биштәре: анда иң кирәкле әйберләр — юлъязмалар өчен ике дәфтәр, каләм, юл кирәк-яраклары һәм кечкенә генә дөнья картасы, шуларның да иң кадерлесе — әти-әнисенең изге теләге. Раушан Мәккәгә кайчан, елның кайсы фасылында барып керәсен дә белми, хәтта анда барып җитәр өчен акчасы да җитми, төгәен маршруты да юк. Шулай да ул Ташкент аша Төркиягә китәргә, андагы Диния нәзарәте аша Согуд Гарәбстанына барырга ният итә. Алла кушса, кайтыр юлда Чечен Ичкериясенә керер идем, ди ул.***

***Раушан Салиховның максаты — юлда барганда төрле шәһәр-авылларга тукталып, кешеләрнең тәнен һәм рухын дәвалау, мөэмин-мөселманнарны Ислам кануннарыннан тайпылмыйча яшәргә өндәү. Киткәндә ул «Мәдәни җомга» редакциясенә кереп намаз укып чыкты, гәзитне юлда укырга дип үзе белән алып китте. Җир-анабыз, анда яшәүче халыкларның җан-тән чисталыгы өчен тырышучы бу фидакарь җанга изге сәфәр телибез.***

***Рәсимә ХАЛИКОВА.***

# Гармун алыйк әле, дускай

*Кайчандыр «Казан кичләре» дигән җыр бик популяр иде:*

*... Ак булып, саф булып истә калсын*
*Казанның кадерле кичләре.*

*Әле генә гөрләп узган «Казан кичләре» фестивале дә тамашачылар күңелендә бик озакка истә калыр. Күптәннән татар сәхнәсендә күрелмәгән тамаша! Мүкләнеп беткән күңелләрне дә хисләндерергә, борчулы уйларыңны оныттырып шатланырга, дөньяга ник туганнарына үкенеп йөргәннәрне дә көлдерергә мәҗбүр итәрлек бер кичә. Бу — «Гармун-шоу» кичәсе иде.*

*Зал тулы түгел иде. Тулы булудамыни хикмәт! Килгән һәр кеше килмәгән биш кеше өчен кул чаба. Килми калганнар үкенсен.*

*... Сүз остасы сөйли тора, аңа кушылып гармун моңнары агыла башлый, ул да түгел, зал җырларга күмелеп китә, дәртле биюләр сәхнәне дер селкетеп ала. Артистлар сәхнәгә генә «сыймыйча» залга да таралалар. Тамашачылар — артист, артистлар тамашачы булып китә. Әйтерсең лә, татар халкының иң матур йоласы булган «аулак өй»гә җыелганнар.*

*... Алмаз Хәмзин «кызык хәлләр» сөйләп тамашачыны көлдереп тора, ә Кирам Сатиев халык көйләренә вариацияләре белән залны моңга күмә, Рөстәм Вәлиев тә аңа килеп кушыла.*

*.. Гармун алыйк әле, дускай,*
*Гармун уйнатыйк әле.*
*Яшь чактагы көй-моңнарны*
*Кабат уятыйк әле.*

*Кәүсәрия Сираҗетдинова көянтә-чиләкләрен күтәреп, «чишмә буйларына төшеп» очынып-очынып бии, ә Хәлим Җәләлов шигырьләр укып ала. Җырчылар Искәндәр Биктаһиров, Мирсәет Сөнгатуллин, Айдар Фәйзрахманов, Фердинант Сәлахов халык җырларын күңелнең түренә җиткерә торалар: «Көйсез-моңсыз үткән көннәр яшәлмәгән көн бит ул». Менә сәхнәгә бер «карчык» килеп чыга, бер яшьлектә, бер картлыкта дигәндәй, туздырып бии дә башлый. Башка артистларны да «тынычлыкта» калдырмый. Бөтен сәхнәгә «җан кергәндәй» була. Бу карчык дигәнебез Рәсимә Мөхәммәтҗанова икән. Айдар Фәйзрахманов үзенең «аулак өй» гадәте буенча тагын халык арасында. Дәртле җырларына гармун чыңнарын да кушып, үзенә генә хас җитезлек белән «зал күңелен күреп йөри». Халык түзәмени? Аңа кушылып җырлап та, биеп тә китә. Сөйкемле егетләрдән торган «Заман» төркеме җырларны яшьләргә хас шаянлык, нәзакәтле дәрт белән башкарып, йөрәкләрне яулый тора, ә Рөстәм Вәлиев, җае туры килгән саен, эреле-ваклы дистәләгән гармуннарын тартып «сайрата» гына. Аңа берьюлы берәү генә түгел, өчәр гармун да «буйсына» (әкияттәге «сихерләгән» гармуннармени?) Равил Габдрахманов сәхнәгә менеп җиткәнче үк «тузаннар очыртып» биеп китә. Аңа башка биючеләр дә кушылгач, залга сибелеп бар халыкны аякка бастыралар. Бу залда бии белмәүче кеше юк та икән. Шау-шу, уен-көлке. Гармуннар тынып тормыйча, «чын безнеңчә милли көй» сузалар. Аларга тагын җырчылар кушыла:*

*Җырламый да икмәк үсә,*
*Җырлы икмәк тәмлерәк,*
*Җырламый да яшәп була,*
*Җырлап яшәү ямьлерәк.*

*Тагын мәзәкләр сөйләнә. Музыкантлар Рәшит Сабиров, Марат Хәснуллин, аталы-уллы Идрис һәм Гадел Сабирҗановлар кичәгә үзенчәлекле ямь өстәп торалар.*

*Кичә барышында тамашачылар еракта калган туган авылларына, гармун тавышлары яңгыраган кечкенә урамнарга, Сабантуйлар гөрләп торган тугайларга, җырлы-биюле, уен-көлкеле дәртле яшьлекләренә әйләнеп кайттылар.*

*Кичәне, гомумән, фестивальне оештыручы һәм алып баручы Алмаз Хәмзингә кичәгә җыелган артистларның да, тамашачыларның да рәхмәте чиксез иде. Аның тырышлыгы нәтиҗәсендә концерт зур бәйрәмгә әверелде.*

***Энҗе ГАЛЛӘМОВА,***
*эшче.*

***P.S. «Мәдәни җомга»ның 9 нчы санында бу фестиваль хакында «Гармун-шоу»ның шавы кайда?» дигән бер басма басылган иде инде. Анда сүз «Гармун-шоу»ны оештырудагы кайбер җитешсезлекләр турында да барган иде. Ләкин укучыларыбыз арасында «Гармун-шоу»га карата башка караштa торучыёлар да бар икән. Хәер, кем әйтмешли, зәвык турында бәхәсләшмиләр бугай ич...***

# «Чабата»лар югалмасын

Мәдәният министрлыгы каршындагы татар дәүләт фольклор үзәгенең төп эшләреннән берсе — фольклор җыю. Без халык авыз иҗатын тупларга үзебезнең районнарга да, читт өлкәләргә дә чыгабыз. Үзәгебезнең фонды быел Арчада, Әтнәдә, Азнакайда, Тукай районының «Татарстан» совхозында язып алынган материаллар белән тулыланды. Экспедициядә фольклор үзәге хезмәткәрләре Д.Галиева, Л.Мөхәммәтшина, Л.Якупова, А.Харисова катнашты. Быел алып кайткан материаллар арасында мөнәҗәтләр, бәет, Коръән сүрәләре, фатихалар, «Йосыф китабы» кәе, Исламны кабул итү турындагы бәет һ.б. күбрәк урын алды. Рухани музыканың күплеге диннең кабат җанлануына һәм фольклор катламының өлкән яшьтәге кешеләребез күңелендә саклануына бәйледер дип уйлыйбыз.

Биектау, Әтнә районнарында язылган материаллар башлыча архегеография жанры белән бәйләнгән — җырлы-биюле уеннар, биюләр. Әлеге районнарда «Чабата» биюе, «Күршеләр», «Чишмә буенда», «Җиләкле җәй», «Сөлге чигәм» дигән биюләр язып алынды.

Дөбъяз авылында исә экспедиция Сабан туеннан соң уздырыла торган «Тау башында» дигән бәйрәмне язып алган. Ул бәйрәмдә хатын-кыз белән бала-чага гына катнаша икән. Алар азык-төлекне кебигать кочагында өзерләп, аны кешеләргә өләшеп, җырлы-биюле уеннар оештырган.

**Роза ИСХАКОВА-ВАМБА,**
татар дәүләт фольклор үзәгенең төп гыйльми хезмәткәре.

# УНӨЧЕНЧЕ БИТ

## Көлсәң — көл, көлмәсәң — ела!

**Әхәт САФИУЛЛИН**

# ВАРИАНТ

Соңгы вакытларда ара-тирә генә очрашкалый торган таныш-белешләр аптыратып бетерде. «Ни булды?!» — дип, гаҗәпләнеп, җанны ашыйлар.

Бетәшерсең дә! Үзләре минем урында булсалар, нишләрләр иде икән? Аны мин дә болай килеп чыгар дип уйлаган идеммени?! Ә бит барысы да шатлыклы хәбәрдән башланды, югыйсә...

Шулай рәхәтләнеп, бернинди кайгысыз гына яшәп яткан көннәрнең берсендә, быел яңа йорттан фатир алачагымны хәбәр иттеләр. Шуңа күрә эшемнән:

— Гөлфирә жаныем, быел яңа фатирга күчәргә җыен! Чиратым җитте! — дип очынып кайтып кердем.

Шатлыгыннан хатыным да чалкан ава язды. Тик, әле дүрт кенә ел элек алган ике бүлмәле фатирыбызны күздән кичереп чыктым да уйга калдым. Туктале, нигә соң әле безгә икенче фатир?! Безгә монысы да бик җиткән бит. Инде менә, зур акча төртеп булса да, телефонын да керттердек. Рәхәтләнеп яшибез ләбаса! Ике балабыз бар, Аллага шөкер, саулыгыбыз ягы да әйбәт. Тагын ни кирәк инде безгә?!

Шулай уйланып-уйланып тордым да, авызын ерып каршымда басып торган хатынымнан:

— Ә нигә безгә ул яна фатир? — дип сорадым.

Кыскасы, шушы сүздән соң төн йокыбыз качты, хатын белән икебез дә кара кайгыга сабыштык. Уйланабыз, баш ватабыз. Китәсе генә килми бит шушы ияләшкән фатирдан! Шул ук вакытта яңасын да аласы килә...

— Карале, Гөлфирә, — дидем мин шулай бер мәртәбә төнге өчләр тирәсендә. — Минемчә, безгә бу фатирны да үзебезгә калдырып, безнең оешмадан өч бүлмәлене түгел, берләне генә алырга кирәк! Ул чагында киләчәктә Илдарыбыз да фатирлы булачак, кечесе дә... Ә?

— Мин бу турыда уйлап арыган инде, — дип җавап кайтарды хатыным, авыр көрсенеп. — Менә шуны ничек эшләргә диген син. Ундүрт яшьлек малаебызга да киләчәктә бер генә бүлмәле булса да фатир кирәк ич, дияргәме?

— Ә монысын аның исеменә яздырсак? — дидем мин икенче төннең кыл бер уртасында. — Ул чагында без үзебезгә тагын ике бүлмәлене ала алабыз! Кешеләр шулай эшләштергәлиләр, ди. Ишеткәнем бар...

Бер-ике сәгатьтән хатыным тагын телгә килде:

— Тагын бер вариант бар барын... Белмим, син ничек карарсың...

— Йә, әйт әле, әйт! — дидем. — Нинди вариант ул? Уйлап карарга кирәк...

— Безгә аерылышырга кирәк, — дип елап җибәрде Гөлфирәкәем, мине кочаклап.

Хәер, елап җибәрми хәлең дә юк. Егерме елга якын бергә яшә дә!

— Син нәрсә?! Ничек инде ул аерылышырга?! — дип сикереп торганымны сизми дә калдым.

— Ничек, ничек... Менә шулай. Тотарга да аерылышырга! Аннары, син фатир алгач, яңадан кавышырга...

Ай буена уйланып йөрдем.

— Йә, берәр нәрсә уйладыңмы син, юкмы? — дип сорады миннән бер төнне хатыным.

— Шулай кирәк булгач, нишлисең инде... Мин риза, — дидем мин. — Кулга керәм дип торган фатирны ычкындырып булмый бит инде...

Кыскасы, килештек. Һәм икенче көнне гариза белән судка киттек. Аерылышабыз булгач, аерылышабыз, дип, анда яхшы гына шаулашып та алдык.

Бу бюрократия дигәннәре безнең судларга да килеп җиткән икән — уйларга вакыт биреп, борып җибәрделәр.

Алай да, көн саен барып тавыш күтәрә торгач, ниһаять, аерылыштык. Хатын балалар белән өйдә калды, мин «убшый»га күчтем. Күчтем дә фатир көтә башладым.

Мин дә, хатын да кызыксынучыларга: «Тормыш булгач, менә шулай да килеп чыга икән ул», — дип кенә җибәрәбез.

И-и, бу кеше дигәнеңнең җитешмәгән җире юк, валлаһи! Бераздан халык арасында: «Алар юри генә аерылышканнар икән», — дигән хәбәр таралып өлгермәсенме?! Фатир өчен генә, янәсе. Шуннан соң, күргән-белгәннәр дә, туган-тумачалар да очрашкан чакларда ничектер серле итеп елмая башладылар. Имеш, беләбез, беләбез ни өчен аерылышканыгызны!

Аптырадык та калдык. Болай булыр дип уйга да китермәгән идек, әлбәттә. Андый-мондый сүзләргә урын калдырмас өчен хәзер төннәрен дә күрешмәскә сүз куештык.

Ярый әле убшыйдагы бүлмәдәшләр бик яхшы егетләр булып чыкты. «Тормыш булгач, менә шулай да килеп чыга икән ул», — дип бер аңлатып биргәч, артык сораулар белән башка аптыратмадылар.

Хәер, аптыратуын аптыратмадылар — бу абзый кеше үзе генә калып газапланмасын, дигәннәрдер инде — мине гел үзләре белән чыккаларга кыстый башладылар. Нишлисең, бер-ике тапкыр алар белән театрга, ике-өч мәртәбә киногa барып кайтырга туры килде. Монысын яхшы да эшләдем бугай әле — таныш-белешләр күрсен, безне чынлап аерылганнар икән дип уйласыннар. Күптән шулай эшләргә кирәк иде миңа!

Тик бер көнне эштән кайтып килгәндә, күрәм, убшый ишеге төбендә хатынның сеңлесе басып тора. Мине көтүе икән. Хатынымнан хат кисәге алып килгән.

Газиз хатынымның шул хатын укыгач, күз алларым караңгыланып китте. Кайчан һәм нинди кинотеатрларга барган булсам, барын да бәйнә-бәйнә теркәп куйган гүзәлкәем. «Кара аны, Әсәдулла, киләчәктә дә менә шулай койрыгыңны күтәреп чаба торган булсаң, үзеңә үпкәлә! Аерылышуыбыз шушы булыр», — дип бетергән иде Гөлфирәкәем хатын.

Чәчләрем үрә торды. Аерылышу хәлләрен Ходай күрсәтмәсен, мин әйтәм. Болай да изаланып беттем бит инде!.. Балдыз безнең хәлдән хәбәрдар кеше, аңа бу кино-фәләннәргә юри генә, кешеләрне ышандыру өчен генә йөрүемне аңлаттым. Сөйләп бир апаңа, дим, Алла сакласын, тайгак юлларда йөримме соң?!

Алай да бер ял көнне: «Монда күрше йортка бер танышыбызга гына кереп чыгабыз, өйдә, җитәр сиңа тәмәке ашап ятарга!» — дип бик кыстагач, тагын иярдем егетләргә.

Аннары... Бер бик зур гына фатирда утырганыбызны хәтерлим. Кайсыдыр бер кызның туган көне булдымы ул, әллә ниндидер бер бәйрәм хөрмәтенә җыелганнар идеме, шайтан белгән шунда... Кыскасы, икенче көнне иртә белән уянып китсәм, шаклар каттым: убшый караватында түгел, өйдә, түшәктә ятам! И-и, мин әйтәм, Аллага шөкер, өйгә кайтканмын икән! Сөенечемнән хатынымны үбәргә тотындым. Тик ни хәл бу?! Минем хатыным кап-кара чәчен менә шулай сап-сарыга кайчан буяткан соң?! Сорарга дип күземне ачып карасам — йә Аллаһы — минем Гөлфирәм түгел ич бу!

Шулай да иркәләгәнне бик яратучан нәрсә икән, кысып алды да нишләтергә белми. Әй, чибәр дә үзе! Унсигез-унтугыз яшьләр чамасы гына үзенә. Иркәле дә белә икән, торып, җәлт кенә аракы да салып алып килде бу. Пәрәме караваткa! Башыңны төзәтеп җибәр, ди.

Ул көнне эшкә дә бармадым. Аракы белән яшь чибәр бергә туры килсә, тәмам акылны ала икән ул... Эшкә килмәгән өчен шелтә белдерделәр.

Бераздан, прогульщик, дип, эшемнән чыгардылар. Аннары, — бәла берүзе генә йөрми, дип бик дөрес әйтәләр икән, — шайтан алгыры — теге хатынның төрмәдәге ире кайтты.

Кыскасы, айнырга туры килде. Фатир очты, хатыным белән аерылышуыбыз мәңгелек булып чыкты. Хет ишек катында гына булса да яшәрмен дип тә әйтеп карадым, юк, кертмәде. Бар, кайда йөрсәң, шунда бар! — дип кенә җибәрә. Теге чибәрең янына олак, янәсе.

Менә хәзер мин күк белән җир арасында селкенеп йөрим. Бетәшү түгел, бетәрсең дә монда...

Хатынмы? Бер кешене йортка кертте. Чөкердәшеп яшиләр безнең ике бүлмәле фатирыбызда.

Кая барышыммы? Туктале, мин әйтәм, шул иске фатирыбыз тәрәзәсендәге утларны гына булса да карап кайтыйм әле...

Эротиканы табигать уйлап тапкан, яки Малайны сөннәткә кем утыртыр?

Әйе, әйткән-язган идек: эротиканы табигать уйлап тапкан. Әгәр шулай булмаса, җир йөзендә тормыш дәвам итмәс иде, буыннар артыннан буыннар тумас иде, җирдә мәхәббәт дигән бөек хис булмас иде. Табигатькә рәхмәт! Эротика да, мәхәббәт тә — табигатьтән.

Ә бу эротик кишерне фотохәбәрчебез Ә.Шәфигуллинга гозит укучыбыз Нажия ханым китергән.

## ПАР(О!)ДИЯ

**Нияз АКМАЛ**

* * *

*Әллә инде, кәккүк булмак булып,*
*Кеше гомерен санаргамы?!*
*Әллә буылып кан йөткергән*
*Даһи булып карааргамы?*
*Ә шулай да*
*Нишләргә соң?!*
*«Кисекбаш»ны язган хода*
*Качкан сөйгән дөньясыннан.*
*Меңәрләгән зәгыйфь кошлар*
*Очкан шигъри оясыннан.*
*Хәбир ИБРАҺИМ.*
*«Нишләргә?»*

**Әллә инде елан булып,**
**Бүре булып карааргамы?**
**Әллә, юл чатына чыгып,**
**Юлчыларны таларгамы?**
**Чыктым җиде юл чатына,**
**Очтым кәккүк оясыннан.**
**Кердем базар дөньясына**
**Коммунизм дөньясыннан...**



● Сүзсез.

Ю.КОСОБУКИН рәсеме.

## Алай да була...

### Сәнгать уңышы

Кием тегүче янына килгән берәү ачуланып әйткән:

— Сез миңа нинди көчтүм-чалбар тектегез, шайтан алгыры? Бәтен кеше миннән көлә!

Тегүче исә, шатланып, кычкырып җибәргән:

— Һа! Бу бит минем беренче сәнгать уңышым! Элек теккән көчтүмнәремне кигәч, барысы да елыйлар иде...

### Кем кемнән туган

— Әни, кешенең маймылдан тууы дөресме?

— Дөрес, улым.

— Әйтәм аны, маймыллар хәзер бик сирәк калган...

**Хәлиф КУРБАТОВ,**
филология фәннәре докторы.

# ПРОКРУСТ ЯТАГЫННАН КО

Мәрмәрә университетында (Истанбул) төрки телләрнең алфавитларына багышланган махсус симпозиум үткәрелдә (1991 ел, 18-20 ноябрь) Анда элекке СССРның барлык төрки республикаларыннан да телче галимнәр чакырылган иде (гәрчә аларның бик күбесе язу теориясе — алфавит һәм орфография — бу-енча белгечләр булмаса да). Алар симпозиумның йомгаклау утырышында барлык төрки телләр өчен менә мондый алфавитны кабул итәргә дигән тәкъдимгә кул куеп таралыштылар (укучыга аңлаешлы булсын өчен мин биредә квадрат җәя эченә алып ул графемаларның кириллицада нинди хәрефләргә туры килүен дә өстәп язам)

a [а], b [б], c [җ], ç [ч], d [д],
e [ə, е], ä [ə], f [ф], g [г], ğ [ғ],
h [һ], x [х], ı [ы], i [и], j [ж],
k [к], q [қ], l [л], m [м], n [н],
ñ [ң], o [о], ö [ө], p [п], r [р],
s [с], ş [ш], t [т], u [у], ü [ү],
v [в], w [w], y [й], z [з].

Күренгәнчә, бу — хәзерге төрек алфавиты, тик аңа төрекләрдә булмаган (ләкин күпчелек төрки телләрдә булган) фонемалар (төп авазлар) өчен биш хәреф өстәлгән.

Бу төр алфавит. симпозиумның йомгаклау карарында әйтелгәнчә, «төрки кавемнәрнең культура берлеген ныгыту» максатын күздә тота. Ләкин, билгеле булганча, кайсы да бер тел алфавиты системасын икенче телгә (гәрчә ул телләр арасында уртаклыклар байтак булса да) китереп салу («Прокруст ятагы»на яраклаштыру*) тора-бара бу телнең әдәби әйтелешен боза (аңа башка бер тел акцентын алып керә) яки уку-язу ысулын кыенлаштыра. Хәер, төрекләр безне «татар» дип түгел, «шимали төрекләре» (ягъни «төньяк төрекләре») дип кенә атыйлар. Алар өчен элекке СССРның башка төрки халыклары мөстәкыйль халыклар түгел, барысы да — төрекләр. Мәсәлән, «Би-би-си»нең бер тапшыруында (1994 ел, 6 апрель) Төркиянең хәзерге Президенты Сөләйман Дәмирәл ап-ачык итеп болай диде: «Урта Азия халыклары һәм төрекләр бер үк телдә сөйләшә». Димәк, үзбәк, каракалпак һәм кыргыз телләре төрек теле белән бер үк тел булып чыга. Инде дә каракалпак һәм үзбәк телләренә бик тә якын татар әдәби теле дә, алайга китсә, төрек теле. Чынлыкта исә төрек телен татар кешесе сүзлек ярдәменнән башка аңлый алмый. Бу юл белән китсәң, славян телләре төркеменә кергән поляк яки чех телләре дә — урыс теле белән бер үк тел. Ләкин алай дип әйтергә беркем дә батырчылык итми, һәм ул халыкларның һәркайсының үз язу системасы бар. Әлбәттә, төрки телләр хакында әлеге караш бер бүген генә башланмады: укымышлы кешеләрнең хәтерендә булыр, Бакчасарайда 1883 елны «Тәрҗеман» гәзитен чыгара башлаган Исмәгыйль Гаспралының (1851-1914) шигаре менә нинди булган: «Телдә, фикердә, эштә берлек!» Татарстанда нәшер ителә торган «Заман» гәзитенә бу сүзләр лозунг рәвешендә куела («Zaman — Татарстан» — 1994 ел, 16 апрель). Фикердә, эштә берлек (дөресрәге, бердәмлек) булырга мөмкин, ләкин телдә түгел.

«Телдә берлек» — бу инде гасырлар буе халкыбыз, бөек әдипләребез тарафыннан эшкәртелгән гүзәл яңгырашлы һәм бай телебезне санга сукмау дигән сүз. Моны үз вакытында даһи шагыйребез Габдулла Тукай тиз күреп алган: «Тәрҗеман»ның без татарларга галәкәсе (бәйләнүе) ботенләй юктыр. Чөнки, өүвәлән, аның теле — безнең телемезгә бөтенләй кире бер Кырым теледер. ... Без моннан егерме биш ел борын, ак күмәч булмаганга.ипи ашаган... төсле генә, «Тәрҗеман»ны укыдык һәм ихлас багладык. Инде бөтенләй үзгәрдек!» Әлбәттә, Тукайның бу әйткәнендә сүз турыдан-туры телнең үзе турында бара, ә язу системасы турында түгел. Ләкин башка тел язу системасы аша әдәби телнең тора-бара зәгыйфьләнүе күн кебек ачык — без аны кириллица куллануда байтактан күреп киләбез.

Әлеге симпозиум карарына икенчеләрдән булып кул куйган милләттәшебез Надир Дәүләт (Истанбулның Мәрмәрә университетында төрки халыкларны өйрәнү институты профессоры), төрек язуы системасының татар әдәби теленә ярап бетмәвен төшенеп һәм шулай ук 1993 елның мартында Төркиянең Анталия шәһәрендә төрки дәүләтләре һәм халыкларының корылтае карарын да искә алып булса кирәк, татар әдәби телендә еш кулланыла торган [ә] фонемасы өчен өске ике төрткеле «а» хәрефен үзебезнең «ә» хәрефенә алыштыра һәм «Ватаным Татарстан» гәзитендә (26.XI.93) «Татарга латинга нигезләнгән яңа әлифба кирәкме?» дигән мәкалә урнаштыра. (Шунысын да искәртеп үтик, «әлифба» сүзе бүгенге татар әдәби телендә «алфавит» мәгънәсендә түгел, укырга-язарга өйрәтү өчен чыгарыла торган дәреслекне, урысча «букварь» дигәнне аңлата). Надир Дәүләт ул мәкаләдә бездәге кнаклаут (һәмзә) авазыннан башка барлык фонемаларга (төп авазларга) да кирәкле хәрефләрне мисаллары белән күрсәтә («һәмзә» фонемасы төрек телендә юк, алар язуында кулланылган өске өтер — апостроф — сүз тамырына яки нигезенә ялганган кушымча алдына куела). Менә Надир Дәүләт мәкаләсендә татар әдәби теле өчен дип әйтелгән алфавит:

"a" - aqıl, "b" - batır, "c" - ciñel, "ç" - cinbarlıq, "d" - dərt, "e" - ezlekle, "ə" - əhəmiyət, "f" - fəlsəfə, "g" - gərçə, "ğ" - ğərəpçə, "h" - həm, "x" - xərəkət, "ı" - ızğış, "i" - iske, "j" - jargon, "l" - lider, "m" - məsələ, "n" - nigə, "ñ" - miña, "o" - osta, "ö" - östenlek, "p" - paklıq, "r" - rizalıq, "k" - kamil, "q" - qərar, "s" - süz, "ş" - şöbhə, "t" - telək, "u" - uyanu, "ü" - ürnək, "v" - vaza, "w" - bərəw, "y" - yarış, "z" - zaman.

Әмма бу вариант барыбер гамәли яктан кулай булмаган язу рәвешеннән — транскрипция билгеләре белән язудан — ары уза алмый (гәрчә, Надир Дәүләт ул мәкаләдә үзе үк гамәли алфавитның транскрипция билгеләреннән торырга тиеш түгеллеген әйтеп үтсә дә). Чөннан да, өске төрткеләр, өске тильда, өске дуга кулдан язу өчен комачау китереп чыгара — тел белемендә алардан фонетик транскрипция өчен файдаланалар. Андый хәрефләрне кәгазьгә төшергәндә, язудан туктап, алар өстенә әлеге диакритик билгеләрне кую өчен язу процессын өзәргә, өкренәйтергә туры килә. Менә кечкенә бер өзекне әлеге графемалар белән язып карыйк.

*Kıç buldı. Cirgə cñger meñger töşte*
*Urman qarañğılığı quyırdı. Ağaç ara-*
*sında berni kürenmi. Kinət qaydadır*
*yıraqta yəşen yəşnəde, kük kükrəde, —*
*awır yañğır tamçıları tıpırdaşa baş-*
*ladı. Yañğır tön buyına, irtə tañ-*
*ğaça qoyıp yawdı.*

Өске диакритик билгеләр генә түгел, татар теленең кыска әйтелешле [ы] фонемасы өчен бирелгән таяк билгесе дә уку һәм язуны кыен-лаштыра. Юкка гына «Яңалиф»кә күчкәндә б... хәреф дифференциациясезлегеннән (кулдан язган вакытта таяк артыннан таяк килүеннән) котылу өчен (әлеге кыска әйтелешле [ы] фонемасы өчен) «ь» хәрефен сайламаганнар — ул хәреф бер хәреф белән икенче хәрефне буташтырырга юл куймый (бу графема, әлбәттә, урыс графикасының нечкәлек билгесе, әмма хәреф ул — шартлы билге, — моны кулланунының бер читенлеге дә юк). Шулай ук «уzək» [үзәк] дигәндәге «у» графемасы да кириллицада башка функциядә кулланыла. Як... Америка һәм Аурупа халыкларының кайбер телләрендә, мәсәлән, инглизләрдә «с» хәрефе [к] авазы өчен (class [класс]), «s» хәрефе [з] авазы өчен (president [президент] дә языла. Кириллицада ирен-теш фрикатив [в] авазын белдерә торган «b» хәрефе шул ук инглиз телендә ирен-ирен [б] авазы итеп укыла (box [бокс]), «х» хәрефе [кс] аваз тезмәсен белдерә (xylophon [ксилофон]). Латиницадагы «р» хәрефе кириллицаның [п] авазына туры килә h.б. Ниһаять, шунысы да бар, татар телендә [ч] фонемасы [җ] фонемасына караганда өч ярым тапкыр күбрәк кулланыла (санап чагыштыру — статистика шуны күрсәтә), — шулай булгач, ни дип соң әле без [ч] авазы өчен койрыклы «с» хәрефен язарга тиеш? Шулай ук күпчелек Аурупа халыкларында (алман, итальян, һолланд, дат, норвег, маҗар, фин, поляк, сербохорват, словак, чех, швед h.б. телләрендә) һәм хәтта телеграф алфавитында да, халыкара фонетик транслитерациядә дә [й] авазын белдерә торган «j» хәрефен ни өчен [ж] функциясендә кулланырга? Татар телендә аз очрый торган бу фонема өчен безнең традицион латиницада махсус хәреф бар, ә хәзер инде «аждаһа» сүзен, мәсәлән, «ajdaha» дип язаргамы?

Инде хәзер язып карыйк югарыда китерелгән текстны үзебезнең яңартылган латиница («Jaңalif + w») белән, — кулдан язар өчен кайсы әйбәтрәк — укучы үзе күрер:

*— Kic buldь Çirgə eзger-meзgeь tөzte.*
*Urman qaraзgьlьgь qujьrdь. Agac ara-*
*sьnda berni kyrenmi. Kinət qajdadьr*
*jьraqta jəзen jəзnəde, kyk kykrəde, —*
*awьr jaзgьr tamcьlarь tьpьrdaзa baз-*
*ladь. Jaзgьr ton bujьna, irtə taз-*
*gaca qojьp jawdь.*

Кайберәүләр, бездә кулланылган бу төр латиницаны чит илдә яшәүче татарлар аңламаслар (әйтерсең лә алфавит һәм орфография барыннан да бигрәк алар өчен генә тозелә), Татарстанда нәшер ителгән басмаларны укый алмаслар, диләр. Ник аңламасыннар — төрекнекеннән аерылып торган берничә генә хәрефнең функциясен истә калдыру читен эш мени зиһене булган кешегә?

Әмма элекке «Яңалиф»тә (шулай ук безнең гамәлдәге кириллицада да) ирен-ирен сонор тартыгы [w] өчен кирәкле махсус хәреф юк иде. Хәер, ул 20 нче елларда урыс теле аша

# КОТЫЛУ ЮЛЫ БАРМЫ?

кергән «совет», «революция» кебек сүзләрне шул телдәге ирен-теш тартыгы [в] белән түгел, үзебезнең телдәге ирен-ирен сонор тартыгы [w] белән (watan, awaz, wəkil, dəw, dəwe сүзләрендәге кебек) әйтәләр иде. Тора-бара андый алынма сүзләр үзләрендәге [в] белән әйтелешкә күчтеләр (билингвизм нәтиҗәсе). Инде шуннан соң — 30 нчы елларның ахырында — ул ике төрле фонеманың һәркайсына ([w] авазына: watan, awaz, wəkil, dəw, dəwe; һәм [v] авазына: sovet, vagon, revolytsiə) мөстәкыйль хәрефләр кирәк булуы ачыкланды, 1937 елда «Яңалиф»кә «w» хәрефен өстәү проекты әзерләнде, ләкин кириллицага күчәргә дигән әмер бу эшне гамәлгә куюны тоткарлады.

Искә төшерсәк, «Яңалиф»кә (латин графикасына) күчүнең хәзерлек чорында хәзерге төрек алфавитындагы кебек транскрипция хәрефләре куллану проектлары булган.

Әмма 1922-1927 еллар эчендә Бакуда, Казанда һәм башка шәһәрләрдә зур тел галимнәре — Л.Щерба, А.Богородицкий, Г.Шәрәф, М.Корбангалиев, Г.Нугайбәк, С.Агамалы-оглы, Н.Яковлев, Г.Алпаров, Г.Рәхим, Ш.Усманов, Н.Түрәколов, Ш.Рәхими, Д.Мәмәдзадә һ.б. катнашында үткәрелгән махсус конференцияләрдә һәм симпозиумнарда бик күп фикер алышулардан соң гамәли алфавитта фонетик транскрипция билгеләрен кулланудан баш тарталар, кулдан язу өчен уңай хәрефләр сайлыйлар.

Төрекләр исә, аны-моны уйлап тормыйча, транскрипция билгеләрен хәреф итеп үз алфавитларына кертәләр (президент Мостафа Камал Ататөрек — хәрби кеше, ул ашыктыра). Анализлый башласаң, аларның алфавит һәм орфографиясендә җитешсезлекләр тулып ята.

Истанбул һәм Анталия сөйләшүләрендә катнашучылар хәзерге төрек язуы системасын гамәлгә кую «бу мәсьәләдә алгарак карау өчен» дип тә әйтеп карыйлар, — нинди инде алга карау ул рациональ булмаган алфавит системасын кабул итү? Татарстан язучылары бу мәсьәләгә багышланган махсус җыелышта (1992 ел, 20 ноябрь) латиницаның бу төрен кире какты, үзебезнең традицион латин алфавитын яңартып («Jaңalif + w») гамәлгә куярга дигән карар чыгарды. Шундый ук фикерләр матбугатта да, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтына килгән күпсанлы хатларда да әйтелде.

Һәр халыкның ү з м ә с т ә к ы й л ь язу системасы булу — милләтне саклап калуның цыклы терәге, әһәмиятле чараларыннан берсе. Грузинның, әрмәннең, эстонның, французның, инглизнең, немецның, испанның, полякның, урысның үз язу системасы, ә ник әле безгә үз-үзебезне ныгыта торган язу системасын — традицион («Jaңalif + w») графикасын кулланмаска? Әйтик, румыннар белән французлар роман телләре төркеменә, урыслар белән поляклар славян телләре төркеменә карый, ләкин ул халыкларда алфавит системасын берләштерү дигән сүзнең чыкканы юк һәм андый тәкъдим булмаячак та.

Латин графикасына кире кайту идеясе безгә бер бүген генә барлыкка килмәде. 40-70 нче елларда бу турыда сүз дә булырга мөмкин түгел иде — заманалары башка иде. Ничек тә әдәби әйтелешне саклап калу максатыннан (орфоэпик сүзлек юк, ул булса да аңа һәркем карап тормый) 1987 елны хәзерге көндә кулланылган кириллицаны өч хәреф өстәп камилләштерү проекты төзелде. Ләкин гаҗизлектән чыгып башкарылган бу эшне җәмәгатьчелек кабул итмәде — 1927-1939 елларда кулланылган латин графикасын яңартып (ирен-ирен сонор тартыгы өчен «W» хәрефен өстәп), шуңа әйләнеп кайтуны катгый таләп итте татарча уку-язу, иҗат эше белән шөгыльләнә торган татар кешеләре. Бу турыда матбугатта, алда әйтелгәнчә, инде күп мәкаләләр дөнья күрде, белгечләр катнашында махсус киңәшмә һәм җыелышлар булып узды. Шуннан соң Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында латин графикасына нигезләнгән («Jaңalif + w») академик орфография кагыйдәләренең тулы җыелмасы әзерләнде. Ә профессор В.Хаков исә шул ук яңартылган традицион алфавитыбыз нигезендә аерым китап бастырып чыгарды. «Салават күпере» журналының 1992, 1993, 1994 елгы саннарында В.Хаков мәктәпкәчә яшьтәге балалар һәм мәктәп яшендәгеләр өчен әлеге графиканың алфавитын, аның буенча үрнәк текстлар, язу күнекмәләре дә бирде.

Хәзер исә укытучыларыбызның һәм барыннан да бигрәк Татарстан Мәгариф министрлыгының, дәүләт һәм хөкүмәт башлыкларының, парламентның (мәгариф министры урынбасары телевидение аша турыдан-туры элемтәдә бу эш парламент аша хәл ителә, дип җавап бирде. — 1995 ел. 24 май) үзебезнең камилләштерелгән традицион латин графикасын гамәлгә куюга ныклап керешүе кирәк. Әлбәттә, татар әдәби теленең үзенчәлегенә идеаль рәвештә туры килгән алфавитны тормышка ашыру бер ел эчендә генә була алмый — моның өчен кимендә дүрт-биш ел буена әкренләп күчү процессы зарур (газит-журналларда аерым хикәя яки шигырьләр, кыска мәкаләләрне менә шул графикада бастырып чыгару, махсус кулланмалар булдыру һ.б.). Искә төшерсәк, 20 нче еллар ахырында гарәп графикасыннан латиницага күчү дә шул рәвештә булган. Латиницага кайту башка төрки республикаларда да бүгенге көндә шулай бара (Әзәрбәйҗанда, Үзбәкстанда, Кыргызстанда, Төркмәнстанда һ.б төрки илләрдә). Бу күчеш процессын нәшриятның кайбер корректорлары, бәгъзе мөхәррирләр һәм яңалыкка өйрәнергә теләмәүче ялкау укытучылар әнеп бетермәскә дә мөмкин. Андыйлар хәтта кайбер каләм ияләре арасында да очрап куяр — «Латиницага кайту бүгенге укучыларыбызны югалту надан калдыру булмасмы?» — дип уйлаучылар бар аларның. Ләкин бу — юкка хафалану: беренчедән, бездә — ике теллелек, — урысча укый-яза белгән кеше моңарчы кириллица хәрефләрендә нәшер ителгән китапларны һичшиксез укый алачак, икенчедән, латиницага күнегү читен эш түгел (җитмәсә, мәктәпләрдә шул графика кулланылган Аурупа телләре дә өйрәнелә). Һәрхәлдә, ничек кенә булмасын, үзебезнең гүзәл әдәби телебезне кириллицага корылган һәм камилләштән бик ерак торган алфавит һәм орфография аша тора-бара вату-сындырудан саклап калу өчен бу мөһим эшне башкару — латин графикасын гамәлгә кую — үтә мөһим.

Мин төрек язуының безнең телгә туры килмәвен әйттем.

Әгәр дә инде җәмәгатьчелек һәм югары даирәләр безнең алфавит төрекләр тәкъдим иткәнчә булсын дияр икән, — әйдә, ярый, татар әдәби теле өчен латиницаның шул вариантын кабул итәргә дә мөмкин (Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтында эшләнгән һәм «Ватаным Татарстан»да (1993 ел, 15 октябрь, 24 декабрь, 1994 ел, 18 март, 22 апрель) нәшер ителгән орфография кагыйдәләренең тулы җыелмасы системасындагы традицион графемаларны алыштырып куярга гына кирәк булачак бу очракта), — тик төп максат — кириллицага корылган бүгенге алфавит һәм орфография буталчыгыннан (шуның аша әдәби телне бозудан) чыгу — кичектерелмәсен (юкса, көн артыннан көн үтә — килер бер заман, ул чакта бу эшне башкара алу гафу ителмәслек соң булачак).

* Борынгы грек риваятьләренең берсендә әйтелгәнчә, юлбасар Прокруст кешене җәзалау өчен махсус калып-ятак уйлап чыгарган: шул ятактан озынрак корбанының аякларын кисеп кыскарткан, ятактан кыскарак булганының аякларын тарттырып сузган.

TATARCA KANSELƏRIƏ MAŞINKASЬ KLAVIATURASЬ



TATARCA PORTATIV MAŞINKA KLAVIATURASЬ



Iskarma: "Nomer" bilgese latinitsada "No." jaki "Nr." rəweşendə birelə.

## Ул Хуҗа Насретдиннең иң лаеклы шәкерте иде

***Атаклы төрек язучысы Газиз Нәсин быел сиксән яшен тутырды һәм әле яңа гына — 1995 елның 6 июлендә арабыздан китеп барды. Аның сиксән еллык юбилеен бөтен төрки дөнья тантаналы төстә бәйрәм итәргә тиеш иде. Чөнки Нәсин турында «атаклы язучы» дип кенә әйтү аз, ул — атаклыларның да атаклысы, минемчә, XX йөздә төрки халыклар үстергән һәм дөнья күләмендә чын-чыннан бик киң танылган каләм ияләренең беренчесе иде. Шуңа да карамастан, аны әле татар укучысы аз белә. Бүтән төрки кардәшләребез дә үзе исән чагында Г.Нәсингә лаеклы хөрмәт күрсәтергә өлгермәде***

*Г.Нәсин Мәрмәрә диңгезенең Һәйбәли утравында бер фәкыйрь гаиләдә туа. Хәрби уку йортын тәмамлаганнан соң гаскәрдә хезмәт итә. 1938 елда матбугатта беренче әсәрләрен бастыра башлый. Хәрбиләрнең язучылык белән шөгыльләнүе хупланмаганлыктан, ул әсәрләрен үз исеме Мәхмәтносрәт урынына атасы Газиз исеменнән бастырырга керешә. 1933 елгы канун нигезендә, ул үзенә Нәсин («Ни. кем син») фамилиясен кабул иткән була. 1944 елда өлкән лейтенант хәрби хезмәтен калдырып, шуннан соңгы гомерен тулысынча әдәбиятка багышлый, әмма аңа, гаиләсен асрар өчен, шактый еллар азык-төлек сатучы, фотограф, укытучы, журналист һәм бүтән һөнәрләр белән шөгыльләнергә туры килә. Бераз аякка баскач, үз матбугатына да нигез сала, хәтта нәшрият та ачып җибәрә. Хөррият өчен көрәшкән язучы алты елын төрмәдә яки сөргендә уздыру ачысын да татый, күп кенә халыкара бүләкләргә, Төркия премияләренә дә лаек була. Тик аңа үз исемен йөртү генә насыйп әйләми — ул бөтен дөнья өчен Газиз Нәсин буларак танылa.*

*Әдип нигездә көлке һәм мыскыл тулы әсәрләр авторы буларак әдәбият мәйданына чыга, унлап романында, егерме бишләп пьесасында, меңләгән хикәяләрендә аның сатирик сәләте аеруча куәтле ачыла. Әмма язучының лирик шигырьләре, моңсу истәлекләре, җитди әңгәмәләре дә бар. Аның бу әсәрләренең беренче басмалары гына да туган телендәге сиксәнләп җыентыкка тупланган. Бу китапларның күпчелеге исә кат-кат, кайберләре алты-җиде мәртәбә дөнья күргән. Романнары һәм хикәяләре дөньяның дистәләгән теленә тәрҗемә ителгән һәм шулай ук кабат-кабат нәшер ителгән. Мәсәлән, аның гарәп телендә йөздән артык китабы чыгарылган, Иранда басылган әсәрләре кырык китап тәшкил итә. кырыклап китабы элекке СССРның унбишләп телендә укучыларга барып ирешкән. Нәсин пьесаларын дистәләгән илнең иң атаклы театрлары уйный. Язучының үзе турында да гыйльми тикшеренүләр, мәкаләләр һәм китаплар байтак. Нәсин радио-телевидение тапшыруларында зур урын алды, киң колачлы җәмәгать эшчәнлеге белән дә күпләрнең ихтирамын казанды.*

*Газиз Нәсин бүген арабызда юк, әмма аның әсәрләре яши, аларның киләчәктә тагын да күбрәк укучыларның күңел байлыгына әйләнәсенә шөбһәләнмәскә мөмкин. Чөнки язучы халыкның күпчелеге мәнфәгатьләрен яклый, хакыйкать һәм гаделлек өчен көрәшә. Аның теле үткен, фантазиясе бай, сәнгать чаралары төрле, язу алымы кыю һәм мавыктыргыч. Г.Нәсин әсәрләре Төркия тормышының соңгы илле елын бик тулы күз алдына бастыруы белән генә түгел, теләсә кайсы дәүләттә һәм халыкта очрый торган кимчелекләрне оста камчылавы, җитешсезлекләребездән арынуга бик яхшы хезмәт итүе белән дә кыйммәтле. Шуның белән бергә, ул әсәрләр рухыбызга көч, ялыбызга күңеллелек өстәүләре белән дә игътибарга лаек. Төрекләр аны заманыбызның Хуҗа Насретдине дип таныды, бу бәя белән башка халыклар да килешер, мөгаен.*

*Түбәндә «Мәдәни җомга» укучылары игътибарына мәшһүр әдипнең үзем тарафыннан тәрҗемә ителгән бер хикәясен тәкъдим итәм.*

**Тәүфикъ ӨЙДИ.**

# Без кеше була алмабыз

**Газиз НӘСИН**

***Хикәя***

Кеше-кара җыелган җирдә берәрсе: «Без кеше була алмабыз, туган» дисә, бүтәннәре дә: «Әй-йе-е, бик дөрес, була алмабыз», — дип баш кага башлый. Берсе дә каршы килеп: «Ул нинди сүз, әфәндем? Һушыгызга килегез, без үз-үзебезне хөрмәт итәргә тиеш», — димәс.

Егерме биш яшьләремдә, тамырларымда кан уйнаклап аккан көннәрдә, мин менә шундыйрак бер гәпкә тап булдым. Шаһзадә утрауларының берсенә китеп баручы корабта нәрсәгәдер җенә чыккан бер абзый:

— Без кеше була алмаячакбыз! — дип кычкырынып тора иде. Салондагылар исә, аны җөпләп, баш кагып маташалар.

— Нишләп әле без кеше булмаска тиеш? — дип каршы төштем мин. — Әле ничек кенә булырбыз, бөтен дөнья таң калыр!

Юлаучылар сүз берләшеп куйганмыни, барысы да чыр-чу килә башлады:

— Кеше булмаячакбыз...

— Кешелектән бик ерак без...

— Без кеше була алмаячакбыз...

Бу каркылдаулар җенләнгән картның күңеленә хуш килде, ахры, карашы ягымлыланды.

— Ишетәсеңме, улым? — диде ул миңа. — Барыбыз да бер авыздан, «без кеше була алмаячакбыз», дибез. Димәк, без чынлап та аякка баса алмаячакбыз. Безне болай кычкырырга берәү дә көчләми ләбаса.

— Без кеше булырбыз, булачакбыз! — дидем мин.

— Менә күрәсең ич, улым, үзең үк: «Без кеше булачакбыз», дисең. ...«чакбыз!» Димәк, без хәзергә кеше түгел әле. Моны бүтәнчә аңларга кушасыңмы?

Өнемне чыгармадым, әмма менә шул көннән бирле һаман: «Без нигә соң әле кеше була алмаячакбыз икән?» — дип уйлап йөрим.

Соңгы тапкыр төрмәгә ябылуым миңа ифрат зур мөмкинлек ачты, гомер бакый борчыган соравыма мин шунда җавап таптым.

Төрмәнең илле кешелек сәяси тоткыннар бүлегендә мин илебезнең иң укымышлы кешеләре арасында яшәдем. Монда күренекле малтабарлар, губернаторлар, баш директорлар, парламентыбызның элекке депутатлары, мәгълүм сәясәтчеләр, атаклы инженерлар, табиблар — төрле-төрле мәшһүр затлар бар иде. Аларның күбесе Аурупада һәм Америкада белем алган, чит илләрне гизгән, берничә тел белә. Тормышка, илдәге хәлләргә карашыбыз нигездә туры килә иде. Шуңа да карамастан, мин алардан бик күп гыйбрәт алдым, ә иң әһәмиятлесе — безнең ни өчен кеше була алмаячагыбызны төшендем.

Күрешергә килгән агай-энеләрем җанга ятышлы хәбәр ишеттермәде: фатир хакын түли алмаганнар, кибетчегә бурычка батканнар. Хәсрәткә чумдым, күңелемне өметсезлек чолгап алды. Аннары башыма, тиз көндә берәр роман язып ташларга кирәк, дигән бик шәп бер уй керде. Әгәр аны берәр гәзиткә сатып булса, акчага тиенер идем. Башымда инде күптән язарга җыенып йөргән әсәрнең сюжеты да әзер.

Шушы карарга килү белән кулыма кәгазь-каләм алдым да сәндерәмә менеп кунакладым. Вакытны югалтырга ярамый! Буш сүз, килде-китте сүзне җир йотсын!

Әмма ун юл язарга да өлгермәдем, яныма тоткыннарның берсе — күренекле җәмәгать эшлеклебез килеп утырды.

— Без кеше булалмаячакбыз, — диде ул. — Юк, була алмаячакбыз!

Аңа берни дә эндәшмәдем.

— Ни өчен кеше була алмаячагыбызны әйтимме? — диде ул акыл бирергә җыенгандай. — Мин заманында Швейцариядә белем алдым, алты ел Бельгиядә эшләдем...

Ул озак итеп, җентекләп шул илләрдәге тормышы турында сөйләде. Эшемне бүлеп, сүз белән бозау имезүчегә эчем поша башлады. Тик моны аның үзенә ничек әйтәсең? Әледән-әле кәгазьләремә күз тегеп, каләм йөртәм, вакытым тар, торып китүен көтәм, янәсе. Ә аның исендә дә юк, сөйли дә сөйли:

— Сез анда китап тотмаган кешене күрмәссез. Кайсына карама, ике минутка кулы бушауга, китабын ачып куя да укырга ябыша. Автобуста, поездда, тегендә-монда һәммәсе китапка кадала. Өйләрендә күрсәгез иде сез аларны — тәмам акылдан шашарлык: һәркайсының кулында китап. Укыйлар, укыйлар, укыйлар.

— Нинди әйбәт, — дидем мин, ниһаять, туктамасмы бу дигән өмет белән. — Нинди яхшы!

— Табигый, әйбәт, — дип дәвам итте ул. — Искиткеч! Ә хәзер безгә карагыз: менә шушы камерада ни кадәр укымышлы халык җыйналган инде, югыйсә, әмма арада китап укучы һич югы бер бәндә бармы соң? Юк! Шулай икән, әфәндем, без инде, әлбәттә, кеше була алмаячакбыз.

— Сез хаклы.

Җөпләвем генә булды, ул тагын да дәртләнеброк китап укудан бушамаган бельгияле һәм швейцариялеләр турында авыз суын агыза башлады. Төшке аш вакыты җиткәч, икебез дә сәндерәдән төштек.

— Хәзер инде Сезгә безнең ни өчен кеше була алмаячагыбыз ачыкмы? — дип сорады ул.

— Әйе, — дидем.

Шулай итеп ярты көнем швейцариялеләр һәм бельгиялеләрнең китап яратуы хакында гәп тыңлап узды.

Төшке ашны тиз генә кабып йоткач, тагын сәндерәмә менеп кунаклап, романыма тотындым. Тезенә кәгазьләремне җәеп салып, кулыма каләм алып, уйга чумдым. Беренче юлны язып куярга да өлгермәдем, яныма камерадагы танышларымның икенчесе килеп утырды.

— Нишлисез, кардәш?

— Менә роман язарга тотындым әле.

— Һай, монда берни дә барып чыкмас шул. Эт түе лабаса монда. Сезнең Аурупада булганыгыз бармы?

— Юк, Төркиядән читкә чыкмадым әле.

— Ә-ә-ә, кызганыч! Мин сезнең Аурупага баруыгызны бик теләр идем; барысын да үз күзең белән күрүгә , шунда яшәп карауга ни җитә. Белемне арттыра, дөньяга карашны киңәйтә ул. Мин бөтен Аурупаны әйләнеп чыктым, аяк басмаган илем калмады диярлек. Дания, Һолландия, Швециядә барыннан да озаграк яшәдем. Һай андагы тамашалар! Кешеләр бер-берсенә нинди ихтирам белән карый анда, берәрсен бимазалавым мөмкин дип, кычкырып сөйләшүдән дә тыелалар хәтта. Менә хәзер үзебездәге хәлләргә бак инде: шау-шу, ыгы-зыгы, бака түе. Мин хаклы түгелмени, хөрмәтлем? Бәлки, менә хәзер минем йокым киләдер, йә булмаса, нидер язасым бардыр — адәм баласына нинди уй төшмәс? Ләкин мондый мәхшәрдә кая ул Сезгә роман язу. Билләһи, ирек бирмәячәкләр!

— Шау-шуда да яза алам мин, колак төбемә килеп лыгырдамасалар...

— Җаным-әфәндем, шау-шу булмаса, тагын да яхшырак түгелме? Сезгә комачауларга ни хаклары бар аларның, шыпыртрак сөйләшергә дә мөмкин ләбаса. Дания, Швеция, Һолландиядә менә мондый башбаштаклыкны һич тә күрмәссең. Илдәшләр берсен-берсе хөрмәт иткәнлектән, бу мәмләкәтләрнең халкы да алга бара.

Аурупалыларның тәрбияле, инсафлы булуларына күпләгән мисаллар китерә-китерә сөйләде дә сөйләде бу. Әдәп кысаларыннан чыгуымны сизсәм дә, үземне җиңә алмый, кәгазьләремә иелдем дә яза башладым. Дөресе, язган булып кыландым.

— Юкка башыгызны катырмагыз, — диде әңгәмәдәшем. — Монда барыбер һичнәрсә оештыра алмассыз. Нервларыгызны кызганыгыз. Аурупада анда эш башка. Аурупалы булуның нәрсә икәнлеген беләсезме соң сез? Ул беренче нәүбәттә якыныңны хөрмәт итү

гән сүз. Ә бездә? Кая ул! Менә уның өчен дә, бөем, без кеше ула алмаячакбыз. Әйе, кеше бу- безгә эләкмәячәк!

Ул әле миңа тагын бик күп нәр- әләр ачкан булыр иде дә, адво- аты килеп чакырып алды. Мин котылдым бу аяклы казадан. үтән берәрсе килеп бәйләнер йө, үп курыкканлыктан, шуннан соң ин кәгазьләремә тагын да иелеб- әк төштем. Ике юл яздыммы кән, камерадагы башка бер та- ышым килеп:

— Эшләрең уң булсын! — дип ндәште.

— Рәхмәт.

Сәндерәмә менеп утырды да у:

— Безгә кеше булырга бик ерак ле! — дип ярып салды.

Сүзен баштан ук өзәргә чама- ап, өнемне чыгармадым.

— Америкада булганыгыз бар- ы? — дип сорады бу.

— Юк.

— Кызганыч. Америкада берни- ә ай яшәсәгез, безнең нигә болай ртта калуыбызны аңлар идегез. Америкаnнар, әфәндем, безнең ебек бушбугаз түгел — тиктома- га лыгырдамый. Анда буш сүз- нең кадере юк. Америкада вакыт — акча. «Тайм из мони». Амери- ән, сиңа эше төшсә генә, авызын ача. Ике сүзен әйтә дә бизнесына отына. Ә безнең Төркиядә? Үзе- безне генә алып карыйк. Ни белән мәшгуль без? Тел белән май яза- быз. Айлар буе. Буш, кирәксез сү- ләр. Америкада мондый галәмәт юк. Шунлыктан алар гел алга ба- ра да инде.

Тел бистәсе төшенмәсме, торып китмәсме, дигән өмет белән аһыл- ый-уфылдый башладым. Тик ул, берни булмагандай, такылдавын ына белде!

Кичке аш вакыты җитте. Шуңа уазгалганда ул:

— Без кеше була алмаячакбыз. Әйе-әйе, шушы сафсата сатудан арынмасак, без адәм була алма- ячакбыз, — диде.

— Сез тулысынча хаклы, — дип җөпләдем мин.

Ашык-пошык тамак ялгагач, кә- газьләремне тагын кулыма ал- дым.

— Хезмәт иң кирәкле бер шөй- дер. Эшләгән — тешләгән, эшлә- мәгән — кешнәгән, — дигән та- выш яңгырады шулчак.

Күтәрелеп карасам, камерадаш иптәшләремнең берсе басып тора икән каршымда.

— Сез моңа ни әйтерсез? — дип, ул янәшәмдәге сәндерәгә килеп утырды.

— Эшләргә кирәк, билгеле, — дидем мин.

— Ата-анам мине алман го- реф-гадәтендә тәрбияләде.

Ачуымнан шартларга өзер идем. Ә ул кайнарланып дәвам итте:

— Мин Истанбулда алман мәк- тәбен тәмамладым. Югары белем- не Алманиядә алдым, озак еллар анда эшләдем дә. Алманнар арасында эшләми торган бер ке- шене ялгыш та таба алмассыз. Ә без? Шушы камерадагыларны гына алыйк. Юк-юк, без кеше бу- ла алмаячакбыз. Кая ул безгә!

Мин, ниһаять, боларның миңа һаман да роман язарга ирек бирмә- ячәкләрен аңладым. Нервларым- ны гына бозачакмын икән. Бары- бер да йокыга талганчы, эшемне читкә этәреп торырга кирәк.

Күршем исә Алмания турында һаман да әйтте бер тапкыр:

— Алманиядә эшсез яту мөм- кин түгел. Алман, кая гына килеп эләксә дә, кул кушырып утырмый. Ул үзенә ниндидер бер шөгыль таба. Алман эшләмичә булдыра алмый.

Инде менә шун-5ың киресенә ми- сал: без монда ничә ай ятабыз инде, һич югы беребез аркылыны буйга алып салдымы? Берәрсенә шуны искәрт әле — гаҗәпләнер: төрмәдә эшлиләрмени, янәсе? Укымышлы алман исә болай ди- мәс.Ул йә истәлекләр яза башлар, йә килечәк эшләрен барларга ке- решер, йә китап актарып — кы- скасы, тик ятмас, гомерен заяга уздырмас. Ә без? Юк, ни генә әйт- сәгез дә, без кеше була алмаяча- кбыз.

Төн уртасы җиткәч кенә торып китте бу янымнан. Менә хәзер ин- де эшкә тотынырга да мөмкин. Моннан соң яныма берәү дә кил- мәячәген, ни өчен кеше була ал- маячагыбыз турында лекция укы- маячагына өметем бик зур иде.

Әммә ялгыштым — тагын берсе килде. Бусы күп еллар буе Фран- циядә яшәгән икән. Йокыга оеган иптәшләребезне уятмас өчен, ул акрын гына пышылдый башлады. Имеш, французлар яхшы эшли, әйбәт ял итә һәм рәхәтләнеп кү- ңел ача белә. Бу зирәк халык эш белән ял сәгатьләрен буташтыр- мый, ярты төн узгач, мин эшләргә тиеш түгел, янәсе.

— Хәзер рәхәтләнеп ятып йок- лагыз, иртән уянгач, айнык, саф баштан яза башларсыз. Хезмәт, ял, күңел ачулар — бездә барысы да саташып беткән. Ял итәсе вак- та эшлибез, эшлисе вакытта ял итәргә маташабыз. Нәкъ менә шу- нлыктан уңышлардан колак кага- быз да инде. Менә ни өчен бер- кайчан да кеше була алмаячак без. Юк, кеше булу безгә язмаган!

Ул киткәндә мин инде роман язарлык хәлдә түгел идем. Күзлә- рем йомыла башлаган иде, яттым да йокыга талдым. Иртәгесен исә бүтеннәрдән алдарак торып, ро- манымны текердәтә башладым.

Әммә... минем аеруча ихтирам иткән бер танышым иртүк бәдрә- фкә барган икән, кайту уңаенда яныма кагылып:

— Англия — бөтенләй сәер ил, — диде. — Англиядә булганыгыз бармы?

— Юк.

— Күз алдыгызга китерегез әле: Англиядә поездда барасыз, ди. Купедагы юлдашыгыз, ничә сәгать бергә барсагыз да, сезгә бер генә сүз дә катмаячак. Әгәр бу хәл бездә булса, «юлдашыбыз нинди тәкәббер, әллә телсезме икән?» диячәкләр. Инглизләрдә исә бу — тәкәбберлек түгел, әдәп- лелек билгесе. Бәлки, сез аның белән сөйләшергә теләмисездер. Нигә әле сезне әллә кемнәр бор- чырга тиеш? Ә бездә? Танышмы, түгелме, берәр кемсә янытызга килеп утырса, теләнә салына ба- шлаячак. Әйтик, сезнең, бәлки, ниндидер эш белән башыгыз кат- кан чактыр, ә ул моңа төкерме- ячәк тә. Нәкъ менә шунлыктан бе- ркайчан да кеше булалмаячакбыз без.

Мин теземдә җәелеп яткан кә- газьләрне алып бөгәрләдем дә идәнгә ыргыттым. Авторучкамны кесәмә тыктым.

Бетте! Романның язмышы менә шулай хәл ителде.

Әйе, төрмәдә берни дә яза ал- мадым. Әммә анда миңа уйлап куйган романымнан күп мәртәбә кыйммәтлерәк бер хакыйкать ачылды — мин ни өчен кеше була алмаячагыбызны ачыкладым. Хә- зер минем алда берәрсе үтен сы- тып: «Юк, без кеше була алма- ячакбыз!» — дисә, кулымны күтә- рәм дә:

— Мин аның ни өчен икәнлеген беләм! — дип кычкырам.

Соңгы төрмәдәге казанышым да чынлыкта шул булды.



ИГЪТИБАР!

# Һәр күңелдә шигырь уты бар

***Әйе, чыннан да, игътибар итик әле! Бу яңа рубриканың үзенә дә, «Мәдәни җомга»га килгән, килеп торган хатларга да, шигырьләргә дә. Гәзитебез чыга башлау белән безгә бик күп укучыларыбыздан шигырьләр агыла башлады. Ни гаҗәп, әлегә авторларның күбесе үз хатларының беренче юлларын: «Мин үзем шигырь түгел түгелен...» кебегрәк сүзләр белән башлап җибәрә. Әммә... хат авторы бит шигырьләр язган, безгә үз шигырьләрен юллаган. Менә шунда инде мәшһүр язучының канатлы бер фикерә искә төшә: әгәр дә кеше, уңкиде яшькә җитеп тә бер шигырь дә язмаса, аны табибка күрсәтү фараз... Шулай! Һәр күңелдә шигырь уты бар! Ә учактагы күмерне сүндерми-сүрелдерми саклый белергә, дөрләтә белергә дә кирәк. Нәкъ менә шуны истә тотып, без яңа рубрика ачып җибәрәбез, каләм тибрәтүче дусларыбызның һәркайсына илһамлы кичләр, илһамлы таңнар, илһамлы төннәр һәм илһамлы көннәр телибез!***

Сәйрә ЗАРИПОВА

## *Әнием сөлгесе*

Бүләк итте миңа әни
Үзе чиккән сөлгесен, —
Сөлгедәге чәчәкләре
Кабатлый назлы сүзен.

«Бу сөлгене сакла!» — диеп
Чиккән язулар салган.
Бу сөлгедә әниемнең
Йөрәк җылысы калган.

Чиккән сөлгенең башына
Күз яшьләремне сорттем.
Кайда гына яшәсәм дә,
Һәрчак янымда йөрттем.

Сөлгедәге чәчәк-гөлләр —
Җидесе җиде төстә.
Әниемнең якты йөзе
Истә, һаман да истә...

* * *

Ак мамыктан шәл бәйләде,
Дус кызымның әнисе.
Ул һөнәрне биргән аңа
Бала чакта әбисе.

Ул шәлне иңемә салып,
Көзгегә барып карыйм.
Кеше иңендә шәл күрсәм,
Мин аның кулын таныйм.

Шәл бәйләгән чакларында
Нинди көйләр көйләгән?
Нинди көйләр көйләсә дә,
Ак бәхетләр теләгән...

* * *

Карамагыз сабый күзләренә,
Карамагыз, зинһар, көнләшеп, —
Сабыйларның әле йөрер чагы
Кояш белән генә сөйләшеп.

Карамагыз яшьлек күзләренә,
Карамагыз һич тә көнләшеп, —
Яшьләрнең дә әле йөрер чагы
Айлы кичләр белән серләшеп.

Сабыйларга — сабый бала булып,
Яшьләргә — яшьләрчә эндәшеп,
Аксакаллар йөри — көнләштереп,
Үзләренчә генә көнләшеп...

# «Заман»да кунакта

Шушы елның гыйнвар аенда Казанда татар телендә чыга торган төрек гәзите «Заман — Татарстан» «Алтын Урдада әдәбият һәм мәдәният» дип аталган иҗади конкурс игълан иткән иде. Конкурс шартлары буенча анда җиңеп чыгучылардан беренче өч кеше акчалата бүләк алачаклар һәм бер атна Төркиядә сәяхәт кылачаклар, дип белдерелде. «Заман — Татарстан» гәзите биргән вәгъдәсенә тугры калып, конкурста җиңеп чыгучылардан филология фәннәре докторлары Х.Миннегулов (Казан дәүләт университеты), Ф.Урманче (Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институты) һәм язучы С.Шәмсинә (Татарстан китап нәшрияты) октябрь башында бер атнага Төркиягә алып китте, гәзитнең баш мөхәррире Муәммәр бәй Морат аларны бу сәяхәткә озатып йөрде.

Татарстан кунаклары «Заман» гәзите җитәкчеләре белән очраштылар, Истанбул шәһәренең тарихи урыннарында, мәшһүр музейларында булдылар, илнең мәдәнияте, бай тарихы белән танышып йөрделәр. Сәфәрнең ахырында кунаклар илнең көньягында урнашкан гүзәл курорт шәһәре Анталия белән таныштылар, «Заман» гәзитенең андагы редакциясендә өнгәмә кордылар. Әлегә сөйләшү җирле телевидениегә төшерелеп алынды һәм шул көннәрдә эфирга чыкты.

## Гыйффәт туташны юксыну

# «Ирләр шагыйрь булса, бездә шагыйрә бар»

Татар әдәбиятының тиңе күрелмәгән тизлектә үсеш алган чоры — егерменче гасыр башы Бөек Тукай, берничә ел эчендә, татарлар гомер сөргән төбәкләрдә генә түгел, ә бәлки бөтен төрки дөньяга танылып өлгерә Исхакыйлар Әмирханнар, Ибраһимовлар, Камаллар әдәбиятыбызның алтын фондына кергән әсәрләрен тудыралар

Болар әдипләр, шагыйрьләр — татарның ир-егетләре...

Чорның әдәби мирасы турында сөйләгәндә күңелне горурлык хисләре биләп ала икән. моңа тагын бер сәбәп бар Егерменче гасыр башында әдәбият мәйданына бер төркем шагыйрәләр, әдибәләр дә килеп керә Әле 1907 елда ук Маһруй Мозаффария «Мәшһүр хатыннар» исемле шигырендә «Ирләр шагыйрь булса, бездә шагыйрә бар» дип язып чыга Бу сүз уйнату гына түгел Әйдәгез: 1905-1917 елларда төрле тарафларда чыккан татар гәзит һәм журналларына күз салыйк Нәрсә күрәбез соң? Аларда язышкан авторлар арасында татар хатын-кызлары да еледән-еле очрап тора Дөрес, кайберсе берәр генә шигырь яисә хикәясен бастырып өлгерә, икенчеләре исә үз әсәрләрен китап-рисаләләр, шигырь җыентыклары рәвешендә укучы кулына тапшырган Боларның иҗатын өйрәнүгә, халыкка җиткерүгә заманында профессор Мөхәммәт Гайнуллин зур өлеш кертте Мәсәлән, ул төзеп чыгарган «Өмет йолдызлары» исемле җыентыкка унтугыз шагыйрә, прозаик һәм публицист хатын-кызның шигырьләре, хикәя һәм публицистик мәкаләләре, тәнкыйть язмалары кертелгән Китаптан читтә калганнары да аз түгел.

Бу урында әлеге иҗат әһелләренең тик берсе хакында гына сөйләп үтәргә телим: ул — Гыйффәт туташ Мондый имза белән әсәрләрен бастырган шагыйрәбезнең 100 ел тулуын белеп тә дәшми калу әдәбият тарихын тикшерүчеләрне һич тә бизәмәс иде.

Гыйффәт туташның мулла кушкан исеме — Заһидә, Заһидә Хөсәен кызы Бурнашева. Мишәр ягыннан күтәрелгән шагыйрә. Туган авылы — Әҗе, хәзер ул Рязань өлкәсенә керә. 1895 елның 19 октябрендә дөньяга килгән бу кызның балачагы шактый кадими фикерле әти-әниләре кулында уза. Шуңа да карамастан, ул кызыксынучан, кыю булып үсә, китап укырга ярата, бик яшьли шигырьләр яза башлый Берадан Гаяз Исхакый чыгарган «Ил» гәзитенә даими язышучы булып китә Монда басылган шигырьләре, кыска гына вакыт эчендә басылган өч шигырь җыентыгы аны Октябрь алды еллары татар поэзиясенең күренекле вәкиле итеп танытып өлгерә.

Хәер, аның исемен татар җәмәгатьчелегенә танытуда икенче бер вакыйга да мәгълүм роль уйный 1915 елның 6 сентябрь санында «Вакыт» гәзите яшь авторның «Идарәгә мәктүбен» — «Мәрхәмәт наменә бер үтенеч» исемле мөрәҗәгатен бастырып чыгара. Егерме яшьлек авыл кызы шундый гайрә табигый булган юлны ни өчен сайлап алган соң? Чөнки аны туган йортындагылар — «яшьтән тәрбия күрмәгән ана вә иске фикерле ата» җәберлиләр: шигырь язуы һәм матбугатта чыгаруы өчен кыямәтләр куптаралар, китаплары яндырыла, үзе өйдән чыгармый тотыла, тиргәлә, сүгелә. Түзеп торырлык хәл калмагач, ул туган йортын ташлап чыга (полиция ярдәмендә). Әнисенең: «Ул минем акчамны урлап чыга торгандыр», — дигән сүзенә карап хәтта ки аны тентиләр дә әле. Ана кеше моның белән генә тынычланып калмый, волость идарәсенә барып: «Кызым фәхешханәгә бара, Төркиягә кача», — дип гариза бирә... Әҗедә торырга аңа фатир табылмый, һәм З.Бурнашевага икенче бер авылда гына сыену урыны килеп чыга.

«Вакыт» гәзитенең бу саны чыккач та, татар вакытлы матбугатында яшь шагыйрәгә теләктәшлек белдергән шигырьләр, публицистик чыгышлар басыла башлый. Аның бу кыю адымын ул чорның шагыйрьләре һәм шагыйрәләре, әдипләр, журналист-публицистлар хуплый.

Гыйффәт туташ үз шигырьләрен 1910 елларда, унбиш яшеннән үк яза башлый, татар укучысы, әдәби җәмәгатьчелек каршында танылуы 1914-1915 елларга туры килә. Аның шигъри фикерләвендә, сурәтле сөйләмендә дидактика, үгет-нәсихәтчелек сизелми. Ул күңелендәгеен яза, күңелен ача. Аның рухи дөньясы шул чор тормышы тудырган нурсызлык, рухсызлык, өметсезлек күренешләре белән кискен каршылыкка керә Шагыйрә вакыт-вакыт золмәттән, каратоннардан зарланып алса да, аның күңелендәге өмет йолдызын болытлар каплый алмый.

Туктамас күңлем очудан,
Яшь йөрәк ярсыр әле;
Изге ак нурлар сибеп,
Йолдызларым балкыр әле, —

дип башлап китә ул, мәсәлән, «Дулкынлы йөрәктә» исемле шигырен Гыйффәт туташ шигырьләрендә лирик герой туктаусыз эзләнә, тормыш каршылыклары арасында, каршылыклы хисләр дөньясында югалып калмый. «Тарсыну» шигырә бу сүзләремә дәлил булыр кебек:

Яшим читлек эчендә:
юк миңа ямьле көннәр,
Караңгы дүрт ягым, юк,
ичмасам, йолдызлы ак төннәр!
Әсир күңел, әсир җан-тән;
һава тынчык, йөрәк сүнгән;
Янам ялгыз, көям ялгыз. берәү юк
күз яшем силгән (сөрткән).
Ничаклы талпынып баксам да,
юк миңа нәҗат (котылу) бер дә;
Шулай да түзми күңел,
эстәми тормакны тар җирдә...
Яши ул дәрт белән, төшми,
егылмый ул. һаман рухлы
Аңар түбән хыяллар күрсәтәләр
алда нур-утың!

Гыйффәт туташның шигъри мирасында табигать күренешләрен пирик хисләр белән оста үреп биргән әсәрләр дә шактый. Гомумән, аның шигъри фикерләвенә ай, йолдыз, кояшлы көн, сандугач, яз, көз образлары килеп керә, ләкин традицион сурәт булсалар да — яңарып, яңа яклары белән ачылып.

Йөзен ачкан булып кайчан
Ае чытлыкланып балкый.
Димен. «Юк. ак юлым, кайтмам,
Нурыңа алданып калмыйм, —

кебек юлларда шагыйрәнең башкаларны кабатламыйча, шигырьдә үз сүзен, үзенчә әйтергә теләвен күрәбез. «Көз» шигыренә дә укучы күңеленә үтеп керерлек сурәтләлек хас:

Караңгы көз. һава салкын,
томанлы,
Сибә җиргә болыт карны,
буранлы,
Агачлар да тонып беткән —
каралган,
Коелган барча яфраклар —
таралган.
Йөзен чыткан кыры да. урманы да,
Күз уйнатмый шаярып
кызлары да.

Октябрьгә кадәр шигырьләрен «Гыйффәт», «Гыйффәт туташ» имзалары белән бастырган Заһидә Бурнашева 1918 елда коммунистлар партиясе сафына керә. күренекле җәмәгать эшлеклесенә әверелә (шигъри иҗаттан читләшә, билгеле) Ул — Сәмәркандта чыгарыла башлаган «Михнәттәшләр тавышы» гәзите мөхәррире, Төркестан коммунистлар партиясе үзәк комитетының хатын-кызлар бүлеге мөдире. III Интернационал конгрессында да катнаша ул, берара партия үзәк комитетында инструктор булып эшли.

З.Бурнашева 1933 елдан соң Кыргызстанда яши һәм, пенсиягә чыккач, 1952 елда Казанга кайта Ул безнең арабыздан 1977 елның 6 ноябрендә китте.

З.Бурнашеваның 1917 елдан соңгы сәяси-иҗтимагый эшчәнлегән, тоталитар режим шартларында барганга күрә, кызыллык күренеше итеп бәяләргә ашыкмыйк. Ул ихлас күңелдән, якты тормыш килерәнә ышанып, кешеләрдә, бигрәк тә хатын-кызларда (аеручa Урта Азия халыклары арасында) иҗтимагый активлык сыйфатларын тәрбияләүгә бөтен көчен куйган, мәгърифәт эшенең нәтиҗәлелегенә омтылган...

**Зөфәр РӘМИ.**

## Ераkta — йөрәктә

# Илгизәр авылдашыбыз

Факия апаның ире Закир ага дөнья куйганда аның төпчеге Вахитка 10 яшь иде Ике хәсрәт бергә килде — нәкъ шул көннәрдә Бөек Ватан сугышы башланды Дөнья көтү балаларны аякка бастыру Факия апа җилкәсенә калды. 6 бала Дөрес, аларның өлкәннәре әниләренең булышчылары иде инде, ләкин ана өчен алар барыбер бала, алар өчен ул җавап бирә Факия апа гаҗәп көчле ихтыярлы, сабыр холыклы киң эрудицияле кеше иде Ул искечә бик гыйлемле, Йосыф-Зөләйха китабын. «Бәдәвам»ның, пәйгамбәрләр китабының күп җирен, мөнәҗәтләрне риваятьләрне яттан белә, телгә ифрат оста Күршеләре аны «мулла түтәй» дип йөртә Язмыш Факия апаны төрлечә сыный әмма ул авырлыкларны үзенә хас ныклык белән җиңә килә Аның балалары да үзе кебек тырыш эшчән, татулар Ө кечә уллары Миргазиян белән Вахит әниләрен бигрәк тә куандыралар иде — балачаклары авыр сугыш елларына туры килүгә карамастан аны бер нәрсә белән дә борчымадылар — мәктәптә иң алдынгы укучылар булдылар, җәйге каникулларда башка малайлар белән төптән җигелеп колхоз эшенә йөрделәр Факия апа үзе дә улларының укуларын кайда йөрүләрен, нинди китаплар белән мавыгуларын тикшереп кенә тора дөнья хәлләре белән кызыксына мәктәпкә еш бара Алгарак китеп шуны әйтәсе килә, Факия апа балалары укуны тәмамлагач та, мәктәп белән элемтәне өзмәдә, бигрәк тә үз урамындагы малайларның укуы белән кызыксына иде Мәктәпкә бер килүендә әдәби китап укырга иренгән укучыларны: «Ул нинди эш ул, минем улларым сезнең кебек чакта Жюль Верннның «Серле утравын» укыйлар иде инде», — дип әрләп тә китте (Бу китапларны Факия апа мәктәпкә тапшырды, алар мәктәп музеенда саклана). Дөнья гизүче якташыбыз Вахит Юнысның күренекле шәхес булып җитешүендә аның әнисе Факия апаның өлеше зур булгандыр.

Вахит Юныска быел 20 октябрьдә 65 яшь тулды.

Вахит — Татарстанның Баулы районы Исергәп авылында туган гади авыл малае 7 сыйныфны тәмамлаганнан соң, читтә яшәвенә карамастан, туган телен самими-саф килеш саклаган «Телне саклавым — мәрхүмә әнием мирасы, — ди Вахит. — Туганым Миргазиян Юнысның татар язучысы булуына да ул тәэсир иткәндер Мин Шөгер мәктәбендә тарих, тел, әдәбият, логика һәм психологияне татар телендә укыттым. Соңгы ике фәнне татар телендә алып баруны күз алдына китерәгез әле!»

Үзенең нык ихтыяры, белемгә, дөнья күрергә омтылышы, максатчанлыгы аркасында Вахит Юныс гади авыл малаеннан педагог, филолог, халыкара мөнәсәбәтләр белгече, журналист,экономист, сәяхәтче булу дәрәҗәсенә ирешә Ул 4 уку йорты тәмамлады, кулында 4 дипломы бар Бөгелмә педучилищесы һәм укытучылар институтын тәмамлаганнан соң, укытучы һәм мәгариф бүлегендә инспектор булып эшләдә 6 ел МГИМОда (Мәскәү халыкара багланышлар институты) укыды һәм СССР Госпланының югары экономик курсларын тәмамлады.

Вахит Юныс белгечлеге буенча һәм эше төшеп 70 чит илдә булган Барысы 16 ел гомере чит илләрдә эшләп үткән. Иң күп эшләгән илләре — Гыйрак (7 ел), Мисыр (3 ел ярым), Әфганстан (3 ел ярым), Сүрия (1 ел).

В.Юныс асылда безнең илнең чит илләрдәге илчелекләрендә икътисад һәм сәүдә эшләрен алып бара Бу илләрдә яшәгәндә ул төрле тарихи вакыйгаларның шаһиты була Билгеле ки, хөкүмәт башлыклары, күренекле шәхесләр белән якыннан аралашып яши. 1994-95 нче елларда гына да Бразилиядә (Рио-де-Жанейро һәм Сан-Паулу шәһәрләрендә), Германиядә Швециядә, ике тапкыр Тайваньда. Гонконгта, Вьетнамда, Берләшкән Гарәп Әмирлекләрендә булып кайта.

Вахит Закир улы Юныс татар һәм урыс телләреннән тыш, тагын җиде чит телдә тегә яисә бу дәрәҗәдә сөйләшә немец, корея, гарәп, фарсы инглиз һ.б Вахит чит телләрне өйрәнүдә татар теле ифрат ярдәм итә, дип исәпли. «Татар теле гаҗәп матур, бай һәм гади тел, — ди ул. — Әгәр аны яхшы белсәң, тагын утызлап телдә аңлашырга мөмкин Димәк, татар телен әйбәт белгән кеше чын-чынлап үзен полиглот дип. саный ала Мин өч тапкыр Төркиядә булдым, татар анда төрекләр белән рәхәтләнеп аңлаша ала»

Вахит Юныс татар әдәбияты-сәнгате белән даими кызыксынып тора Үзе дә хикәяләр, очерклар, сәяхәтнамәләр һәм мәкаләләр яза Әйтик, соңгы 5 ел эчендә генә дә ул 90нан артык ил турында юлъязмалар. хикәяләр, эссе, публицистик һәм мәдәният буенча мәкаләләр бастырды. Ул — Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы.

Шушы көннәрдә генә Баулы район гәзитендә «Тагын телебез турында» дигән очеркы дөнья күрдә Ул анда татар телен саклау, баету турында фикерләрен әйтә. татар халкының киләчәктә киң халыкара мәйданга чыгуына зур ышаныч белән эш итәргә кирәк, ди

Вахит туган авылына туган төбәгенә ел саен диярлек кайта мәктәпләрдә, башка оешмаларда очрашулар үткәрә Элегрәк авылга бер кайтуында кич белән урамда (капка төбендә) өлкәннәргә үзенең йөргән җирләре турында сөйләдә. аннары шул җирләр турында диафильмнар күрсәттә Бәйрәмнәрдә мәктәпкә, укытучыларына котлау хатлары фоторәсемнәр җибәрә. Мәктәп музеенда бертуган Миргазиян һәм Вахит Юныларга багышланган стендлар бар Шунысын да әйтик, Исергәптә мәчет салу эше башлангач, Миргазиян белән Вахит бу изге эшкә дә үз өлешләрен керттеләр.

Без, Вахит Юнысның авылдашлары, аны 65 яше тулу уңаеннан ихлас күңелдән котлыйбыз, аңа ныклы сәламәтлек, озын гомер, гаилә бәхете, иҗади эшендә зур уңышлар телибез. Канатларың бер дә талмасын, Илгизәр авылдашыбыз!

**Роза ҮТӘМИЕВА,**
**Гали ШАГАЛИЕВ,**
укытучы-пенсионерлар.
Баулы районы, Исергәп авылы.

## АВЫЛЫ БАРНЫҢ КАВЕМЕ БАР

Бәркон шулай авыл бе- ...н авыл арасында йөргә- ...дә, чиркәүләргә бөтенчә- ...ек күзем төшеп куйды ...пе. Торалар болар. Кара- ...ысыз. Кайсысы шәрә ха- ...лай җәелеп утырган, ...айсының каланчасы кук-

Шулай анысы.

Тик моның күзгә күренмәгән бер ягы бар. Өнә шул таркау авыллар кемнәндер башына төшкән мәшәкать, хәсрәт тә ич әле ул. Заманында аларны күршә авылларга йортка ке-

нең кадерен белүчеләрдән, игенчелек, терлекчелек, тозелештә азау төшләрен ярганнардан. Шуңа күрә, җиргә сеңгән кенсә баскыч төбенә чүмәшкәч, Хәмистән:

— Монда күчәргә ничек

Әлбәттә, сөйләшүебез болай шома гына түгел инде. Әле шоферлары килеп туктый да сүз ката, әле баласын күтәргән берәр хатын-кыз зарын-интизарын сөйли башлый. Боларын язып тормыйм инде, гадәти

ятабыз. Фермаларга асфальт юл түшибез. Ашханә, механизаторлар йорты, сигез еллык мәктәп... Җитәме?

Кече Әшнектә өтинең сеңлесенең олы улы Рәшит абый бар. Сөйләшә китсәң, аның:

— Мин, брат, кәкре мөгезле кәҗә алып башка чыккан кешә бит! — дип кабатлый торган гадәте бар. Шуны искә алып, Хәмискә:

— Син Имәнкискәдән ничек-ничек аерылдың? — дидем.

— Җиде йөз илле мөгездән санаганда күпмә була? — диде ул. — Мең дә биш йөз мөгез, әме? Көнгә дүрт тонна сөт сатабыз.

— Ни аласыз соң?

— Ни инде... өмет, ышаныч, брат.

— Кемгә ышанасың соң,

Әхәт ГАФФАР

# Ташларны җыяр вакыт

...ашкан. Аларны төзәтергә тотынсаң, тау күчерүгә ...рабәрдер. Ә авыллары ...ек инде. Урыслар өкрен... таралышкан. Ан... ...анда торып калган өйре кызганыч бер хис уя... Бу өйләр тезелешеп, ...р-берсенә тотынышып ...лгән, ә аннары ни хик...ттәндер аерылып адаш...н, кай тарафка юнәлергә ...лмәгән сукыр адәми за...арны хәтерләтә. Ул кый...ык өйләр, каралты-кура...р арасында яңалары ...гадәттә ике катлылары ...кукыраешып утыра. Бо...ры — буш урыннарны ...пеп алып «дача» кору...ларныкы. Кайвакытны ...эр, туфан сыман, барча ...ылларны басып китәр... шикелле. Килер за...н, дип уйлыйсың, төп ха...кка әлеге туфаннан ка... котылыр өчен Нух көй...ә кирәк булмагае.

...Шушындыйларның бер... — Лаеш районындагы ...пы авылы. Ул да тигез ...дә көтмәгәндә калкып ...кан кыя ише таш чирпе авыл. Тик ташның да ...заманны ком булып ...аны сыман, ул да хәл... хәлендә инде.

...өзәтүләре, сипләүләре ...шикле. Моннан Казан... ...аба 30 чакрымдагы Әс...дияр авылындагы мә...әт бер чиркәүне Амери...акчасына җүнләгәннә... аннары шундагылар... үз канатлары астына ...ннары шикелле итсә...генә инде.

...әфәрдәшемә:

— Шушы чиркәүләрне ...ак, кечкенә итеп сал...р, ярамаган микәнни? ...идем.

— Итәр сиңа урыс кеч...! — диде ул. — Кил...әкләр җир кызганып ...ан ди сиңа, бар!

— Хәзер төзәтә алмый...ич инде.

— Син салып куйган чи... түгел, эчең пошма-

ртеп бетерделәр. Янәмәсе, тигезләнсеннәр. 30 нчы елларны шәп хуҗалар белән булдыксыз, ялкау, үшән, тырбык гидайларны бутап, болгатып бетергән кебек инде. Ит изгелек, кот явызлык, дигәндәй, әлеге хәерчә авыллар кеше җилкәсен кимереп ятарга гадәтләнделәр, шушы өлкәдә шактый уңышка ирешеп, якты киләчәккә кушаяклап барып җитәргә өметләнделәр. Шул кушаяклап сикерәнгән аяклары гына чиләнеп беткән тышаулы булып чыкты.

Әлеге Чирпы авылы кешеләре дә ерак китә алмады. Боларны Имәнкискә дигән татар авылы алдан да тартып карады, арттан да этеп бакты. Ләкин алар кигәвеннән качкан көтү урынына таралыша бирделәр, шәһәр уҗымына тартылдылар. Мондый күтәрәмгә калганнарны өкренләп төрле хуҗалык оешмалары үзләренең «ярдәмче хуҗалык»лары итеп алды, аякка бастыра башлады. Кызык инде, кайсысы кайсысына ярдәмчедер бит әле, өйеме?

Чирпы да быел язын Имәнкискәдәге «Маяк» күмәк хуҗалыгыннан башка чыгып, «Кама» күмәк җитештерү хуҗалыгы рәвешен алып, Казандагы он комбинаты белән ярәшкән дә, шуның «ярдәмчесе»нә әйләнгән. «Кама»ның бүгенге җитәкчесе — Хәмис Хәйбуллов. Каратут йөзле, елгыр, тәнендә гайрәт, җанында ут уйнап торган ир уртасы кеше. Заманында алты ел буена Лаеш районындагы «Нармонка» совхозы директоры Гыйльфан Вафинның, аннары җиде ел Имәнкискәдәге «Маяк» колхозы рәисе Нургали Газиятуллинның хуҗалык эшләрә буенча урынбасары мәктәбен узган. Бу ике җитәкче дә — эшне оста оештыручылардан, кеше-

җөрьәт иттең? — дип сорадым. — Күтәрәмгә калганны күтәрә торгач, эчең төшмәгәе, брат.

— Ярдәмчеләр куәтле. Казаннар да, он комбинаты директоры Виктор Иванович Анисимов та бик булыша.

хәл.

...Янәшәбездә генә бер марҗа әбисе бәрәңге ала: үзе казый, үзе җыя, чиләктән капчыкка бушата, тутыра. Тырыша инде.

Хәмистән:

— Моның балалары кайда икән соң? — дип сора-



— Яхшы. Ә эшчеләрегезгә түләргә хәлегездән киләме соң?

— Зарланмыйлар. Сыер савучылар айга алты-җиде йөз мең тәңкәнә каерып ала, механизаторныкы дүрт йөз, биш йөз ярым мең сум чыга.

— Әй, әйттең сүз, — мәйтәм. — Бүген акча учта бишкә төрләнә ич ул. Өч-дүрт, биш-алты ай алмый торсалар, синең ярты миллионың каен тузы урынына дөрләп яна. Төтенен дә иснәми каласың.

— Безнекеләр төтен түгел, — диде Хәмис. — Айныкын айга бирәбез.

— Кит әле! — диюдән гайре ни әйтәсең инде?

дым.

— Белмим әле, — диде ул. — Минем хәзер бу авылда йөз утыз пенсионерым бар.

— Хәлләрен белешәсеңме соң?

— Беренче чиратта.

— Ә эшчеләрең күпме?

— Туксан. Утыз өйгә газ керттек. Көзгә тагын кырыгына кертергә ниятлибез. Хәзер ярты авыл суга чиләк-көянтә күтәреп йөрми. Калганнарын да коткарырбыз.

— Әйбәт. Ә бу хәрабәләреңнән ничек котылмак буласың соң, Хәмис?

— Җылы гараж салдык. Үзең күрәсең, хәзер фураж саклагычлары төзеп

Хәмис?

— Халыкка. Тирә-күрше хуҗалыкларга. Имәнкискәдән аерылгач, өнәтерә Кече Елга рәисе Равил Әхмәтов комбайннар җибәрде. Аннары суң Имәнкискә дә аяк типми, рәхмәт төшкерә. Син сорадың да сорадың. Мәчет саласыңмы инде, дигән соравыңны көткәнием. Ә син чиркәү дип баш катырасың. Шулай итеп язасыңмы инде?

Мин уйга калдым. Хәзер җавап бирәм.

— Дустым Хәмис! Мин — хәерчә классик. Ә сез — классически байлар. Әйдә, шушы нәрсәләрне бергә-бергә хәл кылыйк.

**Лаеш районы,**
**Имәнкискә — Чирпы.**

## ...Ак барс» пакь булып калды

...тарстан Министрлар ...нетының 1995 ел, 27 ...брь көнне кабул ите... 692 санлы карары бе... Республика яшүсмер... китапханәсенә Казан... Ибраһимов проспек... (Ибраһимов проспе... 55 А) яңа бина бирел-

**...ге карарда болай ди... Республика яшүсмер... итапханәсенең эшчә... н тәэмин итү макса... һәм аның өчен «Ак ... банкы билгәгән мөй... рда эш шартлары ...у сәбәпле, «Казан ...лет заводы» акцио...ык җәмгыятә кара... дагы 319 нчы бала... бакчасы бинасын, бакчага караган ...мойданчыгы белән ...кто, Татарстан Мә...т министрлыгы балансына тапшырырга.**

Без әлеге карар турында шатланып хәбәр итәбез һәм Татарстан Министрлар Кабинетына, Республика яшүсмерләр китапханәсе өчен 150 миллион сум матди ярдәм тәкъдим иткән «Ак барс» банкына, «Казан вертолет заводы» акционерлык җәмгыятенә рәхмәт белдереп, Республика яшүсмерләр китапханәсенә уңышлар телибез.

**P.S.** Мәдәният министрлыгыннан хәбәр итүләренчә, бүгенге көндә яңа бинага Республика яшүсмерләр китапханәсенең фондында сакланган 100 меңнән артык китап, 1977 елдан бирле яздырылып-алынып килгән гәзит-журналлар һәм җиһазлар күчерелде инде.

## ӘЛЕГЕ ДӘ БАЯГЫ

Кеше күңеле шулай корылган инде ул: яхшылыктан эри дә китә, барлык яманлыклар онытыла да куя. Безнең, китапханәчеләрнең «Ак барс» белән мөнәсәбәтендә дә нәкъ менә шулай булды. Ә әлеге мөнәсәбәтләр шактый ук кат-

# Банкирлар сүзендә торды

лаулы иде. Үзара каршылыклар һәм үпкә-рәнҗешләр бина мәсьәләсендә килеп чыкты. Мондый аңлашылмаучылыктан яшүсмерләр китапханәсенең яшь укучылары да иза чикте.

Мәдәният оешмасының банк билгеләгән бинада яши-эшли алмавын, әлбәттә, һәр ике як та яхшы аңлый иде. Банк җитәкчелегә, үз чиратында, китапханә өчен бина табарга тырышты һәм китапханәнең матди базасын ныгыту өчен хималәчелек ярдәме дә оештырырга вәгъдә итте.

Шактый озакка сузылган эзләнүләрдән соң, ниһаять, китапханә өчен мөстәкыйль бина табылды. Бу бина Яңа Савин районында, Г.Ибраһимов проспектында урнашкан. Безнең карашка, китапханә өчен бу бик тә уңайлы урын. Аның янәшәсендә генә берничә уку йорты бар, шулай ук төп транспорт юллары да якында гына. Димәк, яшьләр, шәһәр халкы китапханәгә һәрчак килеп йөри алачак. Моннан тыш, әлеге районда моңарчы социаль-мәдәни учакларның бигүк җитенкерәмәвен дә әйтеп үтәргә кирәк. Китапханә яшьләрнең шөгыльлән-ялын оештыру өчен шактый зур мөмкинлекләргә ия булачак.

Китапханәне яңа бинага күчергәндә дә коллективка нәкъ менә «Ак барс» банкы ярдәм итте. Аның җитәкчелегә китапларны, гәзит-журналларны һәм җиһазларны ташу өчен транспорт бирде, эшчеләр билгеләдә. Һәм бәхетебезгә яңа бинаны китапханә галәпләренчә үзгәртеп кору өчен банк тарафыннан безгә элек вәгъдә ителгән йөз илле миллион сум акча да бүлеп бирелде.

Республика яшүсмерләр китапханәсе «Ак барс» банкына чын күңелдән рәхмәт белдерә, сүзендә тора белгән банкирларыбыз булуына шатлана һәм киләчәктә дә ярдәмнәреннән ташламаслар дип ышана.

**Республика яшүсмерләр китапханәсе дирекциясе һәм хезмәткәрләре.**

***«Мәдәни җомга»ның 3, 5, 8 нче саннарында күтәрелгән мәсьәлә, ниһаять, уңай хәл ителде. Инде бәхескә кире әйләнеп кайтырга язмасын.***

*Филология фәннәре кандидаты Фәрит Яхинны укучыларыбыз «Олуг пәйгамбәр», «Пәйгамбәрләр тарихы», «Иман» кебек әсәрләре аша яхшы белә. Күптән түгел ул «Ислам диненең төп нигезләре бәяне» дигән хезмәтен тәмамлады. Әлеге хезмәт тә, элгәрләре кебек үк, тарихи чыганакларга нигезләнеп язылган.*

*Бу сәхифәдә без әнә шул әсәрдән өзекләр бастыра башлыйбыз.*

Фәрит ЯХИН



И мөэмин исемен алыр өчен җан аткан бәндә, син иманның алты сыйфатын белдереп әйтүең белән мөселман булдың. Син күңелдән әйтәсеңме, укып барасыңмы, яки кеше артыннан, ... лимең сүзләреннән соң кабатлап барасыңмы — болар барысы ... эшең. Әмма «укымадым-белмәдем» дип аклану бер дә дөрес эш ... иман китерү һәм шушы инануыңны гомерең буе саклау фарыз ... ләрдән санала, фарыз эшең булып тора.

«Әмәнтү билләһи», ягъни «Аллаһы Тәгаләгә инандым» дигән ... бу сүзләрнең үз эченә нәрсәләрне берләштерүен ачык итеп бе... кирәк. «Мин Аллаһы Тәгаләгә инандым, — диген. — Ул бер бердәнбер, затында һәм сыйфатында иптәше, охшашы юк, ким... ле сыйфатлардан азат вә пакь, камил сыйфатлар белән сыйфа... ган, барча җан ияләре-мәхлукатьләрне юктан бар иткән, гый... өчен бары ул гына лаеклы һәм тиешле булуына ышаныч итәм». ... шундый бәндәләр бардыр, алар һәр сүзгә дәлил сорарлар. Ал... Тәгаләнең барлыгына дәлил Коръән аятьләреннән билгеле булы...

# ИСЛАМ ДИНЕНЕҢ ТӨП НИГЕЗЛӘРЕ БӘЯН...

## Иманның сыйфатлары

Иманның сыйфатлары алты төрле булып, аларны

«әмәнту билләһи» — آمَنْتُ بِاللَّهِ

«вә мәләикәтиһи», — وَمَلَائِكَتِهِ

«вә кутубиһи», — وَكُتُبِهِ

«вә русулиһи», — وَرُسُلِهِ

«вәл-йәумил-ахири» — وَالْيَوْمِ الْآخِرِ

«вә бил-кадәри хәйриһи», — وَبِالْقَدَرِ خَيْرِهِ

«вә шәрриһи минә Аллаһи тәгалә», — وَشَرِّهِ مِنَ اللَّهِ تَعَالَى

диләр.

Бу алты төр иман дин теленде «иманның шартлары», яки «иман шарты» дип аталып йөртелә, аны шулай ук «зат иман», «асыл иман», «мөэминнәр иманы» дигән сүзләр белән дә белдерәләр. Димәк, бу иманның алты сыйфатын санаганда без аларны иманның шартлары (иман шарты) яки зат иман, яисә асыл иман, йә булмаса мөэминнәр иманы рәвешендә аңларга һәм күңелебез белән инанган рәвештә телебез белән әйтә алырга тиешбез. Иман сүзләренең кодрәте вә башка диннәр каршында куәте зурдыр. Бәндәләр, ир булсыннар, яки хатын-кыз затыннан торсыннар, алар шушы иман сүзләрен, ягъни «Мин Аллаһы Тәгаләгә инанам, шулай ук фәрештәләренә, китапларына, пәйгамбәрләренә, Ахирәт көненә, хәерле вә яман тәкъдиренә ышанам вә ышаныч белдерәм». дип үз ана телләрендә чын мәгънәсендә моның хаклыгын җан-тәннәре белән тоеп әйтә алалар икән, алар шуның белән мөэмин-мөэминә (мөслим-мөслимә) дәрәҗәсен алырлар һәм Аллаһы Тәгалә каршында сөекле колларына әверелерләр, Кыямәт көненең авырлыкларыннан вә тәмуг газапларыннан, әгәрем ки үзләре начарлык вә бозык эшләре белән зыянлы шөгыльләр кылмасалар, һичшиксез котылырлар, җәзасыз калырлар һәм рәхмәт вә рәхәт табарлар Иманлы бәндәләрне Аллаһы Тәгалә үзенең ярдәменнән ташламас.

Кем дә кем иманга килә, ул шуның белән үз өстенә мөэминнәрдән таләп ителә торган бурычларны ала. Кем дә кем имансыз кала, ул кеше үзен бәхетсезлек вә җәбер-җәфага хөкем итә Бәндәнең күргәне һәм күрәчәге Аллаһы Тәгаләдәндер, чөнки бәндәләрнең үз-үзләрен тотышларына карап аларга җәзалар бирә, бәндәләрнең күргәне вә күрәчәге үзләренең кулындадыр, чөнки алар үз теләкләре белән тәгә яки бу гамәлне кылалар, яманлык өчен яманлык, яхшылык белән яхшылыкны табалар, Аллаһы Тәгаләдән уза алмыйлар, чөнки Хак Тәгалә бар нәрсәләрне күреп вә белеп торучы булапак ахырдан үзе хөкем йөртәр

Аять:

... أَفِي اللَّهِ شَكٌّ فَاطِرِ السَّمَاوَاتِ وَالْأَرْضِ

**Аятьнең мәгънәсе:** «Аллаһы Тәгаләнең барлыгына һичбер шик ... мы, бәлки дәлилләрнең күплеге һәм ул дәлилләр барлыгына бик ... дәлиллелек күренгәнлеге өчен шик ихтималы юк, ул Аллаһы Тә... җирнең вә күкләрнең барлыкка китерүчеседер». Аллаһы Тәгалә... бердәнбер икәнлегенә дәлил шулай ук Коръән аятендә китерелә...

قُلْ هُوَ اللَّهُ أَحَدٌ اللَّهُ الصَّمَدُ لَمْ يَلِدْ وَلَمْ يُولَدْ وَلَمْ
يَكُنْ لَهُ كُفُوًا أَحَدٌ

**Аятьнең мәгънәсе:** «(И Мөхәммәд), әйт, Аллаһы Тәгалә бер генә... Ул камил хуҗадыр. Ул һичкемне тудырмады һәм үзе дә һичкем... тумады, һичкем аңа тиң түгел».

Моңа өстәп, тагын да бер аятьне искә төшереп үтәргә мөмкин.

Аять:

لَوْ كَانَ فِيهِمَا آلِهَةٌ إِلَّا اللَّهُ لَفَسَدَتَا

**Аятьнең мәгънәсе:** «Әгәр күкләрдә һәм җирләрдә Аллаһы Тәга... дән башка бер Аллаһ булса иде, болар үзара бозылыр һәм б... карарда тормас иделәр».

Моннан фәлсәфәи фикер казанышы өчен шулар күренер. Алла... Тәгалә бер һәм ялгыз, әгәрем ки алар икәү булсалар, ул вакытта ... ике камил акыл үзара тартышыр, тегесе яки монысы өстен чыга... тырышыр һәм галәмнең тәртибе бозылып, тынычлык югалыр и... Халкыбызда бер мәкаль бар: «Ике тәкә башы бер казанга сыймы... Бу сүздән үзебез өчен күңелгә барып җитәрлек төшенчә чыга... алабыз. Тарихлардан шулай күренә ки, тәхет өстенә ике хан я... падишаһ менеп утырса, алар бер-берсенә дошманлык кылып, ил... тынычлыгын бозарлар иде. Мәмләкәтләрнең таркалуы вә бетүе ... шуның аркасында. Читтән басып кергән дошманны куып чыгары... була, әмма ил эчендәге бозыклыкны, туган белән туганның га... калашуын җиңү мөмкин түгел эшләрдән. Димәк, камиллеккә ирешү... чиге юк дип белсәк тә, шуны төшеник: камиллекнең нигезе — ялгыз... лыкта, күплектә түгел. Бер урынына ике булуга ук камиллек җимер... лә. Шуның өчен дә суфи вә дәрвишләр ялгызлыкны өстен күргән... шәех яки ишаннарының итәкләренә генә тотынып йөрү аркасында ... юлында адашмаганнар, ягъни үзләре ялгызлык белән камиллек... ирешү генә түгел, тагын да югарырак дәрәҗәгә омтылып, ялгыз б... шәех яки ишанга гына ияргәннәр, бер даирәдән икенчесенә күч... йөрүләрне сагашу итеп кабул күргәннәр. Гомумилек, берләшү к... өчен кирәк, ялгыз берәүгә буйсыну, ягъни ялгызлыкка ирешү — к... миллекне табу өчен шарт. Әгәр дә шәех яки рухи җитәкченең с... синең тарафтан хакыйкый һәм дөрес дип кабул кылынмый ик... башка фикергә тукталсаң, ул вакытта камиллегең югала, күңел... тынычсызлануга югыла.

«Әмәнтү билләһи...» сүзләренең мәгънәсе менә шушылар бел... аңлатылыр, аның дәвамы булган «вә мәләикәтиһи», ягъни «һәм ан... фәрештәләренә» дигән вакытыбызда, «мин Аллаһы Тәгаләнең фәре... тәләре булганлыгына инандым» дигән төшенчә хисап ителә Коръ... хәдисләр гыйлемнәреннән аңлашылганча, фәрештәләр ашамаслар ... эчмәсләр, ризык җыюда һичбер мохтаҗлыклары күренмәс, алар... ирлек вә хатынлык сыйфатлары да юк, шунлыктан җенес теләг... ярдәмендә ишәймәсләр. Алар күкләрдән җир йөзенә иңәрләр ... җирдән күкләргә чыгарлар, моны бер дә авырлыксыз вә артык к... куймыйча башкарырлар, бер хәлдән җиңел генә икенчесенә к... алырлар, сурәт, төс, кыяфәтләрен алмаштырырлар, каөат асыл р... шләренә кайтырлар.

(Дәвамы бар).

## ДҮШӘМБЕ

### 30 ОКТЯБРЬ

#### «ТАТАРСТАН»

.00—8.00 «Чулпан» информацион програм-асы. 17.55 Мультфильм. 18.15 Балалар ıeн «Тамчы». 18.30 «Сайлауларны каршы-ап». 19.00 «Татарстан». 19.30 «Телебуклет». апшырулар анонслары. 19.40 «Әлли-бәл-и-бәү». 19.45 «Түгәрәк өстәл». Реформалар рограммасы: ул нинди булырга тиеш? Тап-ыруда ТР беренче Вице-премьеры Р.Мо-атов һәм журналистлар катнаша. 20.25 До-ументаль фильм. 20.45 «Чүпрәле басула-ына нәрсә яный?» Районнан репортаж. 1.30 «Консерватория сәхнәсендә». Пианист .Михайлов. 21.40 Экранда кинокомедия: Тридцать три». Рольләрдә: Е.Леонов, Н.Мо-дюкова. 22.55 Тапшырулар программасы.

#### «ЭФИР»

.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 «Эфирда – музыка». 7.30 «КиноМеню». 8.00 «ПОСТ» – музыка яңалыклары. 8.15, 11.05 — «Юл атруле». Атналык йомгак. 8.30, 14.45 «Даруханә». 8.40 «Сул аяктан!». 9.20, 2.50 — «90x60x90». 9.40 Диск-канал. 10.00 Канун». 10.30 Сериал: «Один к десяти». 1.20 «Атна фаразлары». 11.50 «Валюта бә-се». 12.00 Нәфис фильм: «Мстители». 5 нче ерия. 13.05 Нәфис фильм: «Республика Јкид». 15.00 Телесериал: «Флиппер». 9 нчы əм 10 нчы сериялəр. 16.00 «Русская живо-ись XX века» циклыннан документаль ильм: «Петербургский каталог», «Перла-утровые грезы». 16.55 Документаль ильм: «Дом в Матвеевском». 18.05 А.Габ-иловичның документаль фильмы: «Анд-ей». А.Миронов истәлегенә. 19.20 «Эфирда – музыка». 19.30 «Видеомода». 19.50 «Кы-лар һәм матурлар». 20.20, 23.45 — «Шә-әр» информацион программасы. 20.45 «Ла-иса» яңалыклары. 21.15 Телеэкспресс. 1.35 «Криминаль хроника тележурналы». 2.05 Нәфис фильм: «Не плачь больше, до-огая». 0.05 «TAP RECORDS» коллекциясен-ән. «Siouxsie» төркеме.

#### 1 НЧЕ КАНАЛ

.00 Иртә. 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.00 - Яңалыклар. 9.15 Телесериал: «Тропикан-а». 10.05 «Могҗизалар кыры». 11.00 «Кеше əм закон». 11.30 Телеуен: «Көен таны». 2.10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телеради-компаниясе тапшырулары. 12.50 «Приклю-ения Шерлока Холмса и доктора Ватсона» ериалыннан нәфис фильм: «Соломенная ляпка». 1 нче серия. 14.00 Мультфильм: Доремиэ. 14.15 «Кумирлар, кумирлар...» Самоцветы». 15.20 Мультсериал: «Виджит пешит на помощь». 15.40 «Марафон-15». .00 «Йолдызлар сәгате». 16.35 Яшьләр се-алы: «Элен и ребята». 17.00 «Джем». .30, 0.35 — «Спортның җиде көне». 18.20 лесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зы-ылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». .00 «Әгәр...» В.Познерның авторлык про-аммасы. 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». .00 «Вакыт». 21.50 Фантастик детектив: Электронные жучки-5». «Горячий металл». .50 «Көмеш шар». М.Козаков. В.Вульф ып бара. 23.30, 0.10 — Сериал: «Твин икс»

#### «РУСИЯ»

30 «Эшлекле кешеләр вакыты». 8.00, .00, 14.00, 17.00, 20.00, 23.00 — Хәбәрләр. 25 «Кирәк, кирәк...» 8.30 «Йолдызлар сөй-». 8.35 «Ритмика». 8.50 «Үтә яшерен». 9.40 елегазета». 9.45 «Рыжовларның театраль настиясе». 10.50 «Мәһим мизгел». 11.20. илиция хроникасы». 11.30 Мульти-пульти: олшебник Изумрудного города». 12.15 ңа тармак». 12.30, 14.20 — «Эшлекле Ру-я». 16.05 «Шау-шулы яңалыклар». 16.20 он дә бәйрәм». 16.30 «Могҗизаларга ярты гать». 17.20 «Яңа тармак». «Бәлкем...» 50 «Минем сугыш». Г.Гоппа. 18.20 «Алыр-ны-алмаскамы». 18.30 «Коткару-911». 25 «Сабый авызыннан». 20.25 әйнә-бәйнә». 20.35 «Дүшәмбе саен детек-в». «Инспектор Морс» сериалыннан нә-с фильм: «Доведенный до отчаяния» (Бө-британия). 21.45 «Репортер». 22.05 «Ха-йкать мизгеле». 23.30 «Вакыт елгасы». 35 «Автомизгел». 23.40 «299-00-00» хезмә-. 23.55 Төнге телесериал. Нәфис фильм: октор Фаустус». (ФРГ). 1 нче серия. 0.55 алиҗанап мәхәббәт». Юлиан җырлый.

#### «САНКТ-ПЕТЕРБУРГ»

0 «Хәерле иртә!» 7.45, 11.45 — «Тәҗрибә». 5 «Киңәшче». 8.45 «Балалар өчен». 9.15 үзәллек». 10.20 «Төш юрау». 10.40 «Так-клар». 11.15 «Коллекционерлар». 12.10 узыка». 12.40 «Кунак». 13.00, 15.30, 22.45 ТВ мәгълүматлары. 13.10 «Яшәү стиле». 25, 15.40, 17.55, 22.25 — «Музыка миз-ле». 13.30 ТВ мәгълүматлары. Немец дул-кыны. 13.45 Мультфильм: «Ромка, Фомка Артос». 1 нче фильм. 14.00 «Ашыгыч яр-дәм». 14.30 Телефильм: «Мануэла». 15.20 акчачыларга киңәшләр». 15.45 Ура, коме-я! Нәфис фильм: «Непорядочный дядя». 25 Телефильм-концерт: «Столько чувства апеве родном». 18.00 ТВ мәгълүматлары. ропа калейдоскобы. 15 «Телеблиц». 22.30 «Шәһәр эшләре». 00 «Спорт, спорт, спорт...» 23.15 Музы-ль шоу: «Телекомпакт». 0.15 Нәфис те-фильм: «Валентина» (Италия). 9 нчы се-я.

## СИШӘМБЕ

### 31 ОКТЯБРЬ

#### «ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.20 Мультфильм. 18.30 Хоккей. МХЛ чемпионаты. «Ак Барс» (Казан) — «Торпедо» (Түбән Новгород). Турыдан-туры трансляция. 19.00 «Татарстан». 19.30 Хоккей матчының дәвамы. 20.30 «Әлли-бәлли-бәү». 20.35 «Хосусыйлаштыру: сораулар һәм җаваплар». 21.05 Күп серияле нәфис фильм премьерасы: «Тарзан». 24 нче һәм 25 нче серияләр (Мексика — Канада — Франция). 21.55 «Җидегән чишмә». Композитор С.Садыйкова. 22.55 Тапшырулар программасы.

#### «ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!». 7.10 «Эфирда — музыка». 7.30, 20.20, 0.25 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (30 октябрь тапшыруын кабатлау). 8.15, 11.05 — «Юл патруле». 8.30, 14.45 — «Даруханә». 8.40 «Сул аяктан!». 9.20, 13.00 — «90x60x90». 9.40 «Диск-канал». 10.00 «Минем кино»: Л.Ярмольник. 10.40 Юмористик сериал: «Один к десяти». 11.20, 18.25 — «Атна һәлакәтләре». 11.50 «Валюта бәясе». 12.00 Сериал: «Спасатели Малибу». 13.10 Нәфис фильм: «Подружка моя». 15.00 «Музыка һәм матбугат». «Каләм осталары». Андрей Разин. 16.15 «Кинескоп-100» киноканалы. 19.00 Сериал: «Против течения». 8 нче серия. 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 «Коммерция әйләнмәсе». 21.05 Мультфильм: «Малиновка и медведь». 21.15 Телеэкспресс. 21.35 Туры эфирда уен: «Кичкечың». 22.35 Русия киносы көне. Нәфис фильм: «Очарованный странник».

## ЧӘРШӘМБЕ

### 1 НОЯБРЬ

#### «ТАТАРСТАН»

7.00—8.00 «Чулпан» информацион программасы. 18.00 Телеочерк: «Леша агай» («Бәгелмә» телевидениесе). 18.30 «Моңнар кайта еректан» «Сорнай» ансамбле. 19.00 «Татарстан» 19.25 «Досье-02.» 19.45 «Турыдан-туры элемтә» Телевизор караучылар сорауларына Казан шәһәре һәм районнары хакимиятләре башлыклары җавап бирә. 20.45 «Әлли-бәлли-бәү» 20.55 Нәфис фильм: «Анна Каренина» 1 нче серия Рольләрдә: Т.Самойлова, В.Лановой. 22.05 Тапшырулар программасы.

#### «ЭФИР»

7.00 «Зарядкага басыгыз!» 7.10 «Эфирда — музыка» 7.30, 20.20, 0.15 — «Шәһәр» информацион программасы. 7.55 Телеэкспресс (31 октябрь тапшыруын кабатлау). 8.15, 11.05, 18.15 — «Юл патруле» 8.30, 14.45 — «Даруханә». 8.40 «Сул аяктан» 9.20, 13.00 — «90x60x90». 9.40 «Диск-канал». 10.00 «Минем тарих»: А.Градский. 10.40 Сериал: «Один к десяти». 11.20, 15.20 — «Атна низаглары». 11.50 «Валюта бәясе». 12.00 Сериал: «Ночная жара». 13.15 Нәфис фильм: «Бегущая по волнам». 15.00 «Тегеләр, кемнәр» 15.50 «Планета земля»: «Живой механизм» 16.45 «Эрмитаж» сериалыннан: «Арсенал». «Третья особая кладовая». 17.40 «Кино музыкасы». 18.00 «POST — музыка яңалыклары». 18.30 Диск-канал: «BEE GEES». 19.15 «Янгын куркынычсызлыгы айлыгы» «Утсыз төтен булмый» 19.20 «Поза» 19.50 «Кыюлар һәм матурлар». 20.45 «Казан» автосалоны.

## АТНАЛЫК МАНЗАРА TV

#### 1 НЧЕ КАНАЛ

6.00 Иртә. 9.00, 12.00, 15.00, 18.00, 0.00 — «Яңалыклар». 9.15 Телесериал: «Тропиканка». 10.05 В.Познерның авторлык программасы: «Әгәр...» 10.50 «Көлкеле манзара». Е.Петросян алып бара. 11.20 Мультфильм: «Большой Ух». 11.30 Телеуен: «Көен таны». 12.10 Эфирда — «Мир» Дәүләтара телерадиокомпаниясе тапшырулары. 12.50 «Соломенная шляпка». 2 нче серия. 14.00 Сериал: «Ставка больше, чем жизнь». 15.20 Мультсериал: «Виджит спешит на помощь». 15.40 «Күңелле квампания» кварьетесы. 15.50 «Мультитроллия». 16.10 «Тылсымлы дөнья, яки Синема». 16.35 Яшьләр өчен сериал: «Элен и ребята» (Франция). 17.00 «16 яшькәчә һәм өлкәнрәкләр өчен». 17.30 «Спортның җиде көне». 18.20 Телесериал: «Тропиканка». 19.10 «Ыгы-зыгылы сәгать». 19.35 Телеуен: «Көен таны». 20.00 «Тема». 20.45 «Тыныч йокы, нәниләр». 21.00 «Вакыт». 21.50 Т.Макарова һәм П.Алейников «Семеро смелых» фильмында. 23.30 «Мәскәү-Кремль». 23.50, 0.10 — Сериал: «Твин Пикс». 0.50 Хоккей. МХЛ чемпионаты. «Спартак» — «Крылья советов». 3 нче период.
Төнге канал: 1.30 Сериал: «Ставка больше, чем жизнь». 2.30 Ярослав Евдокимов фильм-концерты: «Пока на земле существует любовь».

#### «РУСИЯ»

